ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№6 (365)
ИЮНЬ 2022

СОҢГЫ КЫҢГЫРАУ:
КИЛӘЧӘК ИРТӘГЕДӘН БАШЛАНА

Редакциядән

ТЫНГЫ БЕЛМӘС ЯШЬЛЕК ТУРЫНДА

«Татарстан» редакция коллегиясенең яңа командасын туплый. Кабул итү чакырылган мөхәррир вазыйфасы «тикшерүе» аша алып барыла. Йөз еллык тарихка ия «Татарстан» журналы республиканың беренче затлары – тарихта тәүге РКП (б) Татар өлкә комитеты секретаре Александр Таняевның; ВКП (б) Татар өлкә комитетының беренче секретаре Александр Карповның; ТАССР Халык Комиссарлары Советы рәисе урынбасары Гасыйм Мансуровның; ВКП (б) Татар өлкә комитеты секретаре Мендель Хатаевичның үз заманында басмабызны җитәкләве белән горурлана…

Күптән түгел генә бер санъбыз чакырылган мөхәррир – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева җитәкчелегендә эшләнде. «Китап саны»нда «Татарстан» редакциясе китап укырга яратмаучы буында укуга мәхәббәт уяту турында сөйләде.

Сез кулда тоткан санны Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов җитәкләде. Ул да китаплардан башлады, чөнки тормыштагы күп кенә сорауларга җавапны нәкъ менә шул чыганак бирә.

Без, Татарстанның иң яшь министрының китап тәҗрибәсенә таянып, Татарстанның иң «яшь» номерын эшләдек:

республикада яшьләрнең акчаны ничек эшли алуы турында;

Татарстан яшьләренең ни өчен авылны сайлавы хакында;

студотрядларга йөрүчеләрнең уй-хисләре турында.

Һәм, әлбәттә инде, тынгысыз яшьлек еллары төрле заманнарга туры килгән әти-әниләребезнең язмышы хакында.

– Бу көннәрдә республикада барган төп вакыйгаларны чагылдырырга онытмагыз! Ислам да – иң яшь дин бит! – диде Тимур Сөләйманов Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу хөрмәтенә оештырылган бәйрәмгә хәбәрчеләребезне юллаганда.

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Яңарыш юлында
Идел буе Болгарстанында исламны кабул итүнең 1100 еллыгын ничек бәйрәм иттеләр

14. Ядкәрләрне саклау: Татарстан тәҗрибәсе
Тиңдәшсез тарихи объектларны ничек торгыздылар

16. Иман нуры
Болгарга Багдад хәлифәсе илчелеге нинди максат белән килгән

20. «Нурулла» мәчете
Аллаһ йортын кем төзеткән

игелекле эшләр

26. Хыялга юл
Талантлар Университеты кемгә булыша

28. Киләчәкне төзү форсаты
Махсус билгеләнештәге отрядта нәрсәгә өйрәтәләр

30. Шигъри бәйгеләр
Поэзия өчен грантлар отып буламы

32. Ихсановларның тату гаиләсе:
Яшьләр, тынгысызлар, булдыклылар

34. Сәламәтлек сагында
Авылны сайлаган табиблар

36. Редакция кухнясы
Эшлекле ханымнар нәрсә белән сыйлый

40. Шук-шаяннар командасы
Канн фестивалендә ничек лауреат булырга

53. Көч-дәрт ташып торган чак...
Күренекле кешеләребезнең яшьлек еллары нинди булган

70. Китап дөньясы
Яшьләр эшләре министры нинди китаплар укый

мәңгелек кыйммәтләр

74. Безнең киштәдә
Ул безне кабат эзләп тапты...

77. Тарих сәхифәләре
Таҗетдин Ялчыгол татар мәдәниятендә нинди эз калдырган

84. Татарстан авыллары
Түбән Ушмы: урам тулы бала-чага

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Искәндәр Измайлов, Ксения Сёмина, Луиза Шарова
Фотографлар: Анна Арахамия, Рамил Гали, Александр Ефремов, Евгений Канаев, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: 1993 елда Яшел Үзән шәһәрендә «Соңгы кыңгырау» бәйрәме.
Фото: Евгений Канаев.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–1612
Басарга кул куелды: 07.06.2022
Басмадан чыкты: 14.06.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

Акыллы гамәлләр

19.05

Россия Федерациясе Президенты, – Идел Болгар дәүләтендә исламны кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итү чараларында катнашучыларны һәм оештыручыларны сәламләү сүзендә:

– Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итү илебез тарихында мөһим дәверләрнең берсе булды, күпконфессияле дәүләт буларак оешуына шактый зур йогынты ясады, Россиянең күпмилләтле бердәм һәм дус халкын формалаштыруда әһәмиятле роль уйнады. Гасырлар дәвамында Россия мөселманнары ил үсешенә зур өлеш кертте һәм кертә. Аларның төрледән-төрле сфералардагы казанышлары – безнең бай тарихи, фәнни, мәдәни һәм рухи мирасның алыштыргысыз өлеше.

Игелекле эшләр

19.05

Гурбангулы Бердымөхәммәдов, Милли Генгешы Халык Мәсләхәте Рәисе, – «KazanSummit 2022» XIII Халыкара икътисадый саммитының пленар утырышында:

– Татарстан традицион рәвештә икътисадый, сәүдә, инвестицион, гуманитар сфераларда дәүләтара хезмәттәшлекне үстерүгә юнәлдерелгән күп кенә проект, тәкъдимнәрнең инициаторы һәм гамәлгә ашыручысы булып тора. Мондый миссия бүген бигрәк тә кирәк. Ул гомер-гомергә Россия – Ислам дөньясы мәдәнияте тудырылган һәм баетылган, Россия һәм мөселман илләренең фикер сөреше һәм рухи якынлыгы формалашкан нигезне сакларга һәм ныгытырга тиеш.

Мәңгелек кыйммәтләр

20.05

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Президенты, «Россия–Ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме рәисе, – Казан Ратушасында Төркем утырышын ачканда:

– Без иң мөһим кыйммәт, үсеш ресурсы, мәдәниятләрнең аралашуы һәм үзара баетылуы буларак этномәдәни төрлелекне формалаштыру һәм ныгытуның кирәклегенә иманабыз. Бүген традицион кыйммәтләрне яклаучы, күп поляр дөнья позицияләрендә торучы дәүләт һәм халыкларның берләшүе, Россиянең ислам, гарәп илләре белән үзара файдалы икътисадый хезмәттәшлеге бигрәк тә әһәмиятле.

Фото: Алексей Дружинин/ТАСС, ru.wikipedia.org

ИГЕЛЕКЛЕ эшләр

акыллы гамәлләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Идел буе Болгарстанында исламны кабул итүнең 1100 еллыгын **НИЧЕК** бәйрәм иттеләр

Бүгенге Болгар **НӘРСӘДӘН** башланды

Ата-бабаларыбыз **НИ ӨЧЕН** ислам цивилизациясенә кушылган

Казанда «Нурулла» мәчете **КАЙЧАН** төзелгән

МОГҖИЗА ШАҺИТЛАРЫ

– Татарстаннан килгән кунаклар – «Без», ә башка төбәкләрдән килгәннәр – «Булдырабыз!» дип кычкыра. Әйдәгез, эшләп карыйк әле! – дип мөрәҗәгать итә алып баручы бәйрәм сәхнәсе тирәсендәге тамашачыларга.

Колакны ярырлык «Без булдырабыз!» сөрәне Болгарга һәм Идел елгасы буйлап тарала.

– Мин сезнең кайсы яклардан килгәнегезне белергә телим. Биредә Түбән Новгород бармы? – дип дәвам итә алып баручы.

– Без монда!

– Ульяновск?

– Монда!

– Пермь! Омск! Иркутск! Уфа! Архангельск! Пенза! Киров өлкәсе! Төмән өлкәсе! – һәркем «Изге Болгар җыены» вакытында Идел буе Болгарстанында ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итәргә җыелган меңләгән кешенең аны ишетүен тели.

922-2022

Бәйрәм гомумфедераль дәрәҗәдәге чара дип игълан ителде, әмма Татарстанга кунаклар бөтен дөньядан килгән кебек.

Тантаналы бәйрәмне кабул итүче Болгар бу сәгатьләрдә ярминкә, һөнәрчелек остаханәләре, азык-төлек тулы киштәләр, җыр-биюле сәхнәләрне туплап, кайнап торган шәһәргә әверелде. Һәркем биргә килгән имамнарның берәрсе янына килеп сөйләшә-аралаша, алардан хәер-фатиха алу мөмкинлегенә ия. Кешеләр барысына да өлгерергә тырыша: Болгарның борынгы һәйкәлләрен карарга да, хәләл тәм-томнарны авыз итәргә дә, тантаналы тамашаны карарга да, бергәләшеп өйлә намазын укырга да…

Иман һәм бердәмлек тантанасы мохитендә тарихи истәлекле көнне күз алдына китерү дә җиңел.

– Күңелләрдә ышаныч булмый торып, мондый салкында яшәп буламы? Мондагы кешеләрнең күңелен дин җылытыр, иншаллаһ. Менә күрерсез:

Фото: Александр Ефремов

бу җирләрдә Аллаһ кодрәте белән ислам таралыр, – ди сәхнәдән Алмыш хан образындагы актер.

Һава торышы куанырлык түгел: кояш болыт артына качуга, салкын яңгыр башлана, боз да явып китә, аннан соң ялтырап янә кояш чыга. Әмма моңа беркем дә игътибар итми. Җәмигъ мәчете янындагы сәхнә тирәли җыелган халык ислам кабул итүнең татарлар һәм әлеге гаҗәеп дин белән очрашкан һәр кешенең тормышында никадәр зур роль уйнаганлыгы, бөек иман кыйммәтен һәм ислам дөньясына якынлыкны безнең төбәкнең ничек саклап калганлыгы һәм ныгытканлыгы турында чыгышларны күңел салып тыңлый. Мең дә бер йөз ел элек Идел буе Болгарстаны бер илдән килгән илчеләрне каршылаган булса, хәзер дөньяның 76 дәүләтеннән 27 илчелек делегациясен үзендә кабул итә.

Сәхнәдә милли киемнәрдәге артистлар башкаруында сәламләү җыры яңгырый. «Болгарым, Казаным! Шаула син җырларда», – дип җырлый алар.

Мөхтәрәм кунаклар тантаналы котлау сүзләрен ирештерә. Тәүбә намазын, тәүбә-истигъфар догаларын укыйлар. Тантана тәмамлана, өйлә намазына дәшеп, азан яңгырый. Берничә йөз, ә бәлки әле меңләгән мөселман Җәмигъ мәчете эчендә һәм аның диварлары янында намазга тезелә. Алар төрле телләрдә сөйләшә, әмма намаз иманга, рухияткә, Аллаһка омтылышта һәркемне берләштерә.

Тантана тәмам. Кунаклар таралыша. Аларның күбесе Болгардан туп-туры үз илләренә – меңнәрчә чакрымга сузылган кайтыр юлга кузгала. Җыен кунакларының хатирәләре төрле булачак, ләкин бик күпләрдә һичшиксез уртак тойгы – могҗизага кагылу, анда шәхсән катнашу хисе калачак.

Әлбир Крганов, «Мәскәү мөфтияте» Мәскәү шәһәре һәм Үзәк төбәк мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие, Чуваш Республикасы мөселманнары диния нәзарәте рәисе:

– Бу бәйрәм Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең күпьеллык намуслы патриотик эшчәнлегеннән башка уза алмас иде. Мин аның сүзләрен искә төшерәсем килә: «Болгар һәм Зөянең яңадан торгызылган тарихи һәйкәлләре һәр заман өчен кешеләрне рухи җәлеп итү үзәгенә әйләнергә тиеш. Безнең игелекле уртак хезмәтебез замандашларыбыз һәм киләчәк буыннар тарафыннан лаеклы бәяләнәчәк. Без тотынганбыз икән, уңыш килер, иншаллаһ. Мин моңа ышанам, без булдырабыз…» Берничә көн дәвамында иксез-чиксез сөекле ватаныбызның үзәгендә мөһим вакыйгалар – KazanSummit форумы да, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышы да уза. Бу – татарларның, мөселманнарның халыклар арасындагы татулыкны илебездәге иминлекне ныгытуга зур өлеш кертүен раслый. **Дус булмаган илләр исемлегендәге 48 дәүләт арасында бер мөселман иле дә юк...** Бу исә төбәк хакимиятләренең дә, федераль үзәкнең дә төрле дин һәм милләтләргә карата сабыр-түземле сәясәт алып баруы белән бәйле.

Абдуллаһи Шеһу, Нигерия Федератив Республикасының Россиядәге Илчесе:

– Мин Татарстанга KazanSummit 2022 форумында катнашу, шулай ук Идел буе Болгарстанында ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан узачак тантаналарның шаһиты булу өчен килдем. Казан кешеләре белән аралашу бик кызык булды. Мөселман, православие һәм башка конфессия вәкилләренең бер-берсе белән тату яшәвен күрү аеруча шаккатырды. Без әле генә бу диварлар янында күпме кеше гыйбадәт кылганын күрдек. Алар дингә бик җитди карый, ләкин бу аларны таркатмый, ә башкалар белән берләштерә генә. **Безнең өчен бу мәдәнияттән, әлеге бердәмлек һәм шул ук вакытта төрлелектән өйрәнерлек нәрсәләр бар.** Минем Болгарга беренче килүем, әмма бирегә тагын бер әйләнеп кайтырмын, дип өметләнәм.

Ришат хәзрәт Давыдов, Тула шәһәре һәм Тула өлкәсе имамы:

– Минем өчен Болгарга һәр сәфәр – бик көчле хис-кичерешләр ул. Идел, Җәмигъ мәчете, Ак мәчет... **Бу – тарих өчен бик мөһим урын. Минтимер Шәймиев инициативасы белән боларның барысы да яңадан торгызылуына бик сөенәм.** Барысы да кешеләр өчен, халык өчен.

Мөхәммәд Бәшив, волонтер, Көньяк Һиндстан:

– Мин Татарстанга, Казанга һәм Болгарга беренче тапкыр килдем. Һиндстанда мин табиблыкка укыйм. Мин – мөселман. **Биредә кешеләрнең нинди игелекле икәнен күрү күңелле. Бәхет, канәгатьлек мохите тоемлана. Бу исә бик рухландыра.**

Финдия Дәүләтхуҗина, Иркутск өлкәсе Чун районының Чун мөселман җәмгыяте рәисе:

– «Изге Болгар җыены»на беренче тапкыр гына килүем түгел, ләкин бу сәфәр һәрвакыт көчле хис-кичерешләр калдыра. Бәйрәм елдан-ел киңрәк колач ала. **Болгар мине һәрвакыт энергия белән баета, мин аның ата-бабаларыбыз җире икәнлеген, кече һәм зур ватаныбызның бөеклеген тоям.** Бу юлы мин ярдәм сорап та килдем. Безнең җәмгыять әле күптән түгел генә оешты, анда 12 генә кеше. Быел Рамазан ае дәвамында без беренче тапкыр тәравих намазын укыдык, тик әлегә – вакытлы мәчет бинасында гына. Хәзер без даими бина төзибез. Бу игелекле эшебездә безгә ярдәм кирәк. Татарстандагы Бөтендөнья татар конгрессы безне татарча китап һәм дини әдәбият белән тәэмин итә. Барлык планнарыбыз да тормышка ашыр, дип өметләнәм.

Нурлан Кайрбеков, Казахстан мөселманнары Диния нәзарәте делегаты:

– Без монда бик күп башка дин вәкилләрен күрәбез. Бу исә халыклар дуслыгы һәм татулыгы турында сөйли. Без монда булуыбызга һәм әлеге олуг вакыйгага үз өлешебезне кертүебезгә шат. Әлбәттә, бу зур әһәмияткә ия, изге урын. Мәдәният, тарих, дин – дәүләтнең бөтенлеген тәэмин иткән мөһим өлешләр. **Болгарны торгызу – киләчәктә яңа җимешләр бирәчәк бик зур эш ул.**

Руслан Бисенгалиев, Саратов шәһәре:

– 2000 елда мин Россиядә ислам динен кабул итү тарихы турында диплом яздым. Һәм менә, егерме елдан соң, миңа дусларым белән бергә монда килү насыйп булды. **Бүгенге вакыйганы мин Россия һәм ислам дөньясы мөнәсәбәтләре үсешенең яңа чоры буларак кабул итәм.** Без монда Беларусь, Казахстан, Кыргызстан һәм башка илләрдән вә төбәкләрдән килгән кунакларны очраттык. Һава торышы бүген салкын, әмма күңелебездә кичергән хисләр безне җылыта.

Ренат Калиев, РФндә «KazakhExport» ЭИК» АҖнең чит ил вәкиле:

– Бу дөньяда дин-имансыз яшәп булмый. 1100 ел элек ислам кабул иткән Идел буе Болгарстаны рухи мәркәзгә әйләнә һәм бүген дә күпләрне җәлеп итә торган үзәк булып кала бирә. Тантаналарда катнашу өчен, бик күп кунаклар килгән. Бу мәдәни, икътисадый, дипломатик элементләр үсешен көчәйтеп җибәрә. **Әлеге җирләр чәчәк атсын, кешеләргә монда бары игелекләр генә насыйп булсын.**

Милена, 6 яшь, Пенза өлкәсе:

– Без музейларга йөрдек һәм иске корылмаларны карадык. **Миңа монда барысы да ошады.** Бигрәк тә Ак мәчет. Ул бик матур.

ЯҢАРЫШ НИЧЕК БАШЛАНДЫ...

2010 елның июль санынннан башлап, «Татарстан» журналында «Яңарыш: ихлас күңелдән» рубрикасы пәйда булды. Аны ТР Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш – Возрождение» фондының Химаячеләр советы рәисе Минтимер Шәймиев алып барды. «Монда без Татарстандагы ике тарихи җәүһәр – Изге Болгарны һәм Зөя утрау-шәһәрен торгызуга бәйле барлык эшләр турында сөйләячәкбез», – ди ул чакта рубрика авторы. Урамда 2022 ел. Яңарыш кичергән Болгарда исламны кабул итүнең 1100 еллыгын бик зурлап билгеләп үттеләр. Ә «Татарстан» журналының 12 ел элек яңарышның ничек һәм кемнәр тырышлыгы белән башлануын искә төшерү мөмкинлеге бар.

922-2022

: сәясәт : яңарыш

БЕЗНЕҢ МОНДА ДА ҺӘР ҖӘҺӘТТӘН АЛДА БУЛУЫБЫЗГА ШИГЕМ ЮК!



Минтимер ШӘЙМИЕВ
тексты

Татарстан Президенты вазыйфасыннан киткәч, тарихи һәйкәлләрне – борынгы Шәһри Болгарны һәм Свияжск утрау-шәһәрчеген кабат тергезүгә ни сәбәпле алынуым хакында миннән еш сорыйлар. Чөнки без шундый хәерле эшкә тотыну өчен өлгереп җиттек, димәк, аның үз сәгате сукты. Республикабыз территориясендәге тарихи һәйкәлләрне саклау һәм реставрацияләүгә, кыюлык белән зурдан кубып, бердәм рәвештә тотынуыбыз – халкыбызның, гомумән алганда, Татарстан җәмәгатьчелегенең рухи өлгергәнлеген раслаучы ачык мисал ул. Бу эш-гамәлебез җиңеллек белән барамы? Әйтә алам: бер дә җиңел түгел. Чөнки үз-үзеңне җиңү беркайчан да җиңел була алмый. Әмма безнең иганәчелек өлкәсендә бәһаләп бетермәслек зур байлыгыбыз – якты хисләребез һәм изге эшләребез бар. Соңгы елларда башкарган игелекле эшләребез яхшылык итүдән һәркайсыбызның күңелләре яктыра төшүен, рухыбызның чистара һәм әхлагыбызның сафлана баруын сиземләргә мөмкинлек бирде.

Шунысы сөенечле: омтылышларыбыз Президент, республика Хөкүмәте тарафыннан кайнар яклау тапты, алар конкрет карарлар белән беркетелә бара. Без республикадан читтә дә теләктәшлек таптык, беренче чиратта, РФ Президенты һәм Премьер-министры тарафыннан.

Бүгенге көндә нәрсәгә ирештек һәм алдагы көннәрдә ниләр башкарырга тиешбез?

Бүгенгә Болгарда да, Свияжскида да коммуникация чаралары юк дәрәҗәсендә. Шунлыктан, кичектергесез һәм беренче чиратта башкарыласы эшләргә юллар салу, елга вокзаллары төзү, газ, җылылык, чистарту җайланмалары булган канализация челтәрләрен үткәрү, өзлексез рәвештә эшләүче энергия чыганаклары белән тәэмин итүләр кирә. Музей зонасына кергән, шулай ук

34 татарстан / июль / 2010

тузган муниципаль йортларда яшәүчеләрне күчерү өчен, торак та төзергә кирәк.

Реставрацияләнүгә һәм консервацияләнүгә тәгаенләнгән объектларда киң масштаблы төзү-төзекләндерү эшләре башлана. Моның өстенә, күпкырлы максатларны берьюлы күздә тотып эш итәргә туры килә: бик зур күләмдә казу-тикшеренү эшләре алып барырга, проект-смета документацияләре әзерләргә, бүгенге көндә реставрацияләнүче объектларда эшне дәвам итәргә һәм яңаларын моңа әзерләүне фәнни эшчәнлек белән бәйләп алып барырга.

Бүгенге көндә Болгарда һәм Свияжскида аерым, иң күп хезмәт сорый торган тарихи һәйкәлләрне торгызуны һәм инженерлык челтәрләрен сузуны үз өстенә алырга теләк белдергән эре инвесторлар белән килешүләр төзи алдык. Иганәчеләрнең һәркайсына аерым объектлар беркетелгән беренче исемлеге кулыбызда.

Болгарда, истәлекле билге итеп, таш куелды. Ул биек яр өстендә, ерактан ук кунакларны сәламләп торачак.

Болгарда яңа мәчет тә сафка басачак. Аны проектлауны Кол Шәриф мәчете проекты авторлары Сергей Шәкүров һәм Искәндәр Сәйфуллинга йөкләдек. Әлеге мәчет бирелә төзеләчәк «Болгар» мәдрәсәсе үзәгендә урнашачак. Мәдрәсә үзе исә берьюлы 30 лап шәкерткә гыйлем бирә ала торган иркен һәм уңайлы үзәк булыр. Анда руханилар хәзерләп чыгару өчен бик уңайлы шартлар тудырылачак. Бирелә алган гыйлемнең һәм дипломның аерым бер югары дәрәҗәгә ия булачагына шигем юк. Бөек фәлсәфәчеләр кебек, җәмгыятьтән беркадәр аерымланган шартларда гыйлем эстәгән шәкертләрнең бирелә алган белемнәре ныклы буласына иманым камил. Бәлки әле киләчәктә әлеге уку йорты Россия ислам институтының филиалына әверелер. Еллар узу белән, минем уйлавымча, бирелә шәйхел-ислам резиденциясе яки мөфти хәзрәтнең илебезнең руханилары белән рәсми очрашулар уздыру һәм кунаклар кабул итү өчен затлы урыны булыр. Мәдрәсәне сафка бастыруда илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче ватандашларыбыз катнашыр дип өметләнәбез.

Без әле Болгарда Икмәк музее төзүне дә күздә тотабыз, ул тирә-юньгә ямь биреп, туристларны үзенә тартып торачак. Ул аерым бер мәгънәгә ия. Идел Болгарстанында яшәгән борынгы бабаларыбыз нигездә утрак тормыш рәвеше алып барган, игенчелек, сатуалу, һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Икмәк музеен төзү эшен авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, республиканың Премьер-министры урынбасары Марат Әхмәтов һәм агросәнәгать комплексына кергән 20 предприятие үз өстенә алды.

Әле бу арада гына өр-яңа идея туды. Шулай берчакны, Миркасыйм Госманов белән Иранга рәсми визитыбыз вакытында, Президент Мөхәммәд Хатами белән үзара сөйләшүләр алып барганда, бөек дәвачыларның 20 трактаты белән танышу мөмкинлеге мәсьәләсен кузгаткан идек. Алар арасында Болгар табибы, дәвачысы һәм галиме Таҗетдин әл-Болгариның трактаты да килеп чыгуы безнең гаҗәпләнү катыш соклануыбызга сәбәпче булды. Күз алдына китерәсезме, нинди дан китерә бит бу безгә: Көнчыгышның бөек дәвачылары арасында, Әбүгалисина белән беррәттән, 20 трактат авторларының берсе булып, үзебезнең Болгар дәвачысы торсын әле! Безгә ул чакта әлеге документларның күчермәләрен алырга рөхсәт иттеләр. Шундый гаҗәеп мирасыбыз булгач, минем уйлавымча, киләчәктә Болгарда Таҗетдин әл-Болгари исемендәге Дәва йорты да төзеп куярбыз әле.

Мөхтәрәм Минтимер Шарипович!

«ТРда тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фонды» оешу хакындагы куанычлы яңа хәбәрне искиткеч зур канәгатьлек хисе һәм шатлык белән кабул иттем. Бүгенге Россия язмышы өчен безнең уртак мәдәни мирасыбызны саклап калу һәм дөрес итеп шәрехләүдән дә әһәмиятлерәк нәрсә юктыр. Чөнки мин шуны анык беләм: мәдәни мирас һәм тарих гавәмне берләштерә дә, кешеләрне бер-берсеннән аерып та куя ала. Ә бусы күп очракта игелекле нияттән һәм яхшы күңелле кешеләрдән тора.

Татарстанның соңгы дистә еллардагы тарихы – төрле халыкларның мәдәнияте, рухи мирасы һәм конфессияләр турында ихластан кайгыртучанлык күрсәтүнең искиткеч гүзәл мисалы ул. Болгар һәм Свияжск үзләре үк көннән-көн катлаулы сәяси үткәне булган төрле мәдәниятләрне үрелдереп үстерүнең һәм моңа дөрес караш тудыруның символларына әверелә бара. Мин шуңа ышанам: Сезнең җитәкчелегегездәге «ТРда тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фонды», нигездә, Россия мәдәниятенең үсеш юлларын билгеләр һәм аның яңа үзенчәлекле сыйфатларына юл ачар.

Дәүләт Эрмитажы һәм Россиянең барлык музейлары Фонд белән күпкырлы хезмәттәшлек итәргә әзер, барыбыз да аңа бик зур өметләр баглыйбыз. Шәхсән Сезнең үзегезгә һәм хезмәттәшләрегезгә әлеге ифрат та игелекле эшегездә уңышлар телибез.

Михаил ПИОТРОВСКИЙ,
Дәүләт Эрмитажы директоры, РФ Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы рәисе урынбасары, Россиянең Музейлар берлеге президенты.

Болгарда һәм Свияжскида елга вокзаллары төзелә башлады инде. Ә алардагы реставрацияләү эшләре бик озакка сузылачак. Әлеге катлаулы һәм күп чыгымнар таләп итә торган хезмәтне «Яңарыш» фонды белән, иңне-иңгә куеп, ТР Мәдәният министрлыгы да башкара. Барлык тарихи объектларны да ныклы нигезгә бастырмыйча, дымланудан изоляцияләмичә торып, бернинди дә реставрацияләү эшләре алып барырга ярамый. Юкса, бу юкны бушка аударуга акча исраф итү булыр иде.

Болгарда һәм Свияжскида яңа торак төзүгә бәйле барлык мәсьәләләр хакында республика Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТР Премьер-министры Илдар Халиков белән уртага салып фикер алыштык. Болгардагы Иске шәһәрлек янындагы кайбер йортларны күчерергә туры киләчәк, чөнки андагы изге җирләр манзарасы ап-ачык булып күренергә, күзне иркәләп торырга тиеш. Бүгенге көндә бу эш башланды да инде, аны гамәлгә ашыруга ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды җәлеп ителде.

Изге ядкәрләрне торгызу эшенә кушылган дистәләгән кешеләргә һәм оешмаларга мин рәхмәтлемен. Алар турындагы язмалар «Татарстан» журналы битләрендә «Чын күңелдән — изге эшләргә» рубрикасы астындагы сәхифәләрдә даими рәвештә дөнья күрер дип уйлыйм.

Шундый киң масштаблы проект белән илебезнең тарихи-архитектура һәйкәлләрен кабаттан торгызуга керешеп, без бөтен Россия җәмәгатьчелегенә игелекле эшкә керешергә этәргеч бирдек. Берничә ел үтүгә, мондый хәрәкәтнең бөтен ил буенча таралуының шаһиты булырбыз әле, мөгаен. Россиядә бөтенләйгә юкка чыкканчы кабаттан торгызыласы ядкәрләр шактый күп. Мин, әлеге изге эштә дә без башкалардан бер адымга алданрак барабыз, дип уйлыйм.

35

БОЛГАР

бүген һәм иртәгә

Елга вокзалы. Фонтан.



Елга вокзалы. Причал.

Исламны кабул итү хөрмәтенә Истәлек билгесе.



Елга вокзалы. Гомуми күренеш.

Кара пулат. XIV гасыр.



Елга вокзалы. Музей экспозициясе.

Палаталы лагерь.


6
Төньяк мавзолей. XIV гасыр.
Зур манаралы
Җәмигъ мәчете.
XIII–XIV гасырлар.
Успение Изге Ана чиркәве.
1732–1734 еллар.
Көнчыгыш мавзолей. XIV гасыр.
(Изге Николай чиркәве).
9
Көнчыгыш пулат. XIV гасыр.
8
Кече манара. XIV гасыр.
Хан төрбәсе. XIV гасыр.
4
Көньяк капка.
5
Икмәк музее.

61

ИЗГЕ УРЫННАРНЫ САКЛАУ: ТАТАРСТАН ТӘҖРИБӘСЕ

922-2022

Татарстанның тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен торгызу республика фонды кылган гамәлләр

Болгарда һәм Зөядә **62дән АРТЫК ТАРИХИ ОБЪЕКТ** саклап калынды һәм реставрацияләнде.

Болгарда моңарчы күрелмәгән күләмдә археологик казу эшләре алып барылды һәм X–XI гасырлар ислам мәдәнияте ядкәрләре реставрацияләнде.

Зөядә XVI–XVII гасырлар православие мәдәнияте ядкәрләре реставрацияләнде. Барлык реставрация эшләре ЮНЕСКО таләпләренә җавап бирерлек итеп башкарылды.

Болгардагы тарихи урыннар исемлеген **ИСЛАМНЫ КАБУЛ ИТҮ ХӨРМӘТЕНӘ ИСТӘЛЕК БИЛГЕСЕ** баетты.

Фото: Александр Ефремов, kazantravel.ru, tatarstan.ru, Ната Смирнова

Болгарда тарихи шәһәрлектән читтә мөселманнарның саф нияте символы буларак **АК МӘЧЕТ** калкып чыкты.

БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ МУЗЕЕ

ачылды.

Аның архитектурасы, эчтәлеге, артефактларга һәм заманча күрсәтү формаларына байлыгы Болгарга гаять күп туристларны җәлеп итә.

АГАЧ АРХЕОЛОГИЯСЕ МУЗЕЕ

Зөянең аеруча горурлыгына әйләнде. Россиядә башка мондый музей юк, дөньяда исә нибары икәү.

Болгарда һәм Зөядә уңайлы **ЕЛГА ВОКЗАЛЛАРЫ** төзелде.

ТАРИХИ ЯР БУЙЛАРЫ төзекләндерелде.

Су төбе тирәнәйтелде, яр буйлары ныгытылды – хәзер биредә дүрт палубалы теплоходлар туктый ала.

БОЛГАР ИСЛАМ АКАДЕМИЯСЕ төзелде.

КАЗАН ИЗГЕ МӘРЬЯМ АНА ИКОНАСЫ СОБОРЫ

үзенең тарихи кыяфәтендә яңадан төзелде.

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ, ТР ДӘҮЛӘТ КИҢӘШЧЕСЕ: «ҺИЧШИКСЕЗ, ИСЛАМНЫ КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫН ДӘҮЛӘТ ДӘРӘҖӘСЕНДӘ БИЛГЕЛӘП ҮТҮ ТУРЫНДА КАРАРНЫ КАБУЛ ИТҮ БӨТЕН ХАЛЫК ДӘРРӘҮ КУБЫП БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕН ЯҢАРТКАННАН СОҢ МӨМКИН БУЛДЫ».

Фото: Ибн Фадлан илчелеге Идел буе Болгарстаны ханы Алмыш янында. Булат Гыйльванов (islamonline.ru) картинасы фрагменты.

БЕЗГӘ КИЛЕП ҖИТКӘН ИМАН НУРЫ

Искәндәр Измайлов, тарих фәннәре докторы

1100 ел элек Көнчыгыш Европада хәзерге татарларның борынгы бабаларын ислам цивилизациясенә юнәлткән бер вакыйгага була. Бу турыда мәгълүмат шунда турыдан-туры катнашкан Багдад хәлифәсе илчелеге сәркатибе Әхмәд ибн Фадлан тасвирламасында безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Шулай булса да, галимнәр әлегә кадәр борынгы чыганакны өйрәнгәндә туган сорауларга җавапларны эзләү белән мәшгуль.

1100 българ

922-2022

Кыскача тарихка тукталмый булмый. Ул 921 елның язында, Багдад хәлифәсе әл-Мөкътәдир сараена ерак төньяк илдән илче – «хәзәр» кушаматлы Габдуллаһ ибне Башту килүдән башлана. Илче хәлифәгә, шулай ук сарайдагы хәрәм сакчысы Нәзир әл-Хәрәми һәм вәзир Хәмид ибне әл-Габбаска Болгар ханыннан хатлар китерә.

Багдадка илче җибәрү мөмкинлеге һәм хәтта зарурлыгы сәүдә юллары булу белән бәйле – алар Бөек ефәк юлының Урта Азиядән Идел буйлап Балтыйк диңгезенә кадәр булган арасын үз эченә ала. IX гасырда сәүдә гөрләп үсә – Шәрык товарларыннан тыш, аның буйлап төньяк илләрнең товарлары да агыла башлый. Идел буен Урта Азия белән бәйләгән икенче мөһим сәүдә артериясе – Хәрәземдә башланып, Үст-Урт коры яссы тау сыртлары аша үтеп, Җаек (Урал) елгасының урта агымын кичеп чыгып, Идел-Агыйдел субүләре буйлап Болгар шәһәренә барып җиткән кәрван юлы. Бу Бөек ефәк юлының үзенә бертөрле төньяк тармагы була.

ИСЛАМ ТАРАЛУ ЮЛЛАРЫ: СӘҮДӘ ҺӘМ СӘЯСӘТ

Болгар кәрваннар килеп туктый торган урын була, ә товарлар суднолар һәм коры җир буйлап Рус иленә һәм Төньяк Европага юлын дәвам итә. Әлеге сәүдәдә Болгар иле төп роль уйный, ул шәрык илләре

белән Европа арасында чын күпер булып тора. Нәкъ менә дөньякүләм сәүдәдәге уңайлы урыны болгар кабиләләренең утрак тормыш алып баруга күчүен тизләтә. Халыкара сәүдәдән кергән байлык, камырга эләккән чүпрә кебек, куәтле социаль кузгалышларга сәбәп булган һәм дәүләт барлыкка китергән, дип тә әйтеп буладыр.

Башта болгар кабиләләре Хәзәр каһанлыгына буйсындырыла һәм ясак түләргә, идарәчеләре исә балаларын каһаннарга тотык итеп бирергә мәҗбүр ителә. Әмма X гасыр башына икътисадый куәт һәм сәяси консолидация нәтиҗәсендә аеруча көчле өч кабилә – болгар, барсил һәм искилләр берләшә. Алар хәзәрләр хакимлегеннән котылыр өчен көрәш башлый.

Ислам әлеге көрәшнең байрагына һәм идеологиясенә әйләнә. Эш шунда ки, мәҗүсилекнең төрле кабиләләр өчен берләштергеч көчкә әйләнергә хәленнән килми. Ул борын-борын заманда әйләнәтирә дөньяны рухи аңлау чарасы буларак барлыкка килә, мифологиянең нигезен тәшкил итә һәм кабиләнең эчке тормышын көйли. Алар һәр җәмгыять өчен үзгә була, шунлыктан дәүләтнең этносларга бүленмәгән мәдәнияте формалашу шартларында кабиләләрне берләштерү өчен бөтенләй яраксызга чыга. Моннан тыш, мәҗүсилек хәзәрләрнең иудаизмына берничек тә каршы тора алмый.

Мөселманлык Урта Идел буена шактый иртә, сәүдәгәрләрнең тәүге кәрваннары белән бергә үтеп керә башлый. Урта Азия һәм Болгариядән чыккан көчле мөселман общиналары булу исламның җиңәчәгенә алдан ук өметләнү мөмкинлеген бирә. Әлеге факт хәтта болгарларның рәсми историографик традициясендә дә чагылыш тапкан. Аның Андалусиядән (Испания) килгән гарәп сәүдәгәре һәм дипломаты Әбү Хәмид әл-Гарнати хезмәтендә сакланган иң борынгы вариантында болгарларның ислам динен әмирләрен «Бохарадан килгән бер фәкыйһ» дәвалаганнан соң кабул итүе тасвирлана. Шуннан соң Болгарның бар халкы исламга күчә һәм нәкъ менә шуңа күрә сугышта хәзәр каһаны гаскәрен җиңә.

XVIII–XIX гасырларда язып алынып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән икенче бер фаразда әлеге сюжет тәфсилләбрәк сурәтләнә һәм Болгарстанда ислам дине таралуын Мөхәммәд Пәйгамбәрнең өч сәхабәсе белән бәйли. Янәсе, аларның берсе хан кызын төзәлмәс чирдән дәвалый һәм, аңа өйләнеп, яңа ислам династиясенә нигез сала. Тарихи чынбарлыкка моның бер катнашы да юк. Әмма риваятьтә хакыйкать бөртеге шулай да бар. Асылда, бу риваятьне Болгардагы урта гасыр тарихчыларының үзләренең хак дингә килү тамырларын «борынгылату» һәм ил халкында үзләренең күрше халыклардан өстенрәк булу хисен ныгыту омтылышы дип бәяләргә була – болгарлардан кала аларның берсе дә Пәйгамбәр сәхабәләре белән кардәшлеккә дәгъва кыла алмый бит.

Күрүебезчә, бер генә рәсми болгар традициясе дә яңа динне кабул итүгә бәйле рәвештә Багдад хәлифәләрен искә алмый. Һәм бу очраклы түгел. Идел буена исламның кайдан килүен һәм болгарлар өчен нинди дини элемтәләрнең гасырлар дәвамында актуаль булып калуын болгарлар үзләре бик ачык һәм төгәл күрсәтә – Урта Азия һәм Бохарадан. Дин тәгълиматы ягыннан караганда бу бик мөһим роль уйный. Эш шунда ки, Урта Азиядә, бигрәк тә Саманидлар сараенда, исламның Хәнәфи (Әбү Хәнифә) мәзһәбе аеруча киң таралган була, Багдадта исә Шәфигый һәм Хәнбәли мәзһәпләренә таяналар. Ибн Фадланның болгарлар динендәге кайбер «хаталарны» сурәтләве буенча (хөтбә уку үзенчәлекләре, икеләтә камәт төшерү, хәлифә исемен телгә алмау һ.б.) аларның нәкъ менә Әбү Хәнифә мәзһәбенә каравы турында нәтиҗә ясап була. Болар барысы да болгарларның дин сайлаганда Урта Азиядәге ислам үзәгенә өстенлек бирүен дәлилли.

ТӨНЬЯК ОЙКУМЕНА КОТКЫСЫ: АЕК НИЯТ ҺӘМ ДИПЛОМАТИЯ УЕНЫ

Ислам кайчан кабул ителгән соң? Шактый факт буенча, Багдад хәлифәсе белән мөнәсәбәтләрне җайлауга керешкән Алмыш ханның этисе инде мөселман булган. Алмыш илтәбәр үзе дә, аның иң якын көрәштәшләре (мәсәлән, шул ук Габдуллаһ ибне Башту һ.б.) һәм халкының бер өлеше дә (мәсәлән, бәрәнҗәрләрнең хәтта үзләренең агач мәчете дә булган) ислам динен тоткан.

Болар барысы да Урта Идел буенда исламның инде IX гасырда ук тарала башлавын дәлилли, һәм әлеге процесс сәүдә активлыгының кинәт артуы, утрак тормышка күчү, X гасыр башында болгарларда беренче дәүләтчелек пәйда булу вакытына туры килә. X гасыр башында күренекле фарсы галиме, сәяхәтче Ибне Рустә, «Болгарларның Алмыш исемле ханы ислам динен тота», «Болгарларның күпчелеге ислам динендә, авылларында имамлы, мәзинле мәчетләре һәм башлангыч мәдрәсәләре бар», дип язып калдырган.

Әмма Саманидлар дәүләте белән мөнәсәбәтләре шундый нык булган болгар ханы ни өчен илчелекне нәкъ менә Багдадка җибәргән соң? Күрәмсең, Болгарстан хакиме ничек тә хәзәр каһанына бәйлелектән

Алмыш илтәбәр.

котылырга ниятләгәндер. Әлеге ирексезлек ясак түләүдә дә, Алмышның кызларын каһанга көчләп кияүгә бирүдә дә, хәтта Алмыш йөрткән титулда да чагыла.

Борынгы төркиләрнең «илтәбәр» титулын каһанга буйсынган вассал хакимнәр йөрткән. Моны үзгәртү таләп ителгән. Әмма Хәзәр иленә каршы сугыш ачар өчен Алмышның көче җитәрлек булмаган. Союздашлар эзләү зарурлыгы туган. Саманидлар моңа берничә сәбәп буенча ярамаган: алар гомумән Европа сәясәтенә бик сирәк тыкшынган, чөнки мәнфәгатьләре Хорасанда тупланган булган, моннан тыш, аларның үз империясе бетүгә-таркалуга йөз тоткан, һәм X гасыр уртасында таркалган да.

Һәм менә шул вакытта күптәнге сәүдә һәм этник элемтәләр ярдәмгә килгән. Болгарлар Багдад мөселманнарының хәзәрләрнең иң явыз дошманы булуын яхшы белгән. Димәк, Алмыш Багдад ярдәменә өметләнә алган.

Ибн Фадлан «сәкалиб (гарәпләр төньяк илләренең утрак тормыш алып баручы халкын шулай атаган) мәлиге» дип атаган Алмыш хан үзенең хатында хәлифәдән «үзен иманга китерерлек, шәригать кануннарын өйрәтерлек кешеләр җибәрүен, аңа мәчет төзеп бирүләрен» үтенгән һәм «шундагы мөнбәрдән вәгазь сөйләп, ил халкын ислам диненә өндәргә» җыенуын хәбәр иткән. Һәм ул тагын бер нәрсәдә – «үзенә дошман патшалардан кереп качарлык ныгытма төзеп бирүдә» ярдәмгә мохтаҗ булуына бигрәк тә басым ясаган.

Әлбәттә, бу хатлар белән хәлифә янына шундук барып керү турында хыяллану да мөмкин булмаган. Әмма илче сарайда үзләрен хәлифә янына кертерлек һәм аңа хатларны тапшыру мөмкинлеген бирерлек ышанычлы кеше тапкан. Бу төрки Тәгин булып чыккан, хәлифәгә хезмәткә алынганчы ул Хәрәземдә тимер сату белән шөгыльләнгән һәм хәтта кайчандыр Болгарстанда яшәгән дә. Хәлифә гвардиясендә Тәгин шактый югары урында саналган.

Төрки гвардия вәкиле Тәкин, хәрәм сакчысы Нәзир әл-Хәрәми, шулай ук хәлифәнең үзе катнашындагы катлаулы дипломатия уены нәтиҗәсендә хатка җавап итеп төньякка илчелек җибәрергә һәм болгарлар белән килешү төзергә карар кылына. Хәлифәне һәм аның вәзирләрен мондый абсурд планга керешергә нәрсә мәҗбүр итүен әйтүе кыен. Бер яктан, күрәмсең, болгарларның көче һәм куәте турында чынбарлыкка туры килмәгән күзаллаулардыр – Ибн Фадлан сүзләре белән әйткәндә, Тәгин һәм аның төрки тарафдарлары «күзгә төтен җибәрергә яраткан». Икенче яктан – Багдадны ислам илләре үзәге, Пәйгамбәр идеяләрен цивилизацияле дөньяның яртысына тараткан данлыклы әлгәрләре варисы дип санау омтылышы. Моннан тыш, мөгаен, үзләренең күптәнге дошманнары хәзәрләр тылында сәяси диверсия оештыру теләге дә зур булгандыр, чөнки алар узындырган төньяк викинглар – «руслар» Хәлифәтнең Каспийдагы провинцияләренә әледән-әле яу чабып торган.

Ихтимал, барысы да – Болгар илтәбәре Алмыш та, хәлифә дә, Тәгин дә – әлеге гамәлнең сәяси файдасын арттырып күзаллагандыр. Шунлыктан, аның белән бәйле өметләр юкка чыккач, бу шактый тиз арада онытылган да.

Әмма әле илчелекне җибәрергә генә җыенган чакта бөтен сәяси көчләр анда үз урынын ныгытырга тырышкан. Төрле интригалар һәм лоббизм нәтиҗәсендә илчелек җитәкчесе итеп хәрәм агасы Сусан әл-Расси – хәлифә сараенда урнашу өчен үз патронына хыянәт иткән һәм Нәзирнең мәүләсенә әйләнгән кеше билгеләнә. Үз хуҗасына җаны-тәне белән бирелгән булганга, ул аның теләсә нинди карарына да ризалаша. Илчелек составына тагын Тәгин һәм Барс (ул да сугышчы, Сәклаб кушаматлы болгар), шулай ук берничә сакчы һәм хезмәтче, мөселман хокукы белгечләре һәм дин мөгаллимнәре керә. Сәркатиб сыйфатында укымышлы, тирән белемле, сөйләшүләр үткәрү тәҗрибәсе булган кеше – Әхмәд ибн Фадлан кертелә, ул бөтен дипломатия эше белән җитәкчелек итәргә тиеш була.

ҖИР ЧИТЕНДӘ: ДИПЛОМАТИЯ УҢЫШСЫЗЛЫГЫ ҺӘМ ИСЛАМ УҢЫШЛАРЫ

Илчелек Алмыш ставкасына җитмеш көнлек авыр юлдан соң 922 елның 12 маенда аяк баса. Инде «өч көн һәм өч төн алдан» илчеләрне болгар ханына буйсынган дүрт мәлик, аның

ага-эне һәм уллары каршы ала. Күрсәтелгән әлеге югары хөрмәт болгарларның Багдад хәлифәсе миссиясенә никадәр әһәмият бирүен дәлилләп тора. Ниһаять, гарәпләр легендар «сәкалиб мәлиге» Алмышны күрү бәхетенә ирешә, алар инде аны ул чакта «Караңгылык диңгезе» дип йөртелгән Төньяк Боз океанына да шактый якын урнашкан ерак җирләрдә эзләп табудан өметен өзә язган була.

Алмыш яшь күренә, көч-куәте ташып тора. Ил аңа әтисеннән мирас булып күчә, тик ул, ислам динен кертеп, аны киңәйтә һәм хакимиятне ныгыта. Әмма әлеге юлда аны шактый кыенлыклар көтә. Шулардан берсе – үз казнасына байлык кертә торган чыганактан аерылырга теләмәгән куәтле Хәзәр иле каршылыгы. Икенчесе – исламны кабул итәргә һәм Алмышка буйсынырга теләмәгән кайбер болгар нәсел һәм кабиләләренең канәгатьсезлеге. Илчелек килгәннән соң булган шундый бер хәлне Ибн Фадлан тасвирлап калдырган. Искилләр берләшмәсенә кергән суарлар кабиләсе Алмышка буйсынудан баш тарта һәм аңа каршы чыга. Монда болгарларның көчәюеннән курыккан хәзәрләр кулы уйнавы сизелә.

Әмма Алмыш илтәбәр яклылар да юк түгел. Җирләреннән Хәрәземгә кәрван юлы үтә торган көнбатыш огузларның бер өлеше болгарларга дустанә мөнәсәбәттә була. Аларның юлбашчысы Әтрәк хәтта үз кызын Алмышка кияүгә дә бирә. Һичшиксез, Алмыш хан – халкын берләштерүдә алдан күреп эш итүче һәм гакыллы дәүләт эшлеклесе, аны Франциядәге Хлодвиг, Рус дәүләтендәге Олег, Британиядәге Артурга тиңләп була.

Илчелекнең килүен ишетүгә үк, илтәбәр актив эшчәнлек җәелдерә. Инде дүртенче көнне үк, ягъни 922 елның 16 маенда, ул бөтен аксөякләрен – кабилә «мәликләрен» һәм «юлбашчыларын» җыя да, Багдад илчелеге килү хөрмәтенә зур тантана оештыра. Ул бу сәбәпне ил халкына үз хакимиятенең хәтта Пәйгамбәр нәселеннән булган куәтле хәлифә тарафыннан да танылуын күрсәтү өчен файдалана. Илчелек сәркатибе аңа бу эштә актив булыша. Ул ханга ислам дине нигезләрен аңлата, Алмышка хакимлек тапшыру тантанасында (бусы белән әл-Расси җитәкчелек итә) катнаша, кирәкле документларны төзеп һәм сөйләшүләр алып барып, илтәбәр чатырында мәҗлесләрдә катнаша. Ибн Фадлан киңәшен тотып, үз хакимиятен хәлифә исеме белән изгеләштергәндә Алмыш хәлифә әл-Мөктәдир исеменә охшаш Җәгъфәр ибне Габдуллаһ исемен ала. Бераз соңрак Җәүшир (хәзерге Кече Чирмешән елгасы булырга тиеш) елгасында болгар кабиләләре җыенында күп кенә вак идарәчеләр һәм кабиләләр Алмыш хакимиятен таный. Калганнарын исә ул бераз вакыттан соң көч белән буйсындыра.

Әмма илчеләрнең болгар ханы белән дустанә мөнәсәбәтләре озакка бармый. Инде бер атнадан соң ук Алмыш хан Ибн Фадланны чакырта һәм бик күп гаеп ташлый. Авторның бу турыда күпкә йомшартып язуын исәпкә алганда да, хакимнең ризасызлыгы яхшы аңлашыла. Илчелекне акчаны «бушка» сарыф итүдә гаепләп, Алмыш хан күнегелгән Хәнәфи мәзһәбе урынына Шәфигый мәзһәбен кабул итүдән баш тарта.

Болгар мәлиге кәефенең кинәт шулай үзгәрүе Хәлифәтнең чын мөмкинлекләрен аңлаганнан соң булгандыр. Әмма, хәлифә илчелеге белән араны өзсә дә, Алмыш хан Ибн Фадлан белән аралашуын дәвам итә. Алар болгар иле, халкының гореф-гадәтләре, күршеләре һәм сәясәте турында озаклап сөйләшеп утыра.

Ибн Фадлан нәкъ менә шул әңгәмәләр вакытында Болгарстан хакында күп мәгълүмат туплый. Моннан тыш, ул әйләнә-тирә җирләрне дә карап йөри, мәсәлән, бәрәнҗәрләрнең агач мәчетен барып күрә. Алар илче күзлегеннән караганда намазны дөрес укымый, шунлыктан ул «бер төркемне Багдадтагы кебек намаз укырга өйрәттем», дип горурланып язып куя.

Әмма бу ахыр чиктә илчелекнең гомуми уңышсызлыгыннан коткармый. Алар Болгарстанда үз мәзһәпләрен тарата алмый, Багдад хәлифәте хакимлеге дә урнаштырылмый.

БОЛГАРСТАН ЧЫННАН ДА ТӨП ИСЛАМ ҮЗӘКЛӘРЕННӘН ШАКТЫЙ ЕРАКТА УРНАШКАН БУЛА, ШӘРЫКТА ӘЙТҮЛӘРЕНЧӘ, КАРАҢГЫЛЫК ДИҢГЕЗЕ ЯРЫНДА, ҖИР ЧИТЕНДӘ ҮК ДИП КҮЗАЛЛАНА.

Алайса, әлеге миссиянең уңышы нидә соң, һәм ни өчен без Багдад хәлифәсе илчелеге килүне татар халкының борынгы бабалары тарихында мөһим вакыйга итеп билгеләп үтәбез? Сүз дә юк, илчелек илдә Алмыш хакимиятенең аннары исә исламның көчәюенә һәм таралуына куәтле этәргеч бирә. Әмма иң мөһиме – Болгарстанның дипломатиядә ислам дәүләте буларак танылуы.

Шул вакыттан бирле бер генә географик хезмәт тә болгарларны телгә алмый калмый. X гасыр азагы – XI гасыр башында Идел Болгарстаны урта гасыр дәүләтенә, классик ислам иленә әйләнә. Барлык рус һәм гарәп-фарсы чыганакларында, шулай ук археология мәгълүматларында X гасыр азагына Болгарстанның ислам киң таралган илгә әйләнүе, халыкара аренада аның Шәрык илләре белән сәүдә, мәдәни һәм сәяси мөнәсәбәтләр урнаштырган мөселман иле буларак кабул ителүе күрсәтелә.

Болгарстан чыннан да төп ислам үзәкләреннән шактый еракта урнашкан була, Шәрыкта әйтүләренчә, Караңгылык диңгезе ярында, җир читендә үк дип күзаллана. Әмма ислам илләреннән Идел Болгарстанына кадәр ара никадәр ерак булса да, ислам дине һәм мәдәнияте Идел буенда шулкадәр җиңел тарала, һәм биредә төрки мөселман мәдәниятенең искиткеч ареалы пәйда була.

«НУРУЛЛА» МӘЧЕТЕ

922-2022

Печән базары, Җиденче Җәмигъ, Базар, Юныс мәчете... – XIX гасыр урталарында Иске Татар бистәсендәге тарихи базарда мәхәллә кешеләре өчен ачылган әлеге мәчет һәр дистә ел саен диярлек исемнәрен үзгәртә. Бүгенге исемен исә безнең заманнарда мәчетне мөселманнарга кайтарып биргәч ала. Нурулла гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә «Аллаһ нуры» дигәнне аңлата.

Печән базарында дистәләгән сәүдә ноктасы тоткан беренче гильдия сәүдәгәре Гобәйдулла Юнысов биредә мәчет төзергә уйлый. «Бервакыт Гобәйдулла базарга чыга. Намаз вакыты. Халык сату-алу белән мәшгуль, намаз вакытына игътибар итми. «Бу шәһәр халкын намазга басарга ничек үгетләргә? – дип уйга кала Гобәйдулла. Шуннан соң ул Базар мәчете өчен урын сатып ала. Әгәр һәркем диндарлыгы турындагы сүзен тотса, бу мәйданда мәчет төзиячәкмен», – дип ант итә ул.*

Сәүдәгәр үзе ниятен тормышка ашырырга өлгерми, аның эшен уллары Исхак белән Ибраһим үти. 1844 елның 18 августында Казан сәүдәгәре Ибраһим Юнысовның ышанычлы вәкиле губерна администрациясенә үтенеч язуы белән мөрәҗәгать итә: «Минем ышанычлым гражданин Ибраһим Юнысов Казан шәһәренең Аркылы-Базар урамы буенча 2 өлештә манара һәм ишегалдында мәчет салырга һәм шул урында балалар приютлары файдасына иганә ителгән лавкаларны үзгәртергә тәкъдим итеп, 4 экземплярда аларның планын һәм фасадын ясады, ышанычлым Юнысов бүген үк тәкъдим ителгән фасадлар буенча лавкаларны яңартырга керешә алсын өчен, шуларны сез Галиҗәнапларга тапшырып үтенечемне җиткерәм...» Гыйбадәтханә 1844 елда ачылган беренче мөселман балалар приюты өчен кирәк – әлеге дәлил хакимияткә үтенечтән баш тартырга мөмкинлек калдырмый.

Мәчет төзелеше җиңел бармый. Нигез чокыры казылганнан соң фундамент астыннан су чыга, аннан берничек тә котыла алмыйлар. Архитекторның чокырның бөтен озынлыгы буенча сал урнаштырырга, ә аңа гранит ташлар утыртырга дигән карары бу хәлдән чыгарга ярдәм иткән, диләр... Тырышлыгы бушка китми: Болгар шәһәренең дини корылмалары элементлары кулланылган мәчет Иске Татар бистәсенең чын бизәгенә әйләнә. «Алгарак чыгарып урнаштырылган манара искиткеч тәэсирләр калдыру белән беррәттән, пространство нисбәтенең нечкә режиссурасын да тудыра. Ул бик сак кына зур базар мәйданын иң түрендә изге михраб урнашкан намаз залыннан бүлеп-аерып тора», – дип яза танылган архитектор Галина Айдарова.

XIX гасырның 70–90 нчы елларында мәчетнең имам-хатыйбы булып танылган композитор Мансур Мозаффаровның әтисе ахун Хуҗиәхмәт Мозаффаров эшли. Хуҗиәхмәт ахуннан соң мәхәлләне күренекле җәмәгать эшлеклесе, җәдидчелек вәкилләренең берсе, Галимҗан Барудиның дәвамчысы Габдулла Апанаев җитәкли. Озак вакытлар Апанаев мәчетне үз акчасына карап тота...

Печән базары мәчете манарасы шәһәрне узган гасырның 20 нче еллары ахырына кадәр бизәп тора. Мәчет Татар Республикасы Үзәк башкарма комитетының 1929 елның 16 ноябрендәге карары белән ябылганнан соң манараны юк итәләр. Совет чорында манарасыз калган бинада торак һәм конторалар эшләгән.

Мәчет дин тотучыларга 1992 елда кайтарыла. Реставрация һәм яңадан торгызуга биш ел вакыт китә. Бүген «Нурулла» мәчете манарасыннан азан яңгырый.

Фото: Әскәр Сабиров

* *Гобәйдулла Юнысов оныгы истәлекләреннән*

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанда яшьләргә **НИЧЕК** акча эшләргә була

НИ ӨЧЕН яшьләр авылны сайлый

Татарстанның эшлекле ханымнары **НӘРСӘ** белән сыйлый

ТР яшьләр эшләре министры **НИНДИ** китаплар укый

Балтач, 2022 ел.
Фото: Александр Ефремов

ТАҢНЫ КАРШЫЛЫЙК ТА ЗУР ТОРМЫШКА АТЛЫЙК!

– Яшьлек нәрсәдән башлана?

– Чыгарылыш кичәсеннән, – дип җавап бирә «Татарстан»га җылы июнь аенда олы тормыш таңын каршылаган төрле елларның чыгарылыш сыйныф укучылары.

Артта – гамьсез балачак. Алда иң күркәм чор – мөстәкыйль тормыш, гүзәл яшьлек көтә. Киләчәккә планнар кору, һөнәр сайлау, үз караш-фикерләрең пәйда булу чоры. Бу могҗизалы вакытта яшьләрне сагалап торган хата-ялгышларга да карамастан, бик гүзәл мизгел ул. Чөнки ул – мәктәпне тәмамлаучыларның һәр буынына мавыктыргыч олы тормышка юл ачучы әлеге таң кебек иң якты, иң матур, иң истәлекле. Питерның унберенче сыйныфларына гына түгел, ә Татарстандагы Балтач яшьләре бәйрәменә йөзеп килгән ал җилкәннәр кебек...

1989, 1993, 2022 елларда Казанда, Яшел Үзәндә һәм Балтачта чыгарылыш сыйныф укучыларын күзәттеләр: Евгений Канаев, Рамил Гали, Александр Ефремов.

Казан ш., 1989 ел.
Фото: Рамил Гали

Казан ш., 1989 ел.
Фото: Рамил Гали

Яшел Үзән ш., 1993 ел.
Фото: Евгений Канаев

НИ ТЕЛИСЕҢ, ШУНЫ ЭШЛӘ!

Татарстанның Яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов яшүсмер чагында ук яшьләр сәясәте белән кызыксына. Әмма беренче акчасын бал биюләренә өйрәтеп эшләп ала. Татарстан яшьләре өчен тудырылган хәзерге мөмкинлекләр булса, карьерасы, мөгаен, тагын да тизрәк үсәр иде.

1

ТАЛАНТЛАР ЛАБОРАТОРИЯСЕ

Татарстанның Талантлар университетында үзләштергән белем-күнекмәләргә югары уку йорты да, мәктәп тә, түгәрәк тә өйрәтмәячәк. Менә инде җиде ел бу мәйданчык сәләтле балаларга һәм яшьләргә хыял-максатларына ирешергә булыша.

Әмирнең пробиркасында желесыман масса. Егет аны лимон бөтнеге (мелисса) күзәнәкләреннән үстергән. Каллус дип аталган менә шундый массадан фармацевтика һәм косметология өчен биологик актив матдәләр алына. Казандагы 33 нче лицейның 9 сыйныф укучысы, шулай ук республиканың Талантлар университеты студенты Әмир Гыйльванов, КФУдагы фәнни җитәкчесе белән берлектә, лимон бөтнегеннән каллусны иң нәтиҗәле ысул ярдәмендә алырга мөмкинлек бирә торган технологияне эшләү белән мәшгуль.

Яшь егет үз проектын гамәлгә ашыра алсын өчен, Университет аңа КФУ белән хезмәттәшлек мөмкинлеген оештырган. Бу – белем бирү мәйданчыгы тарафыннан күрсәтелә торган ярдәм чараларының берсе генә әле.

– Университетка кергәндә, сиңа 100 балл бирелә, бу – 50 мең сум дигән сүз. Аларны төрле конкурсларда һәм белем бирү чараларында катнашу һәм аларда җиңү яулау өчен тотарга була. Әйтик, быел мин, университет җыелма командасы белән бергә, «ТехноСтрелка» халыкара фес-

Фотолар Әмир Гыйльванов һәм Руслан Матуриннан алынды.

2

тиваленә катнаштым. Без анда беренче урын яуладык, – дип сөйли Әмир.

Талантлар университеты – республиканың сәләтле мәктәп укучыларына һәм яшьләргә ярдәм итү өчен белем бирү мәйданчыгы ул. Республика яисә федераль дәрәҗәдәге олимпиадада яки республика конкурсында җиңү яулаган, Татарстанда яшәүче 12 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр Университет студенты булу хокукына ия. Хәзер биредә 2 меңгә якын кеше укый.

Университет студентларының һөнәри үсешенә финанс ярдәме күрсәтү белән генә чикләнми. Биредә укучыга үз проектын эшләү өчен Татарстан югары уку йортларының лабораторияләренә керү мөмкинлеге бирелә, белем алу юнәлешен планлаштыруда остазлар ярдәме күрсәтелә, аларга шулай ук һөнәр сайлауда, фәнни, технологик, иҗади конкурс һәм олимпиадаларга әзерлек барышында булышалар. Күптән түгел Университет Казанда үз лабораториясен ачты. Мәйданчык тулы кыйммәтле фәнни эш өчен кирәкле бөтен нәрсә белән җиһазландырылган. Болар барысы да сәләтле балаларга бик тиз арада үз сәләтләрен мөмкин кадәр күбрәк үстерергә, киләчәкне күздә тоткан эшчәнлек өлкәсен сайларга ярдәм итә. Ә кемдер, моннан тыш, үзе өчен яңа кызыксыну офыкларын ача.

ДӨНЬЯНЫ ҮЗГӘРТӘЧӘК МАТЕРИАЛЛАР

– Университетта шөгыльләнгән проектымны «Эшмәкәрлек фабрикасы»нда күрсәттем. Бу минем өчен бик кызыклы тәҗрибә булды. Элек мин киләчәк өчен биология яки программалаштыруга бәйле һөнәрләрне карый идем, әмма хәзер эшмәкәрлек юнәлешендә белем алу турында да уйлана башладым, – ди Майя Костюкова. Хәзер әле ул Казанның 86 нчы мәктәбенең тугызынчы сыйныфында укый.

Университетта Майя шөгыльләнә торган проект – кузаклы үсемлекләрдән алына торган, шактый аз өйрәнелгән уникаль аксым – форисомны тикшерү. Форисомнарда иң кызыгы – аларның тышкы шартларга карап, формасын кире кайтырлык итеп үзгәртү сәләте. Шуңа күрә аны «акыллы» материаллар исәбенә кертеп карыйлар һәм аэрокосмик сәнәгать һәм авиатөзелеш тармагы, электроника һәм медицина өчен бик өметле чимал дип саныйлар.

– Бу Университет тормышта үсәргә теләүчеләр өчен күп нәрсә бирә. Шул ук вакытта тәртипкә дә өйрәтә. Һәр студентның шәхси үсеш планы бар, монда аның максатлары күрсәтелгән – кыска вакытлы (1 елга кадәр – ред. иск.), уртача вакытлы (2–3 ел – ред. иск.), озак вакытлы (5–7 ел – ред. иск.) Нәкъ менә шушы план миңа нәрсә эшләргә һәм нинди нәтиҗә алырга теләвемне аңлауда ярдәм итте, – ди Майя.

ЛИДЕР ӨЧЕН ОСТАЗ

«Яшьләр эшләре буенча министр булырга» – Чаллыдагы «Шатлык» яшьләр үзәге җитәкчесе, 24 яшьлек Руслан Матурин үзенең шәхси үсеш планында әнә шундый стратегик максат куйган. Талантлар университетында уку тәкъдиме аңа «Ел лидеры» конкурсының республика этабында җиңгәннән соң ясала. Университет Руслан өчен республиканың эре предприятиеләренең берсендә стажировка узу мөмкинлеге тудыра, анда яшь егет шәһәр Советы депутаты ярдәмчесе ролендә «Алабуга инициативасы» социаль проектында катнаша. Стажировка Русланның һөнәри тәҗрибә сандыгына нәтиҗәле элемтәләр, файдалы танышлыклар өсти. Май аенда «Эссен Продакшн» «Шатлык» үзәгенә ветераннар өчен шәхси котлау акциясе үткәрергә дә булышкан.

– Минем өчен Университетта иң мөһиме – остазым, профессиональ коучым. Үзенең профессиональ һәм шәхси тәҗрибәсеннән файдаланып, ул миңа юнәлешне дөрес билгеләргә, иң мөһим нәрсәгә игътибар тупларга, нәтиҗәгә ирешү өчен ресурслар таба белергә ярдәм итә, – ди Руслан. – Моннан тыш, Университет миңа кирәкле өстәмә белемне бушлай алу мөмкинлеге бирә. Мәсәлән, шул рәвешле инглиз телен өйрәнүемә юл ачылды. Моңа әле бик күп файдалы элемтә, чара һәм материалларны да өстәгез. Университет – чын-чынлап искиткеч үсеш коралы ул.

ТАЛАНТЛАР УНИВЕРСИТЕТЫ СТУДЕНТЫ БУЛЫРГА ТЕЛИСЕҢМЕ? UTALENTS.RU САЙТЫНДА ГАРИЗА КАЛДЫР.

1 Татарстан Республикасының яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов (сулда) Чаллының «Шатлык» яшьләр үзәгендә.

2 Казандагы 33 нче лицейның 9 нчы сыйныф укучысы Әмир Гыйльванов лимон бөтнегеннән каллусны иң нәтиҗәле ысулларның берсе белән алырга мөмкинлек бирә торган технологияне эшли.

3 «Яшьләр эшләре буенча министр булырга» – Чаллыдагы «Шатлык» яшьләр үзәге җитәкчесе, 24 яшьлек Руслан Матурин үзенең шәхси үсеш планында әнә шундый стратегик максат куйган.

3

МАХСУС БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ОТРЯД

Карьера ясау, аралашу һәм сәяхәт кылу – әлеге ингредиентлардан ясалган коктейль «студентлар отряды» дип атала.

Адреналин Динарны һәм тагын аның йөзгә якын иптәшен ташлы калкулык түбәсенә таба куа. Бер биеклек, тагын берсе һәм, ниһаять, менә ул тау түбәсе. Биредән иксез-чиксез тоелган ылыслы диңгез һәм еракта җәйрәп яткан күл өстенең гаҗәеп матур манзарасы ачыла. Озерскиның төзелеш мәйданнарында ике айга якын барган тырыш хезмәт артта калды. Монда, Сугомак тавына, алар төзелеш отряды сугышчысына багышлау өчен күтәрелде. Тауга күтәрелү һәм Чиләбе өлкәсендә узган беренче җәй турында хатирәләр, КДАТУда укулар башлангач та, Динарны җылытып һәм рухландырып тора.

ҮЗ КИЛӘЧӘКЛӘРЕН ТӨЗҮЧЕЛӘР

Динарны отрядка икенче бер студент аның иптәше белән җәй көне кайда акча эшләргә дип сөйләшеп торуын ишеткәннән соң чакыра.

– Егетләр, әйдәгез, төзелешкә киттек! – ди ул. Хезмәт хакы барысын да хәл итә. Студент өчен бер эш сезонында 80 мең сум акча эшләү мөмкинлеге – бик зур уңыш.

Озерскида «Росатом» объектлары төзелеше берничә ел дәвам итә. Һәр җәй һәм кышкы каникулларда биредә бөтен илдән җыелган студент төзелеш отрядлары эшли. Беренче ике атна дәвамында Динар һәм аның иптәшләре Чиләбе климатына ияләшә. Сәгать алтыда торуга да җайлашырга туры килә. Казанда бу вакытта иртәнге дүрт кенә бит!

– Миңа монда эшнең ничек оештырылуы бик ошады. Куркынычсызлык техникасы 100% ка үтәлә. Бик яхшы ашаталар. Әгәр туйдыра икән, объектта эшне алыштырырга мөмкин. Бер сезон эчендә без объектны реставрацияләп бетердек – штукатурладык, буядык, нигезен ныгыттык, грунтны тигезләдек, урман кистек, бордюрлар ясадык, – дип искә ала Динар. – Бу күнекмәләр һәм белемнәр безгә кирәк бу-

лачак. Мин архитектор булырга укыйм, отряд егетләре арасында сәнәгать һәм гражданлык төзелеше юнәлешендә укучылар бар. Объектта бөтен эш процессын күрсәң, киләчәктә болар барысы да кирәк булачак.

Сменадан соң егетләр шәһәргә чыга, төрле чараларда катнаша. Фотокросс дисеңме, биюме, квиз яисә спорт уеннарымы…

– Вакыт бик тиз үтеп китте. Шәп җәй булды ул елны, – ди төзелештән кайтуга укый башлаган Динар. Хәзер ул янә Озерскига барырга әзерләнә, бу юлы инде отряд командиры сыйфатында.

ҖИР ЧИТЕНДӘ АЛГАН ЭМОЦИЯЛӘР

– Самолеттан чыгуга вулканнарны күреп алдым. Башка, әллә соң бу төшме, дигән уй килде. Камчатка – шулкадәр матур. Аны һәркем үз гомерендә бер генә мәртәбә булса да күрергә тиеш, – дип сөйли Казан медицина көллиятенең 3 нче курс студенты Мәликә. Студент кыз һәм Татарстаннан тагын 500 кеше балык эшкәртү предприятиеләрендә эшләргә бара. Сезон эчендә яшьләр 100-130 мең сум акча эшләгән. Кайбер заводлар иң яхшы хезмәткәрләрне «айфон» белән бүләкләгән.

Мәликәнең балык эшкәртүчеләр отряды составында беренче сәфәре узган ел була. Казан яшьләре Камчаткадагы Октябрьск бистәсенә юл тота. Мондагы климат һәм 9 сәгатьлек вакыт аермасы беренче мәлләрдә бик авыр тәэсир итә. Әмма берничә буш көн эчендә егет һәм кызлар барысына да ияләшергә өлгерә. Ә аннары 8 сәгатьтән соң 8 сәгать эшләргә кирәк булган график буенча эшли башлыйлар. Студентлар бөтен процесста да катнаша: сортларга аерудан алып, катырылган әзер продукцияне төяп-озатуга кадәр.

– График тыгыз, әмма бөтен буш вакытыбызда диярлек аралаштык, өстәл уеннары уйнадык, җырлар җырладык, бәйрәмнәр уздырдык. Заводка Россиянең 11 регионыннан 120 кеше килде. Красноярск крае, Тува, Мәскәү, Питер егетләре һәм кызлары белән танышу бик кызык булды, – ди Мәликә. – Анда, җир читендә, илнең никадәр зур булуын, гаҗәеп матур табигатьне һичшиксез сакларга кирәклеген аңлыйсың. Ә өйгә әйләнеп кайтуның рәхәтлеге!

– Ел саен Татарстаннан «чирәм җирләргә» төзүче, проводник, вожатый, медик, авыл

5

хуҗалыгы, балык эшкәртү предприятиеләре хезмәткәрләре, кунакханәләр персоналы сыйфатында 10 меңгә якын кешене җибәрәбез. Яз һәм көз айларында алар укулар уза һәм бер ел эчендә ике һөнәри «катыргы» алырга мөмкин. Язылу өчен үз вузың яки шәһәреңдә безнең бүлеккә мөрәҗәгать итәргә кирәк, – дип аңлата «Россия Студентлар отрядлары» Яшьләр иҗтимагый оешмасының Татарстан бүлеге матбугат секретаре Надежда Васильева. – Төзелеш отрядының даими катнашучысы буларак, шуны әйтә алам: бу шәп компаниядә саллы хезмәт хакы алу һәм вакытны бик яхшы үткәрү генә түгел, үзеңне оештыручы, идарәче, белгеч буларак сынап карау мөмкинлеге дә. Төзелеш отрядлары чып-чын кадрлар чыганагы булды һәм шулай булып кала да. Күп кенә танылган сәясәтчеләр дә әлеге мәктәпне үткән. Шул исәптән – Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тә.

СТУДОТРЯДКА ЯЗЫЛАСЫҢ КИЛӘМЕ?

ШАЛТЫРАТ: +7 (843) 231-82-27.
ЯЗ: VK.COM/TRORSO, #ОТРЯДЫТАТАРСТАНА.

4

Яңа белем-күнекмәләр архитектура, сәнәгать һәм гражданлык төзелеше юнәлешләре буенча укучы яшьләргә кирәк булачак.

5

Камчаткага Мәликә һәм Татарстаннан тагын берничә йөз студент балык эшкәртүчеләр отряды составында бара.

Фотолар Мәликә Низамова һәм Динар Саттаровтан алынды.

ТУЛЫ БЕР СЛЭМ ДА АЗ

Грантка гариза тутырырга. Әлеге өч сүз ярдәмендә бүген теләсә нинди яшьләр проектын тормышка ашырып була.

«Үземнең 26 яшемдә мин шигъриятне модалы итәргә хыялландым. Бу шулкадәр көчле теләк иде, мин «әгәр шагыйрьләрнең үз-үзләрен күрсәтү өчен мәйданчыклары юк икән, мин аны булдырачакмын» принцибы буенча яңа башлап җибәрдем. Казан шагыйрәсе Регина Әхмәтова «ВКонтакте»дагы үз битенә урнаштырылган әлеге посты белән шәһәр тарихында тәүге мәртәбә «Слэм» Бөтенроссия заманча шигърият фестивален башлап җибәрә. Регина һәм аның белән бергә маркетинг агентлыгында эшләүче команда шагыйрә ел саен Кырымда үткәрелә торган «Таврида. Арт» «Россия яшьләре» форумында катнашып откан 750 мең сум күләмендәге грантка слэм үткәрә.

«КАПМА-КАРШЫГА» КОРЫЛГАН ПОЭЗИЯ

Бер слэм гына аз тоела, шуңа күрә Регина янә гариза бирә һәм быел «күп серияле» проект өчен 1 млн сум күләмендәге грантны ота. Июнь ахырында инде өченче чара узачак.

– Мин 9 яшемнән үз шигырьләремне бик зур аудитория каршында укырга хыялландым. Әмма һәрвакыт бу миңа гына кирәк дип уйладым. Гариза әзерләгәндә, һәр икенче кешенең диярлек шигырь язуын, яшьләргә дә шигъри бәйгеләрнең кызыклы икәнлеген һәм слэмнарга килергә әзер аудитория барлыгын ачыкладым. Бу миңа илһам өстәде, – ди Регина.

Регина өчен авторларның ярышка иҗади якын килүе бик мөһим, шуңа күрә гадәти үк булмаган темалар тәкъдим ителә. Быел, мәсәлән, капма-каршылык темасы: ак һәм кара, яшәү һәм үлем, мәхәббәт һәм нәфрәт.

– Шигърият – без яшәгән чорның кучермәсе, чагылышы. Шигырьләребез бүгенге көндәге вакыйгаларны чагылдырсын иде. Шәхсән үзем өчен хакыйкать һәм ялган темасы кызык. Әле күптән түгел генә мин вакыйга һәм сүзләрне контекстта, шул исәптән вакыт, заман кысасында карауның никадәр мөһим булуын аңладым. Бөек Ватан сугышы чорына хас шигырьләр минем өчен хәзер бөтенләй башкача яңгырый. Бу хакта иҗат аша сөйләшергә теләр идем, – ди Регина.

Казан слэмнарында барлыгы 2 меңгә якын автор чыгыш ясаган, ә сайлап алуларга өч тапкыр күбрәк кеше килгән. Мондый проектлар өчен бик зур саннар. Слэмда катнашучылар җиңүче призы, укылган шигырьләренең аудио- һәм видеоязмаларыннан тыш, бөтен бөек шагыйрьләр дә һәрвакыт ия булган камилләшү, ярыша алу мохите дә таба.

– Башта бу үзенә күрә бер катлаулы сорау иде: мин ахыр чиктә менә шундый нәтиҗә килеп

Фотолар «Слэм» poetrvfest2021 фестиваленең рәсми төркеменнән, Алинә Костягинаның шәхси архивыннан алынды.

чыгарлык итеп яза аламмы? Нәтиҗәдә, слэм куркуларны җиңәргә һәм алга барырга ярдәм итте. Үз мөмкинлекләреңне күрергә һәм аларны арттыру ысулларына төшенергә. Әгәр беренче чарада калтырап, салкын тиргә баткан булсам, хәзер, әйтик, сәхнәдә үз-үземне иркен тотам, күңелем кушканча чыгыш ясыйм, – ди узган слэмнарда җиңүчеләрнең берсе, Казан авторы Васил Сәфәргалиев.

ҮЗ «ОСТАХАНӘҢНЕ» АЧ

– Бүген без сезнең белән нәрсәне дә булса үзгәртергә тиеш. Дошманлыкка мөнәсәбәтне карыйк, – дип башлый үз чыгышын публицист, «Башкача укырга өйрәнәбез» телеграм-каналы авторы Светлана Моторина. Моннан берничә ел элек Светлананың улы сыйныфташлары ягыннан буллингка дучар ителгән. Әлеге хәлне җайлаганнан соң, Моторина мондый бәлагә тарыган ата-аналар өчен китап яза. Ул Мәскәүдән Казанга башка спикерлар белән бергә «Ата-аналар остаханәсе» проектында чыгыш ясау өчен килә. «Балагыз сезгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә алсын өчен, ул бу ярдәмнең барлыгына ышанырга тиеш», – дип үзенең төп фикерен формалаштыра Светлана.

– Без балаларга да, өлкәннәргә дә максималь файда китерәчәк проект эшләргә теләдек. Безнең министрлык каршындагы Ата-аналар советы төзелде, ата-ананы борчыган темалар, ата-ана һәм яшүсмерләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә килеп туган проблемалар турында нинди форматта фикер алышырга кирәклеге ачыкланды. Шулай рәвешле «Ата-аналар остаханәсе» концепциясе пәйда булды, – ди проект авторы Алинә Костягина. Алинә, үзе «Минмол Тинс» яшүсмерләр белән эшләү юнәлешен җитәкләгән Яшьләр эшләре министрлыгы ярдәменә таянып, «Росмолодежь» химаясендәге Милли студент клублары лигасы грантына гариза юллый. 252 мең сумны тәшкил иткән грант акчалары Россиянең төрле төбәкләреннән килгән алты спикер катнашында TED форматындагы бер көнлек чараны оештырырга җитә. Казан Милли китапханәсе задына 200 дән артык ата-ана җыела, ә онлайн-трансляцияне 51 меңнән артык кеше карый. Һәр чыгыштан соң спикерларга сораулар бирәләр. «Остаханә» хәтта күп еллар яшьләр сәясәте белән шөгыльләнүче белгечләрдә дә бик күп хис-фикерләр уята.

– Шулкадәр кирәкле чара булды! Минем өч улым бар, өлкәне – яшүсмер. Спикерларның үз тарихларын сөйләве бик ошады. Кризислы хәлләрдән чыгуның чын тәҗрибәсе бик мөһим, – ди Яшел Үзән районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге башлыгы Веста Калистратова.

«Остаханә»нең нәтиҗәсе оештыручылар көткәннән дә артыграк була. Алинә бу юнәлештә эшчәнлеген алга таба да дәвам итәргә ниятли.



– Кирәкле һәм мөһим проектлар һәрвакыт ярдәм таба. Хәзер «Росмолодежь» 15 номинация буенча грант конкурслары үткәрә. Грантлар суммасы – 1,5 миллион сумга кадәр. Безнең республика министрлыгы 14 юнәлеш буенча грант суммасы 300 мең сумга кадәр булган конкурслар уздыра. Моннан тыш, «Росмолодежь» химаясендә ел саен «Таврида.АРТ», «Территория смыслов», iВолга һ.б. шундый форумнар уза. Анда 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге һәр катнашучы үз проектын тәкъдим итә ала, – ди «Татарстан – мөмкинлекләр территориясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы җитәкчесе Нәфис Сираҗетдинов. – Без проект авторларына киңәшләр бирәбез, гаризалар әзерләргә булышабыз. Конкурслар турында һәр җирдә сөйлибез! 2021 елда Татарстан яшьләре үз проектлары өчен 142,3 миллион сумга якын акча алды. Республикадан килгән гаризалар һәм җиңүчеләр саны арту бик әйбәт. Алар күбрәк булган саен, без регионга бюджет акчаларын күбрәк җәлеп итәбез. Моннан барысы да ота гына.

ГРАНТ АЛЫРГА ТЕЛИСЕҢМЕ? «ТАТАРСТАН – МӨМКИНЛЕКЛӘР ТЕРРИТОРИЯСЕ» АКБОНЫҢ VK.COM/VOZMOZHNOSTI-TATARSTAN АДРЕСЫНА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТ.

6
Россия шагыйрәсе Ах Астахова Казанда узган «Слэм» Бөтенроссия заманча шигърият фестивалендә.

7
«Балагыз сезгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә алсын өчен, ул бу ярдәмнең барлыгына ышанырга тиеш», – ди Светлана Моторина.

8
«Остаханә»нең нәтиҗәсе оештыручылар көткәннән дә артыграк була. Алинә Костягина бу юнәлештә эшчәнлеген алга таба да дәвам итәргә ниятли.

«БЫЕЛ ЯҢА ЙОРТКА КҮЧӘРГӘ ХЫЯЛЛАНАБЫЗ!»

Руфия Фазылова

Шәһәр белән чагыштырганда, авылда тормыш салмаграк ага кебек тоела. Һәрхәлдә, читтән караганда шулай уйлыйбыз. Азнакай районы Урсай авылында яшәүче Ихсановлар белән танышкач, моның киресенә инандык.

БЕР КҮРҮДӘ ЯРАТУ

Ленар белән Аленаның гаилә корууларына унбер ел булган. Өч балалары бар. Икесе мәктәптә укый. Ә төпчекләре Ләлә әлегә балалар бакчасына йөри.

Ленар тумышы белән Урсай авылы егете, Алена исә Амур өлкәсендә туып-үскән кыз. Милләте буенча – рус. Язмыш яшь кызны чыпчын татар авылына алып килә.

– Укуымны тәмамлаган елны Урсайга туганнарга кунакка кайттым, – дип сүзен башлады Алена. – Бу яклар бик ошады, шуңа күрә Тимирясов исемендәге Казан инновация университетының Әлмәт филиалына укырга керергә булдым. 2000 нче еллар, әле БДИлар гамәлгә кермәгән иде, университетка барып имтиханнарымны тапшырдым. Әллә ни зур авырлыкларсыз югары уку йорты студенты булдым.

Университетның соңгы курсында укыганда, прописка турында белешмә сорап, Урсай авыл җирлегенә баргач, җирлек башлыгы секретарь итеп эшкә чакыра. «Районда яшьләрне яраталар», – дип тә өсти. Алена озак уйлап тормый – ризалаша.

– Дөресен генә әйткәндә, зур сайлау мөмкинлеге дә юк иде, – дип искә алды ул чакларны яшь ханым. – Тәҗрибәң булмаган килеш яшьләрне бик эшкә алырга атлыгып тормыйлар. Монда әзрак тәҗрибә туплагач китәрмен дип уйладым.

Үткен кызны тиз күреп алалар – озакламый Аленаны Урсай мәдәният йортына сәнгать җитәкчесе итеп тә эшкә чакыралар. Эшли башлагач, мәдәният йортында «Юлдаш» җыр ансамбле оештыра. Киемнәр тектерү, репертуар сайлау, бәйгеләрдә катнашу... Татар мәдәниятеннән ерак торган кыз акрын-акрын барысына да өйрәнә.

– Бер авыз татарча белмәгән рус кызына Урсайда авыр булмадымы? – дим.

– Бик җиңел дия алмыйм. Утырып елаган чаклар да булды. Алланың рәхмәте, юлымда Ленар очрады. Аның белән тормыш күпкә җиңеләйде.

Фотолар Ихсановларның гаилә архивыннан.

«ШТК ТАНЫШТЫРДЫ»

2010 нчы елда авыл җирендә эшләүче яшьләр арасында «Шаяннар, тапкырлар клубы» ярышы оештыралар. Урсайдан да команда туплыйлар. Шаян егет-кызлар арасында Ленар да була. Һәр кич авыл яшьләре мәдәният йортына җыела. Әнә шундый бер кичтә Ленар Аленаны озатып куя. Дуслыктан башланган мөнәсәбәтләр чын мәхәббәткә әйләнә.

– Бер ел дигәндә Ленар тәкъдим ясады, – дип дәвам итте Алена. – Без башта эти-әниләр белән бергә яшәдек, анан соң иремнең әбисе йортына күчендек. 2013 елда «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына кердек. Азнакайдан махсус комиссия килеп яшәгән йортыбызны карады. Озакламый безгә торак салу өчен 1 миллион сумнан аз гына артык акча күчте. 2014 елның язында йортыбызга нигез салдык. Быелның җәендә яңа йортка күчәргә ниятлибез.

Әлбәттә, йортны салып чыгу өчен хөкүмәт ярдәме генә җитми.

– Йортны җиткерүгә үз акчаларыбызны да күп керттек, – дип дәвам итте Алена. – Газ кертәсе генә калды инде. Дөресен генә әйткәндә, вакыт юк. Мин Урсай авылы мәдәният йортында директор, Ленар исә сәнгать җитәкчесе булып эшли. Районда нинди чара бар, барысында да катнашабыз. Азнакайда атна саен җомга көн үзешчәннәр концерты була, шунда барабыз. Өйгә йокларга гына кайтабыз. Рәхмәт әнигә, балаларны ул каршы ала, дәресләрен караша.

Мәдәният йортыннан тыш, Алена Урсай урта мәктәбендә химия укыта. Өченче баласы белән декрет ялында утырганда, КФУда өч ел укыган. Хәзер ул химия, биология укытучысы да.

– КФУны кызыл дипломга тәмамладым, – диде Алена. – Хәер, алдагысы да кызыл минем. Уку авыр бирелми. Балалар да үзебезгә охшаган. Улыбыз мәктәптә гел бишкә генә укый, кызыбыз да бик тырыш.

– Ә үзегезгә мәктәп әллә мәдәният йорты якынракмы? – дим.

– Мәктәп якынрак. Балалар белән эшләү бик ошый. Аллага шөкер, мәктәбебез зур, сиксәннән артык бала бар. Дөрес, ун белән унбергә бик күп укучы калмый, тик ул бездә генә түгел, башка мәктәпләрдә дә шулай бит.

Бу гаиләдә балалар ике телне дә камил белә: этиләре белән фәкать татарча, әниләре белән русча сөйләшәләр. Егерме ел эчендә Алена үзе дә татарчага өйрәнгән, барысын да аңлый, дөрес, авыррак сөйләшә.

– Урсай мәктәбендә татарча укыйлар, – диде Алена. – Шулай булгач балалар төп фәннәрне дә татарча үзләштерәләр. Ә мин химияне рус телендә алып барам. Моңа мәктәп җитәкчелеге, ата-аналар да каршы килмәде. Химия сигезенче сыйныфтан гына керә, терминнарны рус телендә өйрәткәч, аларга имтиханнар тапшырырга да җиңелрәк була. Гомумән, безнең мәктәптә барлык укучылар да татарчаны, русчаны камил белә. Ул яктан бер проблема да юк.

Аленаның тагын бер эше турында әйтми кала алмыйм: шактый еллардан бирле балалар өчен экология түгәрәгенә алып бара. Узган ел гына да түгәрәккә йөрүчеләр ярдәме белән Урсай җирлегендә өч мең, быел исә авылның Сабантуй мәйданында ике йөз төптән артык агач утыртылган. Балалар мондый эшләрне бик ярата. «Алена апа, кайчан тагын табигатькә чыгабыз?» – дип кенә тора икән. Укучылар экология буенча төрле республика, Россия күләмендә уздырылган ярышларда катнаша, җиңүләр яулый.

Җиңү дигәннән, Алена Ихсановадагы диплом, грамота, рәхмәт хатларының исәбе-хисабы юк. «Отражение» Халыкара иҗатчылар конкурсында өченче урын, Каюм Насыйри исемендәге Халыкара конференциядә өченче урын, КФУ үткәргән экология конкурсында икенче урын... Саный китсәң, бер бер бит кенә җитмәячәк.

– Ә сез бу бөтен конкурслар турында кайдан беләсез дә, барысында да катнашырга ничек вакыт табасыз? – дим.

– Күбесен мәктәп администрациясе, районның мәдәният бүлеге җиткерә. Конкурсларда еш катнашкач, гел миңа әйтәләр. Аннары инде электрон почтама да шундый бәйгеләр турында мәгълүмат килеп тора. Ә вакыт табуга килгәндә, миңа ул зур стимул, шуның өчен дә бәйге, конкурсларда бик теләп катнашабыз. Инде балалар да өйрәнеп бетте.

...Азнакай район администрациясендә Ихсановлар белән: «Яшь, бик тырыш, актив гаилә», – дип таныштырдылар. Чынлап та матур алар. Районда, авылда ихтирам яулаган гаилә. Ә Аленага карата аерым хөрмәт уянды. Үзең әйбәт булсаң, җиде ят арасында да үз кешегә әйләнеп була, моңа милләт, тел дә киртә түгел. Зәңгәр күзле, сөйкемле әлеге ханым шуның ачык мисалы.

«ЯШЬЛӘРНЕ КОЛАЧ ҖӘЕП КАРШЫЛЫЙБЫЗ!»

Руфия Фазылова

Табибларга кытлык. Моңа инану өчен теләсә кайсы шәһәр поликлиникасына барып карау да җитә. Ә авыл, районнарда хәл тагын да катлаулырак. Мисал өчен бөтен Мамадыш районына бары бер офтальмолог! Шуңа да әлеге белгеч күз өстендәге кара каш кебек – кадерле! Мамадышлылар «Земство докторы» федераль программасына бик рәхмәтле, аның кысаларында узган ел гына да районга өч яшь табиб кайткан.

ПРОГРАММА ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА ЯНӘ БЕР ИСКӘРТЕП УЗАРГА КИРӘКТЕР: АВЫЛ ҖИРЕНӘ ЭШКӘ КАЙТКАН ЮГАРЫ ҺӘМ УРТА МЕДИЦИНА БЕЛЕМЛЕ БЕЛГЕЧЛӘРГӘ ДӘҮЛӘТ БЕР ТАПКЫР БИРЕЛӘ ТОРГАН КОМПЕНСАЦИЯ ТҮЛИ. АНЫҢ СУММАСЫ: ТАБИБЛАР ӨЧЕН 1 МИЛЛИОННАН БАШЛАП 2 МИЛЛИОНГА КАДӘР (АВЫЛНЫҢ ЕРАКЛЫГЫНА БӘЙЛЕ) ҺӘМ ФЕЛЬДШЕРЛАРГА 500 МЕҢНӘН БАШЛАП 1 МИЛЛИОНГА КАДӘР. РФ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ 2022 ЕЛНЫҢ 6 МАЕНДАГЫ КАРАРЫ НИГЕЗЕНДӘ МАКСАТЧАН ПРОГРАММА БЕЛӘН УКУЧЫ ЯШЬ ТАБИБЛАР ДА ЭШЛӘРГӘ ТУГАН ЯГЫНА КАЙТКАН ОЧРАКТА ӘЛЕГЕ ПРОГРАММАДА КАТНАША АЛАЧАК. (МОҢА КАДӘР АНДЫЙ ЯШЬЛӘРГӘ БУ АКЧАЛАР БИРЕЛМИ ИДЕ.)

Фото: Александр Ефремов

СҮРИЯДӘН

Мамадышның бердәнбер офтальмологы белән якыннан таныштык – **Заин Алабидин Рами**. Бирегә узган ел гаиләсе белән күченеп кайткан. Тумышы белән Сүриядән. Булачак табиб Россия белән танышуын 2002 елда Санкт-Петербург шәһәреннән башлый. Бер ел анда яшәгәч, Түбән Новгород дәүләт медицина университетының дәвалау факультетына укырга керә. Укудан соң Белгород шәһәренә китә, ординатураны шунда уза. 2015 елда исә Казанга күченә, 5 нче шәһәр поликлиникасына эшкә урнаша. Анда алты ел тәҗрибә туплагач, Мамадышка күченеп кайта.

– Онколог Марина Александровна Диланова белән бергә эшләгән идек, – диде Заин Алабидин Рами. – Ул Мамадышка китте. Шулай да аның белән аралар өзелмәде, телефоннан сөйләшеп тордык. Бервакыт ул мине Мамадыш район хастаханәсенә эшкә чакырды. «Офтальмолог кирәк. Әйдә, карап, танышып кит, монда эшләргә бик уңайлы», – диде. Мамадышка барып, баш табиб белән сөйләштем. Ул «Земство докторы» программасы белән 1 миллион сум акча биреләчәген әйтте. Иң мөһиме – яшәр өчен ике бүлмәле фатир бирәбез, диделәр. Казанга кайтып, хатыным белән киңәшләштем дә, озакка сузмыйча, Мамадышка күчендек.

– Казанны ташлап киткәнгә үкенмисезме? – дим.

– Россиянең төрле шәһәрләрендә яшәп карадым, иң рәхәте – Татарстан. Монысын һич икеләнмичә әйтәм. Мөселман динендә булгач, биредә миңа халыкның яшәеше аңлаешлырак. Мондагы халык ачык, табибларга зур хөрмәт белән карый. Мамадышка күченеп кайткач, бу аеруча ачык күренде. Ә үкенү дигәннән, әлбәттә, юк. Мамадышта яшәр өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Әле менә улыбызны балалар бакчасына бирергә йөрибез. Ким дигәндә, тагын дүрт ел биредә яшәргә кирәк бит («Земство докторы» программасы кысаларында, акча алганнан соң, белгеч әлеге урында биш ел эшләргә тиеш - ред. иск.).

– Программаның шартларын үтәгәч, ягъни дүрт ел узгач, яңадан шәһәргә китү нияте бармы?

– Сүз дә юк, Казандагыга караганда монда эш күбрәк. Тәүлекнең егерме дүрт сәгатендә син элемтәдә булырга тиешсең. Кемгәдер төнлә дә ашыгыч ярдәм күрсәтергә кирәк була, йөгереп хастаханәгә киләбез. Ә шәһәрдә бит аерым сәгатьләрдә генә дежур торасың. Ә биредә тәүлек буе, ел әйләнәсе... Баш табибка рәхмәт, безнең күңелне күрергә тырыша: яңа медицина җиһазлары кайтты. Яшь табиб буларак, бер урында гына торасы килми: якын киләчәктә амбулатор операцияләр ясарга телим.

КИРОВ ӨЛКӘСЕННӘН

Узган ел «Земство докторы» программасы белән Мамадышка кайткан табибларның берсе – **Мария Александровна Диланова**. Район хастаханәсенең онкологы ул. Мария Диланова Киров дәүләт медицина университетының дәвалау факультетын тәмамлагач, Киров өлкәсендә терапевт булып эшләп тәҗрибә туплый. 2020 елда «онкология» белгечлеге буенча янә белем ала. 2021 елның апрелендә исә Мамадышка күченә.

– Туган ягыгызны ташлап, бер күрмәгән районга килергә нәрсә мәҗбүр итте? – дим.

– Монда мөмкинлекләр күбрәк, Киров өлкәсеннән китүемнең төп сәбәбе шул. Биш яшьлек улым, ирем бар. Алар да Мамадышны бер күрүдә яратты. Иремә дә эш булды.

Мамадыш район хастаханәсенә табиб-онколог кирәклеге турында Марияга университетта бергә укыган танышы әйтә. Шуннан соң ул баш табиб белән сөйләшергә килә, эш шартлары белән таныша. Һәм биредә калырга ризалаша.

– Коллектив бик тату, эшләргә рәхәт, – диде яшь белгеч. – Гомумән, Мамадыш безне колач җәеп каршы алды дип әйтә алам. Моннан китү турында уйлаганыбыз юк.

– Дәүләт биргән 1 миллион сум акчаны тоттыгызмы әле? – дим.

– 500 мең сумына машина алдым. Фатирны хастаханә арендага бирде, коммуналь хезмәтләр өчен генә түлибез. Киров өлкәсе белән чагыштырганда, хезмәт хакы яхшырак.

МАМАДЫШ РАЙОНЫ БУЕНЧА ОНКОЛОГТА 900 КЕШЕ ИСӘПТӘ ТОРА ИКӘН. КӨН САЕН БЕРНИЧӘ ДИСТӘ КЕШЕ ДИСПАНСЕРИЗАЦИЯ УЗА. БЫЕЛ ГЫНА УНИКЕ МЕҢ МАМАДЫШЛЫ ӘНӘ ШУНДЫЙ ТИКШЕРҮ ҮТӘРГӘ ТИЕШ. СОҢГЫ ЕЛДА ЯМАН ШЕШ БЕЛӘН АВЫРУЧЫЛАР САНЫ БЕРМӘ-БЕР АРТКАН.

– Пандемия чорында кеше табибларга йөрмәде, шуңа күрә бүген онкология генә түгел, башка чирләр дә күп ачыклана, – диде Мария Александровна.

ТҮБӘН КАМАДАН

Мамадыш район хастаханәсендә эшләүче тагын бер яшь табиб – Максим Николаевич Мартынов. Киров дәүләт медицина университетын узган ел тәмамлаган, Түбән Кама егете.

– Университетны тәмамлагач, армиягә барып кайттым, – диде Максим. – Армиядән соң, Киров дәүләт медицина университетын урология буенча ординатурасын тәмамладым. Мамадыш хастаханәсенә уролог кирәк дигән игъланны күрдем дә, килеп карарга булдым. Ошаттым, калдым. Яшәргә ике бүлмәле фатир бирделәр. Менә шул... Бер ел инде бу вазыйфада. Акрынлап район халкы белән таныша барам. Гаилә корырга ниятлим. Булачак хатыным да Мамадыш район хастаханәсендә эшли. Кыскасы, биредә төпләнеп калырга ният.

– Ни өчен урология юнәлешен сайладыз? – дим.

– Хирургия өлкәсе бит, ир-атлар өчен кулай юнәлеш дип саныйм. Теория бар, тәҗрибә кирәк. Шуның өчен дә бу өлкәне өйрәнүемне алга таба да дәвам итәчәкмен. Җиһазлар булган очракта, күп операцияләрне үзебездә ясарга мөмкин. Ниятләр зурдан: үз өлкәмдә яхшы табиб буласым килә.

МАМАДЫШ РАЙОН ХАСТАХАНӘСЕ КАРАМАГЫНДА ИКЕ БҮЛМӘЛЕ СИГЕЗ ФАТИР БАР. ТР ТОРАК ФОНДЫ БЕЛӘН АРЕНДА КИЛЕШҮЕ ТӨЗЕЛГӘН. ӘЛЕГЕ ТОРАКЛАР ХАСТАХАНӘДӘ ЭШЛӘҮЧЕ ТАБИБЛАРГА ВАКЫТЛЫЧА БИРЕЛӘ, ЯГЪНИ ТАБИБ ЭШТӘН КИТКӘН ОЧРАКТА ФАТИРНЫ БУШАТЫРГА ТИЕШ БУЛА.

«КОЛЛЕКТИВЫБЫЗ ЕЛДАН-ЕЛ ЯШӘРӘ БАРА»

Мамадыш район хастаханәсендә бүген табибларның уртача хезмәт хакы алтмыш мең тирәсе. Арендагы торак, 1 миллион сум кайтарылмый торган акча – беренче карашка яшь табибларны болар кызыксындырырга тиеш. Әмма... авыл, район җиренә яшьләр кайтырга атлыгып тормый!

– Безгә генә түгел, яшь белгечләрнең Түбән Кама, Чаллы хастаханәләренә дә кайтасы килми, – диде Мамадыш район хастаханәсенең баш табибы Дамир Хаҗиев. – Аларны Казан кебек зур шәһәрләр кызыктыра. Шуның өчен районга кайткан һәр табибны колач җәеп каршы алабыз. Коллектив елдан-ел яшәрә.

– Моңа кадәр «Земство докторы» программасы кысаларында табиблар кайтканы бар идеме? Һәм аларның барысы да эшләп киттеме?

– Әйе, шактый кайттылар, араларында терапевтлар да күп. Әлбәттә, районга кайткан ул белгечләрнең барысы да хастаханәдә калды, дип әйтә алмыйм. Биш елын эшләгәч китүчеләр дә бар. Монда бит эш бик күп, ялсыз диярлек. Сине теләсә кайчан өеңнән чакырып китерәләр. Китүчеләргә беркайчан каршы килмибез. Киресенчә, бездә тәҗрибә алган табиблар республика күләмендә зур дәрәҗәләргә ирешә икән, сөенәбез генә. Алар белән аннары да элемтәдә торабыз. «Китәргә уйласагыз, ким дигәндә, ярты ел алдан кисәтегез», – дип кенә әйтеп куям.

P.S.

2012 елдан бирле «Земство докторы» һәм «Земство фельдшеры» программалары кысаларында Татарстан буенча 887 белгеч бер тапкыр бирелә торган компенсация алган.

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

ЛИАНА БАҺАВИЕВАДАН КАЙМАКЛЫ БАЛЫК АШЫ

Татьяна Вафина

Эшлекле хатын-кыз ифрат та эшлекле булса, аның өйдәге эшләргә вакыты калмый.

– Тик бу бит Татарстан хатын-кызларына кагылмый! – дип саный «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» ТТИО президенты Лиана Баһавиева. – Безнең кызлар барысын да булдыра, чөнки бизнесларын алар үзләре яраткан хезмәттән чыгып кора – яратып эшләгәндә исә эш тә бара, көнкүреш мәшәкатьләренә дә вакыт кала!

Һәм, моны дәлилләп, Лиана «Татарстан» журналына үзенең иң оста әзерли торган ризыгын – сөләйман балыгыннан каймаклы аш пешереп күрсәтергә вәгъдә бирә.

ЯШЬ, ӘММА ТӘҖРИБӘСЕЗ ТҮГЕЛ

«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» әле бик яшь – оешмага 10 ел гына. Лиана башта туризм тармагында эшкуар була, 2011 елда Инвестицияле үсеш агентлыгына дәүләт хезмәтенә күчкәч исә (анда ул республикадагы кече һәм урта бизнес мәнфәгатьләрен кайгырта), гаҗәпкә кала: эшкуарларга дәүләт ярдәме күрсәтә торган әллә никадәр программа бар икән бит – инфраструктура ягыннан да, мөлкәткә кагылышлы да, консультацияләр бирә торганнары да...

– Мин исә боларның берсе хакында да белми идем. Башка эшкуарларга әлеге мөмкинлекләр турында мәгълүматны җиткерү, аларга булышуны үземә беренче чираттагы бурыч итеп билгеләдем. Ә ничек эшләргә соң моны? Кешеләрне кайдадыр, нәрсәдәдер берләштерергә кирәк һәм шул берләшмә аша ярдәм күрсәтеп булачак. «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» шул рәвешле пәйда булды. Яшь, энергияле, идеяле хатын-кызлар агыла башлады – күрәмсең, ул вакытта алар ирләргә караганда активрак булгандыр. Мәгълүмати ярдәм күрсәтүдән башлаган идек, нәтиҗәдә исә эше бөтен республиканы колачлаган тулы бер берләшмә үсеп чыкты. Татарстаннан читтә дә үсәбез. Менә Эшкуарлар көненә Ижевскига бардык әле – география һәм элементләрне киңәйтәбез.

ЯШЬЛӘРГӘ «СТАРТ»

– Яшь, үз эшен башлап кына килүчеләр белән эшлисезме?

– Бу юнәлешне быел актив үстерә башладык. Яшьләр өчен «Старт» пакетын булдырдык. Бу эшен яңа башлаучы эшкуарлар өчен дә, эшкуар булырга теләүчеләр өчен дә, бизнеста өч елдан азрак эшләүчеләр өчен дә. Берләштерәбез, алар өчен төрле өйрәтү чаралары үткәрәбез. Чөнки кече бизнеска керешкәндә иң мөһиме – мәгълүмат һәм өйрәтү ул.

ХЫЯЛГА ЧИКЛӘР ЮК

– Сезнең химаядәгеләрнең нинди бизнеслары бар?

– Беләсезме, бу оешма миңа нигә шулкадәр ошый? Чөнки безнең кызларыбыз барысы да бик үзенчәлекле фикер йөртә. Кайвакыт, минем карашка, аларның идеяләре бөтенләй гайре табигый була. Еш кына бөтенләй хатын-кызлар эше дә түгел. Әмма аларның барысы да барып чыга. Мәсәлән, берсе металл эзләгечләр ясый. Аның шактый уңышлы үз җитештерүе бар. Икенчесе исә кәрәзле элемтә каланчалары төзи һәм аларны арендага бирә. Кемдер йортлар сала. Кемдер төзелеш материаллары белән шөгыльләнә. Шактые социаль сферада, матурлык индустриясендә мәшгуль. Үзенең балалар бакчасын, хосусый мәктәбен ачучылар да бар. Ә бит алар бөтенесе диярлек үзләре дә ана кеше, күп балалылары

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Сөләйман балыгы – 2 зур кисәк;
- Бәрәңге – 2 данә;
- Кишер – 1 данә;
- Суган – 2 баш;
- Аш яисә соус өчен куе сөт өсте (каймак) – 100 г;
- Тоз, тәмләткечләр – тәменчә.

Фото: Ната Смирнова

1 Турыйбыз

2 Салабыз

3 Салабыз

4 Турыйбыз

5 Кырабыз

6 Кыздырабыз

7 Кушабыз

8 Салабыз

9 Өстибез

10 Кылчыгыннан чистартабыз

11 Турыйбыз

да очрый! Аларның үзләре уйлап табып, гамәлгә ашырган хыял тарихларын тыңлап, мин үземә илһам алам.

ШУНДЫЙ ТӨРЛЕЛӘР

– Оешмада ничә «эшлекле хатын-кыз» исәпләнә?

– Казанда – 73, республикада – 362 кеше. Төрле районнарда эшлекле активлык та төрлечә. Чаллыда бик тәвәккәл кызлар, алар янып тора, идеяләре бихисап. Әлмәттә тыныч холыклы, үз кадерен белүчеләр күбрәк. Яшел Үзәндә – энкерсезләр. Мин аларның барысы турында һәм һәркайсы хакында кичкә кадәр сөйли алам. Безне берләштергән иң мөһим нәрсә – без бергә идеяләр генераторы да, бер-беребезгә ярдәм дә, һәм терәк-көч тә, әлбәттә.

Лиана тиз пешерә торган савытта әзерли, димәк, аш пешерү вакыты тагын да кыскара. Катлаулы эшләрдән – бәрәңге әрчеп турау. Әмма Лиана санаулы минутлар эчендә тамыразыкны шакмаклап турап, кәстрүлдәге балык һәм суган янына салып та куя. Һәм безнең сөйләшүгә нәкъ җиде минут кала: икесе – шулпа кайнап чыкканчы һәм биш минут – пешкәнче.

КЫЗЛАРГА БУ ОШЫЙ

Әлегә исә планнар хакында сөйләшик.

– Минем бизнес-хәрәкәттә билгеле бер тәҗрибәм бар, – ди Лиана. – Шунлыктан без франшиза булдырырга, бизнес-клубны сатарга һәм моны Татарстан базасында Россиянең башка төбәкләрендә кабатларга ниятләдек. Татарстан сынау мәйданчыгы иде, без барлык процессларны тикшердек, барып чыкты. Безнең кызларга мондый эш ошый, башка төбәкләргә дә ошаячак. «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» үрнәгендә, мәсәлән, Ростов, Ульяновск яки Түбән Новгород хатын-кызлары да эшли алачак бит. Кызыксынучылар шактый.

Чөнки казанышларыбыз күп, һәм алар күз алдында. Без үзебезнең берләшмәбездә бер-беребезгә булышабыз, этәргеч бирәбез. Нәрсәдер сатыр өчен генә дә бит моны кем беләндер, кем өчендер эшләү зарур. Без барыбыз да бер казанда кайный, бер чатта аралашабыз. Язылмаган кагыйдәбез бар – үзебезнекеләрдән сатып алабыз. Мәсәлән, миңа визитка бастырырга кирәк икән – һичшиксез үзебезнекеләргә барам. Болай эшләп без бер-беребезгә булышабыз да, куәтебезне дә арттырабыз. Безнең берничә косметика салоны бар икән, аларның хуҗалары бер-берсен көндәш итеп күрми, бәлки бер-берсеннән өйрәнә, тәҗрибә уртаклаша һәм булыша.

ЭЧКЕ ЯКТАН КАРАШ

Мондый мөнәсәбәтләр бик кадерле. Тормыш бер урында гына тормый бит: кемдер декретка чыга, кемдер башка шәһәргә күчәнә, әмма безнең оешманың нигезе һәрвакыт яңа көчләр белән тулыланып тора. Без үзебезнең бизнес-миссия-

без белән горурланабыз: яңа территорияләрне үзләштерү, яңа кешеләр җәлеп итү, яңа тәҗрибәгә баю буенча. Социаль челтәрләрдәге «Әчке яктан караш» дигән рубрикабызда эшкуарларыбызның бизнесы хакында сөйлибез.

Безгә мәгълүмати ярдәм җитми, дип саныйм. Иманым камил, «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» оешмасы турында белеп алсалар, яшь эшкуарлар һичшиксез безнең янга килер иде.

Уважаемые читатели и создатели журнала «Татарстан»! Желаю Вам теплого лета, мирного неба, а главное – гармонии внутри и красоты.
[подпись] 18 мая 2022
Лиана Багавиева

ХАТЫН-КЫЗЛАРЧА БИЗНЕС

– Бизнеста хатын-кыз һәм ир-ат кулы аерыламы? Әлеге мәсьәләдә бу гендерлык бүленеше кайдан килеп чыккан?

– Мин бөтен җирдә «хатын-кызларча бизнес» темасын күтәрергә омтылам. Мин шуны аңладым: ирләргә башта бик каты уйларга кирәк, аннары гына ныклы карар кабул итәләр. Хатын-кыз исә дөрес юлны интуициясе белән тоя. Бәлки, алар сыгылмалырак, бер үк вакытта берничә бурычны хәл итәргә сәләтлерәктер, һәм бу аларның өстенлеге булып тора.

«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» – минем юанычым, хәзер мин монда үземне судагы балык кебек хис итәм, үз урынымда тоям. Бу урынга исә мине: финанс институтында уку (параллель рәвештә юристлыкка да укыдым), үз бизнесым, дәүләт хезмәте, җәмәгать эшчәнлеге алып килде... Әкренләп барысы да җайланды. Балачак хыялым дип әйтү дөрес булмастыр – бала чакта кем иҗтимагый эшчәнлек хакында хыяллансын ди инде. Шунысын гына төгәл хәтерлим: беркайчан да укытучы һәм табиб булмаячагымны тәгаен белдем. Әлеге һөнәрләрдән кала барысына да әзер идем. Иң мөһиме – мин һәрвакытта да мөстәкыйльлеккә омтылдым.

ХЫЯЛЛАНЫРГА – УЙЛАНЫРГА – ТЫНЫЧЛАНЫРГА ҺӘМ... КОСМОСКА!

– Хатын-кыз бизнес белән шөгыльләнә башлагач, аның гаиләсе турында кайгыртырга вакыты калмый, дип санала. Бу шулаймы?

– Эшкуарлыкка керешкәч, хатын-кыз моңа башы-аягы белән бирелә һәм еш кына гаиләсенә вакыты да, көче дә калмый. Әмма бу күңелең ятмаган эш белән шөгыльләнгәндә генә шулай. Бизнесны исә хатын-кызларча да алып барып була: армый-талмый, интекми-газапланмыйча, үзеңә дә, ирең белән балаларыңа да җитәрлек игътибар биреп. Барысын да дөрес эшләргә генә кирәк. Хатын-кызга үз эше ошый икән, димәк, бу дөрес юл. Мондый халәттә ул хыяллана, әлеген хыялын космоска җибәрә, тынычлап уйлана ала – һәм болар барысы да үзеннән-үзе килеп чыга. Мин моңа үз мисалымда да, кайбер кызларыбыз мисалында да әллә ничә тапкыр инандым инде. Ир-ат иртүк тора, эшкә китә, кичен хәлдән таеп кайтып ава ала... Кичке аш әзерләнмәгән, өй җыештырылмаган, балалар каралмаган булса да, аңа берниндидәгъва белдерүче юк. Ул эштә арый ала, ә менә хатын-кызга арырга ярамый, шунлыктан аңа эше ләззәт китерергә тиеш. Эшен шулай оештыра алганнар: «Мин эшкә киләм дә рәхәтләнеп ял итәм!» – диләр. Хатын-кызларча бизнесның үзенчәлеге нәкъ менә шунда да инде: эшеңне куралмау түгел, бәлки аны яратып, рәхәтләнеп эшләүдә. Шунлыктан ләззәт бирә торган эш табу мөһим. Мин шундый эшне таптым.

ШӘХСИ КУЛИНАРИЯ «САНДЫГЫ»

Кәстрүл ашның әзер булуын хәбәр итә. Төгәлрәге, яртылаш әзер булуын. Лиана шулпага кыздырылган суган һәм кишер, сөт өсте, тәмләткечләр сала, һәм аш үзенә бөтен хуш исне җыеп тәмлеләнгән арада Джейми Оливер рецепты буенча тиз генә кәтермәч (икмәк кисәкләре) кыздырып ала.

– 2014 елда Туристлык буенча дәүләт комитетында эшләгәндә коллегаларым, гадәти булмаган тәм-том пешерергә яратуымны белеп, минем фотомны да шунда кертеп, Джейми Оливерның рецептлар китабын бүләк итте. Бирейдә икмәк кыздыруның тәмле һәм бик гади ысулы бар. Башта табада шалфей мае кыздырырга кирәк, аннары шунда икмәк кисәкләрен саласың. Искиткеч хуш исле һәм кабатланмас тәмле ризык әзер! Мондый көтелмәгән рецептларны мин һәрвакыт хәтеремдә калдырам, алар минем башымдагы шәхси кулинария «сандыгында» саклана, гаиләбезнең яраткан ризыкларына әйләнә.

Менә бу сөләйман балыгы белән пешерелгән аш рецептын да мин Самарадан алып кайттым. Бер тапкыр аны ресторанда ашадык. Искиткеч тәмле иде! Үзем дә пешерергә өйрәнергә булдым. Тәҗрибәләр ясый-ясый, тәмен гаиләдә һәркайсыбызга ошый торган камиллеккә җиткердем. Хәзер бу безнең иң яраткан ашыбыз. Ул бик тиз пешә һәм бөтен кешегә дә ошый. Шундый яртылаш бәйрәмчә аш. Иң мөһиме, ул да борщ кебек төнәп җитәргә тиеш. Озаграк торган саен, ул тәмләнә генә бара.

– Сезнең башыгыздагы «кулинария сандыгында» тагын нинди рецептлар бар?

– Классик чизкейк, коймак пешерергә, диңгез кыслалы салат ясарга ятатам... Иң мөһиме – рецепт тиз әзерләнә торган, кәеф исә яхшы булсын! Т

ЛИАНА БАҺАВИЕВАДАН ФАЙДАЛЫ КИҢӘШ:
Иң мөһиме – рецепт тиз әзерләнә торган, кәеф исә яхшы булсын!

ШУКЛАНЫП ТА КҮРСӘТКӘННӘР...

Аларның даны... Канн шәһәренә кадәр барып җиткән! Ун ел эшләү дәверендә «Шкодники» юмор киножурналы һәм Казанның «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе илледән артык бүләк һәм диплом яулаган, хәтта Халыкара «DREAM FILM FESTIVAL» Канн балалар киносы һәм телевидениесе фестивале лауреаты да булган. Хәер, Елена Вальцефер җитәкчелегендәге фикердәшләр командасы элеккечә үк төшерү мәйданчыгында тылсымлы: «Камера! Мотор! Башладык!» сүзләре яңгыраганнан соң балалар күзендә кабынган чаткыларны үзенең төп казанышына саный.

Барысы да исә... «Ералаш» киножурналыннан башлана. Данлыклы киностудия Казанда үз мәктәбен ача. Кино дөньясы белән кастинглар яки сценарийлар түгел, бәлки бухгалтерлык исәпләре һәм финанс хисабы аша гына таныш булган Елена Вальцефер директор итеп чакырыла.

Әмма без физикадан лирикага кадәр араның нибары бер адым булуын яхшы беләбез. Елена очрагында исә бу – кечкенә генә укытучы роле. Төшерү мәйданчыгында зарурлык тугач, режиссер аңа уйнап карарга тәкъдим итә.

– Мин бик иҗади кеше булып чыктым! – дип көлә Елена, гомерен икегә аерган шул көнне исенә төшереп. Һәм «Ералаш» Казан базарыннан киткәч тә, ул балалар киносы дөньясыннан аерыла алмый. Менә инде ун ел буе Елена Вальцефер үзенең «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе белән генә җитәкчелек итеп калмый, бәлки «Шкодники» юмор киножурналының продюсеры да булып тора.

– Бу гаилә скетчкомы, чөнки төшерү мәйданчыгында балалар гына түгел, аларның әти-әниләре дә үзләрен сынап карый ала, – дип сөйли Елена. – Ул 2–3 минутлык кыска күләмле сюжетлардан гыйбарәт. Нигезендә мәзәкләр ята, төп геройлар исә – балалар, мәктәп укучылары. Безнең проектны эксклюзив дип атап була, чөнки бүген кыска метражлы балалар киносы – видеоконтентның әле һаман да сирәк очрый торган форматы бит.

Ун ел эчендә «Шкодники» ярдәмендә биш яшьтән егерме яшькә кадәр һәм аннан да өлкәнрәк йөзләрчә кеше үз мөмкинлекләренең чикләрен киңәйтә алган – актерлык осталыгында беренче адымнарын ясаган, үзен профессиональ кинода сынап караган, хыялга бирелеп, кыюланган һәм үзүзенә ышанычын арттырган. Кем өчендер исә «ДжуниорЛайф» мәктәбе үз хыялын тормышка ашыруда нигез булган – актер, диктор, телевидение алып баручысы карьерасында беренче баскычка әйләнгән... Балалар өстәл тартмаларында тузан җыеп ята торган ленталарда түгел, серияләре телевидениедән күрсәтелә, республика кинотеатрларында прокатта бара торган «Шкодники» журналында төшә бит.

Бу чандыр гына кызның планнары зурдан – Татарстанда тулы метражлы балалар уен киносы төшерергә тели ул.

– Барысы да тормышка ашарлык хыяллар! – дип елмая Елена Вальцефер. – Моның өчен бездә бөтен нәрсә бар – зур иҗади потенциалга ия тәҗрибәле команда, республикабызның искиткеч локацияләре. Һәм талантлы актер балаларның бу ун ел эчендә тупланган зур базасы!

Фото: Анна Арахамия. РЕКЛАМА

РОМАН ГАЛИЕВ, 12 ЯШЬ
Бервакыт без роликны паркта төшердек. Сценарий буенча кояшлы көн булырга тиеш иде, әмма һава торышы кызык итте. Көн буе күктә болытлар агылды, туктап-туктап көчле яңгыр яуды. Без ничек тә яңгырдан качарга маташтык, әмма паркта бу шактый катлаулы. Көн бераз аяза башлауга ук, без чираттагы кадрларны төшерергә йөгерә идек. Иң кызыгы, ролик чыннан да кояшлы булып чыкты, һәм кадрлар арасында безнең давылдан качар урын эзләп йөгереп йөрүебезне күз алдына да китерүе кыен. Әйе, кино – чын маҗара ул!

КАМИЛЛА КӘЛИМУЛЛИНА, 12 ЯШЬ
Минем бик тә кинода төшәсем килде. Һәм аны һичшиксез телевизордан күрсәтерлек булсын! Моны ничек эшләргә соң? Мин «Шкодники» турында белеп алдым. Моның минем өчен менә дигән мөмкинлек булуын шундук аңладым. Кастинг үткәч сөенүемне белсәгез! Аннары безне актерлык осталыгына өйрәттеләр, һәм тиздән хыялым чынга ашты – миңа роликта роль тәкъдим иттеләр. Әлбәттә инде, мин ризалаштым. Беренче тапкыр кинода төшкән көн минем өчен бик кадерлегә әйләнде.



МАРГАРИТА ТӨХФӘТУЛЛИНА, 8 ЯШЬ
Бервакыт мәктәптә безне «Шкодники» киножурналында төшәргә чакырдылар. Минем мәктәп турында чыгарылышта бик катнашасым килгән иде, әмма кастингка соңга калдым. Бик борчылдым инде моңа. Әмма мин киножурналга барыбер эләктем. Миңа тылсымлы «Хогвартс» мәктәбе укучысы ролен тәкъдим иттеләр, бу исә минем яраткан темам. Менә нинди уңыш елмайды миңа!

ПЛАТОН ГАЙКОВОЙ, 11 ЯШЬ
Күз алдына китерегез: дусларым белән камерага төшәбез. Берберебезгә таянабыз да шундук егылабыз. Һәм бу очраклылык түгел: беребез кемгәдер таянмакчы булганда гына, ул читкә китә дә, барып төшәбез. Без менә шулай итеп кызыклы позаларда тордык һәм төрле мәзәкләр сөйләдек. «Шкодники» киножурналында төшү катлаулы да, дулкынландыргыч та түгел, киресенчә, бик күңелле булды. Миңа бик ошады!

АНДРЕЙ КИСЛЯКОВ, 12 ЯШЬ

Бервакыт без магия һәм тылсым турында серле, мистик күренеш төшердек. Бүлмә ярымкараңгылыкта, кулда шәм яна... Без образга тулысынча биреләдек һәм үзебез дә ышана яздык. Менә кинәт минем кулымны нәрсәдер чәнчеде, мин, куркып, үләм, дип кычкырдым! Ут кабызгач, моның шәмнән агып төшкән балавыз булуы ачыкланды. Тулысынча образга керү менә ничек була ул!

ВИКТОРИЯ ПАК, 7 ЯШЬ

Бервакыт, «Шкодники» киножурналында төшәргә җыенганда, әниемнән чәч учмаларын алсуга буявын үтендем – мин бу төсне бик яратам. Әнием буямады. Ә минемчә, сәнгать (гүзәллек кебек үк!) корбаннар сорый ул. Бер сүз белән әйткәндә, үзем фломастер белән буярга ниятләдем, кич әле башлана гына иде. Чәчемнең төсен әнием иртән генә күрде... Кинога төшкәннән соң ук чәчтарашка киттек – ул исә бөтенләй шаккатты!

ОЛИВИЯ ХӨСӘЕНОВА, 6 ЯШЬ

«Шкодники» киножурналында төшкәннән соң минем апам Эмили бик тәэсирләнеп кайтты! Ул миңа: «Анда ничек шәп булуын син күз алдыңа да китерә алмыйсың!» – дип сөйләде. Әлбәттә инде, минем дә кинога төшәсем килде. Башта бераз кыенрак булса да, аннары җиңелләште. Миңа бигрәк тә өлкәннәрнең үсендереп торуы, төшерү мәйданчыгында хәтта печенье дә булуы ошады! Күп кызларның принцесса яки тылсымчы буласы килә, ә мин тәртипсез кызны уйнар идем. «Шкодники» проектында бу бик мөмкин, дип уйлыйм.

МАТВЕЙ РУСАНОВ, 10 ЯШЬ

«Шкодники» киножурналында беренче тапкыр төшкәндә, мин дулкынланудан музыка укытучысының исемен бик озак дөрес әйтә алмадым. Шулай төшерделәр дә. Үземне экранда күргәч, миңа бик кызык булды. Бераз оялдым да – дулкынлануым миңа яхшырак уйнарга комачаулады бит. Әмма инде икенче тапкыр камера каршына баскач, мин үземне күпкә ышанычлырак тойдым.

ЭДГАР НАГАЕВ, 10 ЯШЬ

Бервакыт без курку турында фильмда төштек. Сценарий буенча без, балалар, өстәл астында утырабыз һәм нәрсә турындадыр сөйләшәбез. Кинәт безгә таба бер ир-ат килүен күрдек. «Ул безне куркытмакчы була!» – дип уйлап, үзен куркытырга булдык. Ул иелгән генә иде, без өстәл астыннан сикереп чыктык та бар көчебезгә кычкыра башладык. Безнең план барып чыкты – ул чыннан да курыкты. Соңыннан исә бергәләп көлештек. «Шкодники» киножурналында төшү – һәрвакыт кызыклы һәм күңелле ул.

ЭМИЛИ ХӨСӘЕНОВА, 8 ЯШЬ

Миңа сәхнәдә чыгыш ясау бик ошый. Мин яхшы җырлыйм, биим. Вокал буенча шәһәр конкурсларында катнаштым. Популяр буласым килә, нигә әле кинода төшмәскә, дип уйладым. «Шкодники» киножурналында мин ялганчы ролендә төштем. Миңа ошады! Бу бик күңелле булып чыкты, рольне өйрәнү исә минем өчен бик җиңел – шундук ятлап алам. Әлеге фильмның чыгуын түземсезлек белән көтәм. Мин кино күп карыйм, әмма үзем катнашканы иң яратканы булачак.

АННА СӘЕТОВА, 10 ЯШЬ

«Шкодники» кинопроекты өчен роликта төшәргә әнием тәкъдим итте. Миңа бу идея ошады. Һәм менә инде берничә ел буе рәхәтләнеп һәр сезонда катнашам, һәм һәр яңа роль белән нindider яңа нәрсәгә өйрәнәм. Мәсәлән, күптән түгел йога позалары белән таныштым, детектив һәм агентларның ничек эшләвен аңладым һәм хәтта киләчәктә булып кайттым. Тагын әле аэроторбада очарга өйрәндем. «Шкодники» киножурналын төшерүчеләргә шундый мөмкинлекләр биргәннәре өчен рәхмәт!

МИЛАНА НӘҖИПОВА, 10 ЯШЬ

Без бик кызыклы эпизод төшердек, анда мин үземне гламур кыз итеп күзаллый идем. Эсседә миңа зиннәтле тун, кояш күзлеге кидерделәр, муенсалар тактылар, соклы бокал тоттырдылар. Күп дубль төшерергә туры килде. Нindider бер мизгелдә мин, образга ихластан бирелеп, чәчемне шундый итеп селкедем ки, өстемә сок түктем. Тун, бизәнү әйберләре, матурлап таралган чәчем – барысы да юпь-юеш булды. Әмма, төшерү төркеменең осталыгы нәтиҗәсендә, экранда бу бөтенләй сизелмәде.

РУСЛАН ЕРМОЛАЕВ, 11 ЯШЬ
Миңа бервакыт «Шкодники» киножурналында бик кызыклы роль уйнарга туры килде. Мин гитарада уйнап җырладым. Уйный да, җырлый да белмәгән килеш бит бу! Оялдыммы? Һич юк! Роль миңа бик ошады, аны уйнау күңелле булды.

АЛЬМИРА ҺӘМ АЛАНА ШӘКУРОВАЛАР, 9 ҺӘМ 6 ЯШЬ
Үзен бер тапкыр экранда күргән һәр бала кабат кинопроектка эләгү турында хыялланачак. Безнең өчен «Шкодники» киножурналында катнашу һәрвакыт мавыктыргыч маҗара һәм көтеп алынган вакыйга! Кино әлегә безнең һөнәребез түгел, әмма инде балачагыбызның рәхәт хатирәләре һәм эпизодлары ул. Моның өчен киножурналга зур рәхмәт әйтәсебез килә.

ГАБРИЭЛЛА СӘЛАХЕТДИНОВА, 7 ЯШЬ
Бервакыт без кинога бик серле һәм куркыныч урында төштек. Анда килүгә үк, мин бик курыктым. Скелет, курчак һәм әллә нинди сихерле нәрсәләр тулы караңгы бүлмәгә керергә кирәк иде. Куркуымны җиңеп, рольне ничек тә башкарырга туры килде. Кулымдагы шәмнең балавызы агып, бик авырттырса да, грим булгач, еларга ярамаганын беләидем, шуңа пешүгә түздем. Курыккан кыз ролен мин бик яхшы башкардым. Әмма, дөресен әйткәндә, шулкадәр куркыныч иде анда, хәтта уйнарга да туры килмәде.

ӘМИР МӨХӘММӘДИЕВ, 13 ЯШЬ
Бервакыт «Шкодники» киножурналында төшәсе урынга мине әтием илтте. Безнең тренерны уйнарга тиешле актер исә, төшү көнен бутап, килмәгән булып чыкты. Әтием коткарды безне ул көнне. Сүзләрне белмичә, ул рәхәтләнеп импровизацияләде һәм ролен бик яхшы уйнап чыкты. Мин моңа гаҗәпләндем һәм сокландым. Кино аңа иҗади яктан ачылу, миңа исә әтиемә башка күз белән карау мөмкинлеген бирде!

АРЫСЛАН НУРУЛЛИН, 12 ЯШЬ

Иң беренче рольләремнән берсе – уңышының сере «Теләсә нинди шартларда да күнекмәләрне туктатмаска!» шигаре булган чаңгычы. Җәй, елның иң эссе көне, парк. Һәм мин-кышкы куртка, башлык, җылы чалбардан, «Россия вперед!» дип язылган шарф-тан – үз чиратымны көтәм һәм репетиция ясыйм. Исем дә китми, урамда 32 градус эссе, ә мин чаңгыда басып торам һәм узып баручыларны ирексездән елмаерга мәҗбүр итәм. Бер-ике дубльдән соң бурычым инде үтәлде дә. Әмма көтмәгәндә режиссёр миңа чаңгыда «чемпионнарча» йөреп килергә кушмасынмы! Яшел чирәм буйлап... «Тренер» сызгыра, мин чаңгыда «шуа» башлыйм... һәм, чирәмгә абынып, барып та төшәм. Моны күрмәгән «тренер» сызгыруын дәвам итә, оператор һаман төшерә. Рәхәтләнеп көлдек аннары. Бик көлкеле финал килеп чыкканга, режиссёр әлеге кадрларны калдырырга булды.

СӘЙДӘ ЗАКИРОВА, 6 ЯШЬ

Бервакыт миңа фильмда шоколад ашарга кирәк иде. Төшергәндә мин шулкадәр күп шоколад ашадым ки, аннары ел буена аңа карый да алмадым!

МАРИЯ ЧИНИЛКИНА, 9 ЯШЬ

«Шкодники» киножурналындагы ролем минем беренче тапкыр профессиональ кинога төшүем булды. Мин бик дулкынландым. Ролик «На плечах гигантов» дип атала, һәм анда минем сыйныфташларым катнаша иде. Нәрсә истә калдымы? Режиссёрларның безгә гел ярдәм итүе, бергәләшеп көлүебез һәм шуклануыбыздыр. Миңа болар барысы да бик ошады һәм, әлбәттә инде, үземне «Эфир» телеканалындагы «Доброе утро» программасында күрсәткәч, мин бик горурландым.

АДЕЛИНА ГАЙФУЛЛИНА, 9 ЯШЬ

Әнием белән сеңлем «Шкодники» кинопроектында төшеп кайткач, миңа: «Беләсеңме, Аделинка, режиссёр сине кече метражлы фильм кастингына чакырды. Хәзер үк! Бүген гариза бирүнең соңгы көне», – диләр. Мин нишләргә кирәклеген башта аңламадым да. Әмма киножурнал режиссёры Тимур Шаумянович үзе тәкъдим итә икән, димәк, катнашырга кирәк! Минем белән видео төшереп, аңа җибәрдек. Аннары исә кастинг, төшерү мәйданчыгында эшләү һәм хәтта интервью да булды. Юмор киножурналы менә нинди мөмкинлекләр бирә!



ЖАННА ӘХМӘТШИНА, 46 ЯШЬ
Барысы да минем артист улымнан башланды. Башта «Шкодники» киножурналында ул төште, аннары исә үземне сынап карарга мине дә чакырдылар. Кызык булып китте, мондый казанда кайныйсы килде. Һәм миңа да ошады! Чөнки бу камера каршында үземне иркен тотарга өйрәтте, рольгә кереп, рәхәтләнеп уйнау мөмкинлеге бирде. Өстәвенә, фильмнар бик көлкеле дә. «Шкодники» кинопроектында мин инде берничә ел төшәм. Унбишләп кыска метражлы фильмда төшелгән! Әлеге тәҗрибә нәтиҗәсендә мин хәтта «зур кинога» да эләктем – «Зулейха открывает глаза» фильмы эпизодында төштем. Менә шулай итеп «Шкодники» улымныкын гына түгел, үземнең дә хыялымны тормышка ашыру мөмкинлеген бирде. Тагын әле әниемнекен дә – ул да гомере буе кино актрисасы булырга хыялланган икән.

НУРИЯ ЕЛЕСИНА, 46 ЯШЬ
Бервакыт китапханәдә төштек, мин китапханәче ролендә идем. Бер дубль, икенчесе... Бермәлне карасам, яныма кешеләр җыелган. «Сезгә нәрсәдер кирәкме әллә?» – дим. «Сезнең бушаганыгызны һәм китап бирә башлавыгызны көтәбез», – диләр... Тагын музей искә төшә, анда мин җыештыручыны уйнаган идем. Оператор белән төшерү нечкәлекләре хакында гәпләшәбез. Администратор килеп, мине читкәрәк алып китә: «Соңрак җыештырырга ярамыймыни? Күрмисезмени, бирердә кино төшерәләр бит», – ди. Миңа шундый чакларда бик рәхәт. Димәк, рольне ышандырырлык итеп уйный алам! Кинода миңа бигрәк тә төшерү процессы үзе ошый. Кием алыштыру, үзгәрү бик кызыклы. Барысы да җиңел генә бирелми әлбәттә. Әмма катлаулы рольне уңышлы башкарганнан соң күңелгә бик рәхәт була. Кайвакыт коллегалар да: «Афәрин!» – дип кычкыра. «Шкодники» кинопроектында атмосфера бик җылы, дустанә, һәм мин баламның нәкъ менә шундый мохиттә үсүенә бик шат.

МӘДИНӘ ӘБХӘЛИЛОВА, 43 ЯШЬ
Шулай килеп чыкты ки, актерлык осталыгы белән мин шактый өлкәнәйгәч кенә кызыксына башладым. Мин хәтта махсус курслар да тәмамладым. Балаларга исә актерлык осталыгы мәктәбе бигрәк тә файдалы, ул аларга ачылу, кыюлану, сәхнәдә үзеңне ышанычлы тоту, ораторлык сәләтен үстерү мөмкинлеген бирә. Мин үз баламны «ДжуниорЛайф»ка шул сәбәпле алып килдем. Бирердә улым актерлык осталыгы дәресләрен алып кына калмый, киножурналда төшеп, аларны шундук файдалана да. Мондый мөмкинлек миңа да тәтеде әле! Бөтенләй башка һөнәр иясе булуыма карамастан, «Шкодники» кинопроектында катнашу миңа үземнең иҗат потенциалын ачу һәм моннан гаять зур ләззәт алу мөмкинлеген бирде.

ХЫЯЛ «РИТМ»ЫНДА

Белем, сәламәтлек, иҗат, тәрбия, профориентация, мәктәп, белем бирү мохите, укытучы. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы раслаганча, әлеге күрсәткечләр «идеаль мәктәп» өчен мәҗбүри. Боларның барысы да Казанның 187нче номерлы «РИТМ» лицеена да хас.

– Без мәктәп телевидениесен оештырырга ниятлибез. Мәктәп тормышы турында яңалыкларны төшереп, аларны тәнәфесләрдә күрсәтергә телибез. Барысына да кызык булыр иде дип уйлыйм, – ди **Әмир Насыйбуллин**. Ул җиденче сыйныфта укый, ә мәктәп хөкүмәтендә элемтә һәм мәгълүмат министры вазыйфасын башкара. Әмир айти-компетенцияләрне үзләштерү нинди мөмкинлекләр бирүен үз үрнәгендә күрсәтә: шәһәр, район һәм Россия конкурсларында катнаша һәм җиңеп чыга, робототехника белән шөгыльләнә, спорт дроны белән идарә итә, лицей командасы составында «Челтәр системасы белән идарә итү» компетенциясе буенча JuniorSkills ярышларында катнаша.

ИҖАТ - САННАРДА

Боларның барысын башкарып чыгарга Әмиргә һәм башка укучыларга лицей тарафыннан кабул ителгән «Мәгълүматлаштыру программасы» ярдәм итә.

– Өстенлекләребезнең берсе – цифрлы һәм мәгълүмати компетенцияләргә өйрәтү. Бездә инженер-технология классы, пилотсыз очу аппаратларының инженер классы, телестудия, 3D-модельләштерү лабораториясе эшли, web-программалаштыру, әйберләр Интернеты, робот техникасы буенча дәресләр бара. Быел безнең укучыларның, WorldSkills төбәк чемпионатында беренче тапкыр катнашып, өч призлы урын яулавы белән горурланабыз, – ди лицей директоры урынбасары Анна Яблонская.

– Без киләчәктә балаларыбызның кирәкле булуын, төрле хәлләргә тиз җайлаша, җәмгыятьтә төрле рольләрне башкара алуын телибез. Моның өчен аларда hard skills – техник күнекмәләрне, soft skills – социаль компетенцияләрне үстерергә, шул ук вакытта фундаменталь белем дә бирергә кирәк, – ди лицей директоры Гөлнара Галиева. – Мондый якын килүне без Казандагы Лицей – инженерлык үзәгендә эшләгән коллегаларыбыз тәҗрибәсеннән алдык. Шул рәвешле көчле өстәмә белем бирүдә оештырылган күппрофильле «Ритм» лицее концепциясе барлыкка килде. Бүген без укучыларга бер яисә берничә үсеш юнәлеше тәкъдим итәбез: математика, инженер-технология, лингвистика, табигый-фәнни, социаль-гуманитар өлкәләр.

Фотолар Казандагы 187 нче лицейдан, kzn.ru порталыннан алынды. РЕКЛАМА

«РИТМ» һәр яктан караганда да XXI гасыр мәктәбе. 1224 укучыга исәпләнгән лицей 2020 елда «Мәгариф» милли проекты нигезендә төзелгән һәм ачылган. Ул бөтен кирәкле инфраструктурага ия, шул исәптән бассейн һәм заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән. Астропланетарий, музыка мәктәбе өчен уен кораллары коллекциясе, IT-полигон, цифрлы фәнни лаборатория – әлеге һәм башка бик күп нәрсәләр уку вакытында һәм өстәмә дәресләрдә кулланыла. «РИТМ» сүзе үзе дә русча яшьләрнең инновацион иҗатын үстерү дип таркатыла. Иҗат һәм белем алу монда – синонимнар.

ХӘТЕР

Бервакыт лицей укучысы, пианист Милана Галиева Нәҗип Җиһановның «Бишек җырын» ишетә. Әсәр Миланага бик ошый, ул аны өйрәнә һәм композиторның башка әсәрләрен кызыксынып тыңлый башлый. Аның мавыгуы яңа проект – «РИТМ» лицеенда Нәҗип Җиһанов исемендәге музей оештыруга китерә.

– Безнең мәктәп музее бар. Без аны Татарстанда мәгариф системасының Идел буе Болгарстаныннан алып безнең көннәргә кадәрге тарихына багышларга ниятлибез. Ә Нәҗип Җиһановка багышланган экспозиция арт-киңлектә урнашачак, анда без музыкаль чаралар уздырабыз. Балалар музейда экскурсияләрне үзләре үткәрер, дип уйлыйбыз. Бу проектның пәйда булуы лицейның шушы композитор исемендәге урамда урнашуы белән генә аңлатылмый, Җиһанов – дөнья дәрәҗәсендәге гаҗәеп шәхес. Ул күп көчен педагогик эшчәнлеккә сарыф иткән, консерваториягә нигез салган. Аның күп кенә әсәрләре бүген дә бик заманча яңгырый. Аның дөньясы белән танышып, балалар тынгысыз иҗатчы булуның тирәнрәк аңлый башлаячак, – ди музыка укытучысы Мария Музилеева.

Инновацияләр артыннан куып, элеккеге буыннарның ничек яшәгәнен һәм нәрсә эшләгәнен истә тотарга кирәк. Тарихи хәтердән башка патриотизм була алмый. Бу идея лицей педагогларының да, аның укучыларының да күп кенә проектлары нигезенә салынган.

Һәр иртә 7:45 сәгатьтә «РИТМ»дагы бердәнбер бишенче кадетлар сыйныфы лицей каршында тезелә. Бердәмлектә – көч! – отрядның төп принцибы. Кадет сыйныфы әле бер ел элек кенә ачыла, шул вакыт эчендә укучылар өлгерешләрен арттыралар. Узган ел сыйныфта бер отличник та булмаса, быел алар – өчәү.

Сыйныфта дәрес вакытында – тәртип, тыныч. Сыйныф сәгатьләрендә балалар тарихи һәм документаль фильмнар карый. Бу аларга бик ошый. Алар формалары, яшь армиячеләр булулары белән горурлана. Бер ел эчендә район күләмендә уздырылган җырлап атлау конкурсына әзерләнеп, җиңү яулаганнар. Зур хәрби-патриотик уеннарда 12 яшьтән башлап кат-

нашырга рөхсәт ителә. Балаларны алда яңа җиңүләр көтә!

УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ӨЙРӘНҮ

Өстәлдә «лар», «ләр», «нар», «нәр», кушымчалары язылган карточкалар беркетелгән дүрт сумка тора. Укытучы өч тиен ясалган картинаны күрсәтә. «Тиеннар» яки «тиеннәр» – кайсы сүз дөрес язылган? Тиенне кайсы сумкага салырга? Башлангыч мәктәптә татар теле дәресләре тулысынча диярлек шундый лингвистик уеннар белән бара.

– Без берничә укыту методикасын, шул исәптән Валерия Мещерякованың татар телен чит тел буларак укыту методын бергә тупладык. Башлангыч мәктәптә баланы татар теле белән кызыксындыру бик мөһим. Без уеннар уйныйбыз, шул ук вакытта балалар сүзләр, грамматика, синтаксисны өйрәнә, – ди татар теле укытучысы, милли эшләр буенча директор урынбасары Ләйлә Бикмөхәммәтова.

Лицей укучыларының яртысыннан артыгы, шул исәптән рус гаиләсендә тәрбияләнүче берничә бала да татар телен туган тел буларак өйрәнүне сайлаган. Татар телен өйрәнүче 48 төркемнең 6 сында аны тирәнтен өйрәнәләр. Ел саен лицейда «ALGA РИТМ» дип аталган кече фәнни-гамәли конференция уза. Быел иң яхшы проектларның берсе 6нчы сыйныф укучысы Ислам Әхмәтовның ерак туганы, язучы һәм шагыйрә, күп кенә җыр текстлары авторы иҗатына багышланган эше була. Татарчаны белү модасы укытучылар мохитенә дә үтеп керә. Ир-ат укытучылар командасы татар телендә Муса Җәлилнең батырлыгы турында спектакль куя һәм «Тел сагында – ир-егетләр» шәһәр уенында беренче урынны яулый.

Татар теле дәресләрендә балалар – бары тик татар телендә, ә инглиз теле дәресләрендә инглизчә генә сөйләшә. Үзе инглиз булган Чарльз Емене уздырган өстәмә дәресләр дә инглиз телен яхшы белергә булыша.

– Мин сезгә, мәсәлән, үземнең яраткан ризыгым – гөбәдия рәсемен күрсәтәм. Сез – «I like gubadya» («Мин гөбәдия яратам!») яисә «I don't like gubadya» («Мин гөбәдия яратмыйм!») дип әйтергә тиеш. Бу сүзләрне мөмкин кадәр хислерәк итеп әйтергә тырышыгыз, – дип аңлата Чарльз. Хисләрне хәрәкәтләрдә һәм мимикада чагылдырып, ашамлыклар яисә һава торышы кебек популяр темалар аша ул башлангыч мәктәп укучыларын инглиз телендә сөйләшүне яратырга өйрәтә. Ел башында сәламләү сүзләрен дә көчкә генә белгән укучылар ел азагында диалог төзеп сөйләшү дәрәҗәсенә җитә.

УКУ – ГАИЛӘНЕҢ УРТАК ЭШЕ

Лицейның актлар залы сәхнәсендә – ике «сигезаяк» гаиләсе – этиләр балаларын бутаган һәм хәзер шуклык өчен кемгә җәза бирергә кирәклеген аңларга тырышалар:

– Димәк, без гел минекеләрне кыерсытканбыз? Димәк, хәзер сез миңа өчне тиеш!

Эдуард Успенский әсәре буенча җаваплылык һәм үзара аңлашу турындагы әлеге кызыклы спектакльне лицейның «Дрим РИТМ» театр студиясендә катнашучы укучылар куя.

– Кемдер уеннан ләззәт ала, кемдер сөйләү осталыгына, кемдер үзара аралашуга өйрәнә. Без пьеса, геройлар, характерлар һәм үз спектаклебез белән нәрсә әйтергә теләвебез хакында күп сөйләшәбез. Шулай рәвешле балалар үз-үзеңне иркен тоту һәм шул ук вакытта икенче берәүнең чикләрен бозмауны үзләштерә, – ди студия җитәкчесе, коуч,

психолог һәм «РИТМ»да укучы бер баланың әнисе Елена Гусева. Лицейда аның инициативасы белән «РИТМ family» ата-аналар клубы да оештырылган.

– Әти-әниләребез бик актив, алар балалар белән бергә лицей проектларында катнаша. Күпләр лицей тормышына чын-чынлап тартылган, балаларның барысы да яхшы булсын, дип тырыша. Әмма шуңа да карамастан, бүген дөнья шундый: бала белән бер хисси элемтәдә калу – тулы бер сәнгать. Чикне бозмыйча, аңа ничек ярдәм итәргә? Аның да, минем мәнфәгатьләр сакланырлык диалогны ничек төзергә? Үземнең аны чыннан да яратуымны ничек күрсәтергә? Боларның барысы турында да клубта оештырылган очрашуларда фикер алышабыз. Клуб эшендә катнашучыларның саны артуы бик күңелле, – ди Елена.

– Биредә бала үз көченә, сәләтенә ышансын, үзен иркен хис итсен өчен барысы да эшләнә. Мин моны улым үрнәгендә дә күрәм. «РИТМ»да ул бәйге һәм олимпиадаларда катнашучылар сафыннан призер һәм җиңүчеләр рәтенә күчте. Мин монда әти-әниләргә нинди мөнәсәбәт булуына сокланам. Күп мәктәпләрдә директор кабинеты – ата-ана һәм баланы орыша торган урын. Биредә исә безгә, яңа башлангычларга, баланың уңышына шатлана торган урын. Бу без, ата-аналарны, тагын да күбрәк эшләргә дәртләндерә, – ди «РИТМ family» клубын оештыручыларның берсе Лилия Насыйбуллина.

КИЛДЕ, ӘЗЕРЛӘНДЕ, ҖИҢДЕ

Уртак тырышлык нәтиҗәләрен дә бирә. Бер ел эчендә «РИТМ»да республика олимпиадасында җиңүче һәм призерлар саны арта. Химия белән мавыккан тугызынчы сыйныф укучысы Булат Хәлиуллин быел кинәт кенә экология юнәлешен үз итә һәм лицей педагогы ярдәме белән бөтенроссия дәрәҗәсенә чыга. Аның Россия күләмендә җиңүчесе булу мөмкинлеге дә зур.

– Отличниклар барысын да белә һәм, димәк, олимпиада биремнәрен дә җиңел чишә, дигән стереотип яши. Тик бу алай түгел. Олимпиаданың үз мантыйгы, үз атмосферасы. Аңа шул исәптән психолог белән дә әзерләнергә кирәк, – ди лицейның математика укытучысы һәм олимпиада отряды җитәкчесе Роза Мозаффарова. – Белемне арттырудан тыш, баланы стресслы вазгыятьтә үзен нормаль хис итәргә, шулай ук стандарт булмаганча фикерләргә өйрәтү әзерлекнең плюсы булып тора. Тиз үзгәрүчән дөньяда бу бик файдалы күнекмәләр.

Функциональ грамоталылык, ягъни укучының алган белемнәрен куллана белүе белем бирүдә халыкара бәя санала. «РИТМ»ның бишенче сыйныф укучылары, әлеге тестны узып, республика буенча уртача күрсәткечтән югарырак нәтиҗә бирә. Лицейда әлеге тәҗрибәне башкалар белән уртаклашырга ниятлиләр.

– Апрель аенда район күләмендә, функциональ грамоталылыкка багышлап, «Тормыш өчен укыйбыз» дигән педагогия укулары уздырдык. Анда Мәгариф министрлыгы вәкилләре, мәктәп һәм балалар бакчалары педагоглары, китапханәчеләр катнашты. 50дән артык доклад яңгырады. Мондый чаралар кирәклегенә һәм мөһимлегенә инандык. Хәзер республика дәрәҗәсенә чыгарга телибез, – ди уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Наталья Белова.

«МИН» ПРОЕКТЫ

«РИТМ» Рубик кубигын хәтерләтә. Шакмакның якларын җыйган кебек, бала уку, класстан тыш эш һәм иҗат юнәлешен үзенә охшаганча җыя ала.

– Хәзер без кече фәнни-гамәли конференцияләрдә лицей укучылары күрсәткән иң яхшы проектларны җыентык итеп бастырып чыгару буенча эшлибез. Минем өчен бу бик мөһим, – ди тугызынчы сыйныф укучысы, мәктәп үзидарәсе президенты **Арина Смирнова**. Үзидарә вәкилләре – укучылар һәм лицей администрациясе арасын бәйләүче буын, класстан тыш чара һәм бәйрәмнәрне оештыручы.

– Без сыйныф сәгатьләре үткәрергә, башлангыч мәктәп укучылары белән аралашырга тырышабыз. Миңа аларның безнең ярдәмне тоюлары, уртак проект һәм вакыйгаларда катнаша алуларын белүләре мөһим, – ди җиденче сыйныф укучысы **Диләрә Хәбибуллина**. Җирле үзидарәдә ул остазлык буенча министр ролен башкара. Педагогикадан тыш, Диләрә дизайн белән дә мавыга, кием-салым һәр шәхеснең уникаль сыйфатларын күрсәтү ысулы, дип саный.

– Мин IT-өлкәсендә эшмәкәрлек белән шөгыльләнәсем килә. Бу бик перспективалы юнәлеш, – ди алтынчы сыйныф укучысы **Таир Гатауллин**. Үзенең бабасы белән ул Juniorinvest.ru порталын уйлап тапкан һәм тормышка ашырган, анда 8 яшьтән 16 яшькә кадәрге балалар үз стартапларын яки инвестор эзләү идеяләрен урнаштыра ала. Порталда 150 проект теркәлгән. Бу җәйдә Таир һәм аның командасы проектны яңа дәрәҗәгә күтәрергә ниятли.

«Тормыш – хәлиткеч мизгелләрнең зур бер чылбыры ул», – ди Стивен Спилберг, Гарвард университетын тәмамлаучылар алдында чыгыш ясаганда, киләчәктә шәхес буларак билгеләячәк сайлауны һәр кеше үзе өчен үзе башкаруын күз алдында тотып. Киләчәктә һәр укучы бу сайлауны дөрес башкара алсын өчен, «РИТМ»да барысын да эшлиләр. Т

12+
«КИТАП» ТЫҢЛА!
КИТАП МИЛЛИ радио
КАЗАН 98,6 FM
АО «ТАТМЕДИА» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2 ГРН 1071690057834
Реклама

ГҮЗӘЛ ЯШЬЛЕК ЭЗЛӘРЕ...

Фото: ru.freepik.com

Йөрәкләр кайнар, көч-дәрт ташып торган, алда киртәләр бөтенләй юк тоелган яшьлектә бик күп эшләр башкарыла – яхшылары да, начарлары да. Киләчәк тормышыбыз – эш, карьера, гаилә, ниһаять, картлыгыбыз да нәкъ менә шул гамәлләргә, яшьлегебездә нинди эшләр эшләвебезгә бәйле.

Безнең бүгенге геройларыбызның яшьлек елларына күп вакыйгалар – революция, сугышлар, репрессия, үзгәртеп кору, кризис һәм реформалар туры килә. Һәм аларның һәркайсы язмышына тигән тарихи чорда үзен лаеклы тота. Алар турында Николай Островский язганча әйтергә була: тормыш «бер тапкыр гына бирелә, һәм аны шундый итеп яшәргә кирәк, файдасыз яшәгән еллар өчен үкенерлек булмасын, үлгәндә дә: бөтен тормыш һәм барлык көч дөньяда иң гүзәл нәрсәгә бирелде, дип әйтерлек булсын».

Шуңа күрә геройларыбызның яшь чакларында нинди булганнары, кайчан һәм нинди казанышларга ирешкәннәре турында басмабыз битләреннән укып белерсез.

ТУКАЙ ЭЗЕ...

Ул 27 яшен дә тутыра алмый кала... Ә үзеннән соң нинди тирән эз калдыра. 1913 елның 15 апреле (иске стиль белән 2 апрель) татар дөньясын чын мәгънәсендә тетрәндерә.

26 яшь

26 яшендә Тукай заманының иң атаклы, иң күп гонорар түләнә торган каләм иясенә әйләнә. Шигърияттә генә түгел, публицистикада да зур уңышларга ирешә. Исән чагында ук аның 22 исемдә 46 китабы дөнья күрә.

Кулдан-кулга йөреп үскән гади авыл малае, татар, гарәп, фарсы, төрек һәм урыс телләрендә иркле аралаша һәм яза белә.

Тукай тәрҗемә эшләре белән актив шөгыльләнә. 1906–1907 елларда «Әл-Гаср әл-җәдид» журналында Иван Крыловның 65 мәсәлен тәрҗемә итеп бастыра. Шулай ук Кольцов, Пушкин, Толстой, Лермонтов, Некрасов, Никитин кебек рус әдипләренең әсәрләрен дә татарчага тәрҗемә итә. Рус теленнән тәрҗемә итүне чын иҗат эшенә әйләндерә. Моның белән Тукай татар поэзиясенә яңа тема, мотив һәм сурәтләр алып килә.

Тукай халык җырларын бик ярата һәм аларны җыю буенча да шактый зур эш башкара. 1910 елда «Шүрәле» тәхәллүсе белән «Халык моңнары» дигән китап бастыра, анда 28 җыр туплана. Ул кулдан-кулга йөри торган басмага әйләнә.

Габдулла Тукай үз язмаларын газета-журналларга биргән вакытта төрле тәхәллүсләр куллана. Галимнәр аның җитмешкә якын тәхәллүсе булуын дәлилли. Ләкин бүгенге көндә алар ачыкланып бетте дип әйтеп булмый, чөнки ул чорда нәшер ителгән басмаларның бөтен саннары табылмаган. Гарәп графикасындагы басмаларны укый алучылар да аз. Кайбер газеталарның саны Казан фондларында да сакланмаган. Шуңа күрә йөз елдан соң да Тукайның шигырьләре килеп чыгарга мөмкин, ди белгечләр. Тукай тәхәллүсләре арасында: «Шүрәле», «Тәртә башы», «Догачы», «Каз», «Бер фикерче», «Биик усал», «Болгар», «Шәкерт угы», «Имзасыз да Яраретдинов» һ.б.лар бар.

Тагын шуның кадәр яшәсә, Тукай татар халкы өченниләр эшләгән булыр иде икән? Милли хәсрәткә әйләнгән зур үкенеч бу. Әлбәттә, вакыт ул үкенечне тоныкландыра. Ләкин Тукайның үлеме чын мәгънәсендә фаҗига була. Монысы – бәхәссез. 1913 елда шагыйрь белән хушлашу көнен яктырткан татар газеталары тупланмасын Казан губерна матбугат эшләре махсус җыя. Һәм алар бүген барысы да ТР Милли архивында саклана.

Шул чордагы газеталар шагыйрьнең үлеменнән соң Казан, Кырым, Кавказ, Урта Азиядә татарларның иҗтимагый тормышы берничә көнгә туктады, дип яза. Китап кибетләре, нәшрият, хәтта завод, сәүдә үзәкләре 3–4 апрель көннәрендә ябык булачагын хәбәр итә. Татарлар яшәгән бөтен җирдә матәм чаралары уза. Ә мәктәпләрдә Тукай шигырьләрен, Коръән аятьләрен укыйлар.

2 апрель кичендә Габдулла Тукайны соңгы юлга озату комитеты оештыралар. Матәм чарасын 4 апрельгә планлаштыралар. Иртәнге унда шагыйрь вафат булган Клячкин хастаханәсе янына кешеләр җыела башлый. Халык дулкыны Яңа татар бистәсе зиратына кадәр сузыла. Төрле чыганакларга караганда, Тукайны соңгы юлга озатырга 5–10 мең кеше килә. Җеназаны Галимҗан Баруди уздыра. Кабер өстендә доганы исә Фатих Әмирханның этисе Зариф хәзрәт Әмирхан укый.

Тукайның үлеменә бәйле рәвештә, сәүдәгәрләр шактый отышлы «бизнес» та оештыра. Мәсәлән, шагыйрьне соңгы юлга озаткан көнне Казан кибетләрендә чәчәкләр сатылып бетә. Ә инде өч атнадан Тукайның шигырьләрен граммофон тасмасына яздырып сата башлыйлар. Озакламый «Габдулла Тукай» исемле сабын да сатуга чыга. Аның бәясе ун тиен була. Нәширләр дә читтә калмый: китаплар бастыралар, шагыйрь сурәте белән тәбрикнамәләр ясыйлар. Хәтта шагыйрь сурәте төшерелгән конфетлар да пәйда була. Әлеге конфетларны Казан сәүдәгәре Вәлиулла Ибраһимовның «Альфа» кондитер фабрикасы чыгара.

Тукай соңгы көннәренә кадәр иҗат итә, шуңа да үләр алдыннан да нәширләрдән шактый акча аласы кала. (Һәр шигыре өчен илле тиен көмеш яки алтын белән түләнә.) Тукай шул акчаның 500 сумын ике сәләтле татар баласын рус уку йортларында укытыр өчен сарыф итәргә дип васыять итә. Үзе исемендәге стипендия булдыру теләген әйтә. 1913 елның 7 апрелендә «Йолдыз» газетасында бу стипендия фондына акча җыю турында игълан да басыла. Әмма оештыру эшләре барып чыкмый.

Хәтта Бөек Ватан сугышы барганда да халык Тукайны онытмый. 1943 елда шагыйрьнең вафатына утыз ел тулган көнне зурлап билгеләп үтәләр.

Бүген дә Тукай исеме еш яңгырый. Тукай исемен чит төбәкләрдә, хәтта чит илләрдә очратабыз. Казан, Уфа, Йошкар-Ола, Чиләбе, Ижау кебек Россия калаларында, Ташкент, Нукус, Әнкара, Алма-Атада Тукай исемен йөрткән урамнар бар. Аның исеме белән аталган сквер, бульварлар да шактый. Казахстанның Сәмәй шәһәре, Төркиянең Истанбул, Әстерхан, Мәскәүдә, Казанда һәйкәлләр куелган.

Казанда, Арча районының Яңа Кырлай авылында, Казахстанның Уральск шәһәрендә музейлары эшли.

Тукай исеме Казан аэропортына, ТР Дәүләт филармониясенә, Уральск типографиясенә бирелгән. 1958 елдан башлап гамәлгә кергән Дәүләт премиясе дә Тукай исемен йөртә.

Габдулла Тукай дуслары Фатих Әмирхан (беренче рәттә), Гафур һәм Каюм Коләхмәтовлар белән. Казан. 1912 ел.*

* Фотолар "Тукайга сәяхәт" китабыннан алынды

О. Н. Вишняковның «Сходка» картинасы фрагменты, фото: историческая-самара.рф



ИНКЫЙЛАБКА БЕРЕНЧЕ АДЫМ

1887 елның 4 декабре. Казан университетында студентлар җыены бара. Анда катнашучы беренче курс студенты **Володя Ульяновка** – нибары 17 яшь.

«Кыскарак буйлы, төптән нык, кыска муенга утырган зур башлы, җирән кашлар астында кечерәк кенә хәйләкәр күзләр – тышкы кыяфәте бер дә игътибар җәлеп итә һәм ышандыра торган түгел». Табигать фәннәре факультетының 4 нче курс студенты, сходканы төп оештыручы булган Евгений Чириков Володя Ульяновны әнә шулай искә ала.

– Бу бит теге асылган кешенең энесе! – дип, бер-берсе белән пышылдаша студентлар, университет коридорында Володяны күргәч. Утыз елдан соң кыскарак буйлы әлеге егетне «дөнья пролетариаты юлбашчысы» дип атаячакларын алар күз алдына да китерә алмый.

17 яшь

«ПЕШЕКЧЕ БАЛАЛАРЫ ТУРЫНДА»

Владимир Ульянов Казан университетының юридик факультетында озак тоткарланмый – 1887 елның августыннан алып декабренә кадәр генә укый ул. Кызыклы факт: сентябрь аенда студент укыган өчен түләүдән азат ителә. Университет идарәсе аның шул хакта үтенечен канәгатьләндерә, югыйсә тарихчылар гаиләнең шактый тыйнак тормышта яшәсә дә, хәерче хәлдә булмаганын раслый. Үтенечнең төп сәбәбе Владимирның туганнарыннан бәйсезлеккә омтылышы булгандыр, мөгаен. Ә белем йорты ягыннан егеткә карата мәрхәмәтлек сәбәбе укудагы казанышларына бәйле. Хәер, бу хәерхаһлы мөнәсәбәт Ульяновка, университетның гамәлдәге уставына һәм халык мәгарифе министрының яңа циркулярына каршы булган студентлар төркеменә кушылып, үзенең рәхмәтен ачунәфрәткә алыштырырга комачауламый.

«Пешекче балалары турында циркуляр» – студентлар документка әнә шундый исем таккан. Әлеге «циркуляр» укыган өчен түләү хакын берничә тапкыр күтәрә, ә кер юучы, кучер, пешекче, лакей балалары өчен университет ишекләрен бөтенләй ябып куя. Баш күтәрүләр, ризасызлык җыеннары, дулкын булып, бөтен ил буенча уза һәм 1887 елның 4 декабрендә Казанга килеп җитә.

Сүз уңаеннан, узган гасыр дәвамында әлеге атаклы студентлар җыены тарихчыларның фикерләрен капма-каршы ике лагерьга бүлеп, төрле уйдырмаларга төренергә өлгерде. Берәүләр инкыйлаб юлбашчысы анда актив катнашучы һәм хәтта җыенны оештыручы булган дип саный. Башкалар исә, бу фикерне, йомшаграк әйткәндә, дөреслеккә туры килми дип белдерә.

Шулай итеп, араларында Ульянов та булган Казан университеты студентлары, ашыгыч җыелыш үткәрү өчен, ишекне ватып, актлар залына бәреп керә. Алар җыенны оештыру комитетын сайлый, җырлар яңгырата һәм вазгыятьне үзгәртергә өндәгән ялкынлы чыгышлар ясый. Баш күтәрүчеләр ректорның үзләре янына чыгуын таләп итә, тик аның урынына инспектор килеп, студентларны тынычландырырга тырыша. Инспекторның дорфа кыланмышына җавап итеп, яңагына кундыралар. Эшнең кызып китүеннән куркып, ректор Николай Кремлев студентлар янына керергә карар кыла һәм аларны, соңга калганчы, таралышырга үгетли...

ПРИНЦИПКА БАРГАНМЫ?

Бер тарихи фикергә ярашлы рәвештә, бинаны хәрбиләр чолгап алган, һәм студентларны тоткарлаганнар. Полиция төзегән активистлар исемлегендә Владимир Ульяновның исеме калын итеп астына сызып куелган, янына өч тапкыр тамга да төшерелгән, янәсе, аеруча тырышлык күрсәткәннәрдән. Икенче фикергә караганда, беркем дә кулга алынмаган – егетләрне профилактик әңгәмәгә генә чакырганнар. Барлыгы 39 кеше була, өстәвенә, Ульянов исеме җыенда пассив катнашучылар исемлегендә урын ала. Полиция күзенә ул «асылган кешенең энесе» буларак кына эләгә.

Активистларга Казаннан китәргә киңәш ителә. Ә менә университеттан куылу җәзасыннан берәү дә котылып кала алмый, чөнки укырга кергәндә һәркем «әгъза булып тормаска» һәм «катнашмаска» дигән таләпне үтәү турында имза куйган була. Кайбер тарихчылар, Ульяновның туган төбәге Кокушкинога сәфәрен сөрген дип атаган очракта да, ирекле сөрген дип билгеләү дөресрәк, дип саный, имеш, булачак юлбашчы, баш бирергә теләмичә, принципка гына барган. Әмма аның «хәрби чирканчык» алуы һәм инкыйлабка беренче адымының Казан белән тыгыз бәйләнгәнлеге беркемдә дә шик уятмый.

– КФУ ПЛАННАРЫНДА – ЛАТИН АМЕРИКАСЫ, АФРИКА, ҺИНДСТАН ҺӘМ КЫТАЙ МӘГАРИФ БАЗАРЫНА ЧЫГУ

Казан федераль университеты һәрвакыт трендта калырга һәм чыннан да халыкара университет булырга мөмкинлек бирүче эшчәнлегендә гаҗәеп сыгылмалылыгын бөтен дөньяга күрсәтә. КФУ эшендәге үзгәрешләр, дөнья күләмендәге тәртипне үзгәртеп кору шартларында белем бирү программаларына ихтыяҗны саклау принциплары турында КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры **Рамил Хәйретдинов** сөйләде.

БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАЛАРЫН ЭКСПОРТЛАУ – ӨСТЕНЛЕКЛЕ ЮНӘЛЕШ

Соңгы елларда КФУ лаеклы рәвештә халыкара университет статусына ия булды. Бүген вузда дөньяның 100дән артык иленнән килгән 10 меңнән артык чит ил студенты белем ала. Әлбәттә, университетның максаты чит ил студентларын үзендә укырга җәлеп итү генә түгел, ә тулы кыйммәтле белем бирү программаларын экспортлау да – челтәрле мәгариф системасы һәм төрле телләрдә ике диплом бирү программалары системаларын булдыру аша белем бирүне глобальләштерү. Бу үзгәрүчән тышкы шартларга: пандемиягә, халыкара мөнәсәбәтләр системасын глобаль үзгәртеп коруга һәм хәзерге заманның теләсә нинди башка таләпләренә карамастан, КФУда укуга һәрвакыт ихтыяҗ тудыра торган бердәнбер дөрес юл.

ҮЗӘК АЗИЯ – МӨҺИМ ПАРТНЕР

Бүген Үзәк Азия белән хезмәттәшлек безнең игътибар үзәгендә. КФУда Үзәк Азия югары уку йортлары белән стажировкалар, квалификация күтәрү программалары форматында академик мобильлек җәйга салынган. Бүген челтәрле белем бирү һәм ике диплом бирү программаларын үстерү көн үзәгендә тора. КФУ вәкилләренең Казахстанга, Кыргызстанга, Үзбәкстанга һәм Таҗикстанга сәфәрләре вакытында моңа тиешле нигез салынды.

Аерым алганда, Ташкент дәүләт көнчыгышны өйрәнү университеты, Низами исемендәге дәүләт педагогика университеты, «Дипломат» университеты, Сәмәрканд дәүләт университеты, «Ефәк юлы» халыкара туризм университеты, Бохара дәүләт университеты белән уртак белем бирү программаларын эшләтеп җибәрү турында килешүгә ирешелгән инде. Мәгариф өлкәсендә үзара мәнфәгатьләр өлкәләре арасында тарих, археология, лингвистика, туризм, мәдәни мирасны саклау, цифрлы дипломатия, икътисад юнәлешләре бар. Уку-укыту программалары планнары төзелә, аларны 2023 елга эшләтеп җибәрү планлаштырыла.

ДӨНЬЯ ТЕЛЛӘРЕНӘ КҮЧҮ

Берничә уртак белем бирү программасы баштан ук инглиз телендә төзелде. Шул рәвешле без белем бирүне дөньяның башка төбәкләренә дә экспортлау өчен нигез салабыз: КФУ Латин Америкасы, Африка, Һиндстан һәм Кытай мәгариф базарларына чыгуны планлаштыра. Үзәк Азия югары уку йортлары белән үзара бәйләнештә мондый программаларны оештыруның барлык процессларын җайлаганнан соң, бу тәҗрибәне башка илләргә тарату кыен булмаячак.

ТАРМАКЛАНГАН ФИЛИАЛЛАР ЧЕЛТӘРЕ – КИЛӘЧӘК ӨЧЕН НИГЕЗ

Мәгариф экспортының тагын да зуррак мөмкинлекләрен формалаштыру өчен Үзәк Азия республикаларында КФУ филиаллары челтәрен оештыру эше башланды. Аерым алганда, Үзбәкстандагы Җизаг шәһәрендә КФУ филиалын ачарга әзерләнәбез. Университет филиалын нәкъ менә шушы шәһәрдә ачу – Үзбәкстанның үз тәкъдиме. Казан университеты төбәктә югары квалификацияле белгечләргә булган ихтыяҗны канәгатьләндерә алачак.

Филиалда белгечләрне әзерләү юнәлешләренең иң перспективалы булганнары сайланды: IT-технологияләр дә, табигый фәннәр дә, гуманитар блок та бар. Безнең институт лингвистик юнәлеш буенча тәкъдим ителде: без Европа һәм көнчыгыш телләрен белүче белгечләр әзерләячәкбез. Белем бирү процессының бер өлеше КФУның төп вузы территориясендә узачак.

Төп вузда укучы студентлар Үзбәкстанга практикага бару белән дә кызыксына. Безнең студентлар үзләрен бу илдә уңайлы хис итә, Татарстанда шундый ук дуслык-татулык мохите хөкем сөрә, шул исәптән үзбәк студентларына карата да. Филиаллар булдыру тәҗрибәсен киләчәктә дөньяның башка илләренә дә таратырга мөмкин булачак.

Фото КФУ матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

ИҢ ЯХШЫ ТӘҖРИБӘ СИНТЕЗЫ

Россиядә яхшы югары уку йортлары күп, тик, ышаныгыз, Мәскәүдәге, Петербургтагы югары уку йортлары күп юнәлешләр буенча бездән өстен түгел. Без фән дөньясы өчен ябык түгел, илнең алдынгы академик үзәкләре белән хезмәттәшлек итеп, бу яктан һәрвакыт алдынгы сафта барабыз. Белем бирүне генә түгел, фәнни эшчәнлекне дә югары дәрәҗәдә үстерү – Казан федераль университетының, аерым алганда, Халыкара мөнәсәбәтләр институтының аерым бер үзенчәлеге.

Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институты – безнең уку йортының иң зур бүлекчәләреннән берсе. Әзерлекнең 13 юнәлеше буенча без 6000нән артык студентны укытабыз, шуларның 1000нән артыгы – чит ил гражданы, аларны 12 юнәлеш буенча әзерлибез. Россия һәм чит илләрнең әйдәп баручы югары уку йортлары тәҗрибәсенә таянып, уникаль белем бирү структурасын булдырдык.

Чит ил студентлары өчен Казан федераль университетының белем бирү программалары «бәя – сыйфат» нисбәте буенча да кызыгырлык. Эш шунда ки, Мәскәү һәм Санкт-Петербургның белем бирү программаларына бәяләр бер ел өчен 400 мең сумнан башлана, без исә ата-ананың керем дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә, барлык талантлы балалар да сыйфатлы белем алу мөмкинлегенә ия булырга тиеш дигән принципка таянып эш итәбез.

УҢАЙЛЫ УКЫРГА КЕРҮ ШАРТЛАРЫ

Укырга керү тәртибе турында мәгълүматны һәр абитуриентка җиткерү өчен, мәгариф ярминкәләрендә белем бирү программаларын презентацияләүгә бәйле күпсанлы чаралар оештырабыз, алар онлайн-форматта да, офлайн да алып барыла. «Студент булам» дип аталган махсус системада теркәлеп, укырга керү процессы турындагы барлык кирәкле мәгълүмат белән шулай ук КФУ сайтында танышырга була.

Чит ил студентлары өчен кабул итү кампаниясе 1 марттан башлана һәм көз ахырына кадәр дәвам итә. Без бу мәсьәләдә абитуриентларны аңларга тырышабыз, чөнки җәй көне аларның күбесе үз илләрендә бюджет урыннарына кереп карый. Шуңа күрә чит ил абитуриентларын кабул итү берничә дулкында уза: августта, сентябрьдә, октябрьдә. Кайбер очракларда кызыксындырган юнәлешләр буенча ноябрьгә кадәр керү мөмкинлеге бар. Без абитуриентларны Казанда яки «Россотрудничество» мәйданчыкларында тапшырырга мөмкин булган керү имтиханнары аша да, шулай ук башка вузлардан күчерү системасы аркылы да кабул итәбез.

Бакалавриатны тәмамлаганнан соң, студентларның магистратура программасы буенча уку мөмкинлеге дә бар, өстәвенә, чиктәш юнәлешләрне сайларга була. Мәсәлән, «Лингвистика»дан соң «Халыкара мөнәсәбәтләр», «Халыкара туризм» яисә «Көнчыгышны өйрәнү һәм Африка» бүлекләрен сайларга мөмкин. Университеттан читтә яисә яшь галим, тикшеренүче, укытучы сыйфатында үзебездә үк эшли башлап, Татарстанда төпләнеп калырга була. Шул ук вакытта күп кенә белгечлекләр буенча укучы студентлар уку вакытында ук һөнәрләренә караган эшне табып, гамәлдә өстәмә компетенцияләр ия була. Без моңа каршы түгел, аңлыйбыз. Шул ук вакытта студентларның белем сыйфатына карата да иң югары таләпләр куела: бары тик югары квалификацияле белгеч кенә үз эшен сыйфатлы башкара ала. Һәм, әлбәттә, яхшы белгечкә үз ватанында ихтыяҗ зур, бу туган якларына кайтып һөнәри эшчәнлекләрен дәвам итәргә теләгән чыгарылыш курс студентларының саны артуы белән дә раслана.

ҺӘР ДЕТАЛЬГӘ ИГЪТИБАР БЕЛӘН

КФУда чит ил студентларын мондагы тормышка җайлау өчен дә күп нәрсә эшләнә. Мәсәлән, Халыкара мөнәсәбәтләр институтында инде күп еллар «ХМИ гаиләсе» дигән термин яшәп килә. Безнең бурыч – студентлар аралашуда әзерлек юнәлешләре, белгечлекләре яисә милләтләре буенча чикләнмәсеннәр өчен, аларны катнаштыру-таныштыру өчен шартлар тудыру. Студентлар арасында уртак чаралар уздыру нәтиҗәдә үзләренең КФУның теге яки бу институтында укуларын тойган-аңлаган бердәм җәмгыять оеша. Татарстан Республикасы Халыклар дуслыгы йорты белән берлектә бик күп чаралар үткәрелә, бу да ияләшү-җайлашу процессын җиңеләйтә.

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институтында укучылар, ким дигәндә, ике чит телне югары дәрәҗәдә үзләштергәнгә, төрле чараларда, волонтерлык программалары һәм проектларында аларга ихтыяҗ һәрвакыт бар. Дөньядагы бәйләнешләр тәртибен үзгәртеп кору нәтиҗәсендә барлыкка килгән чикләүләргә карамастан, чит илләрдә стажировка үтү программалары актив рәвештә гамәлгә ашырыла.

Безнең өчен һәр студентның шәхес буларак үзен күрсәтә алуы, күңеленә хуш килгән эш белән шөгыльләнү мөмкинлеген табуы мөһим. Без аңа тәкъдим итә алганнар белән генә түгел, ул үзе безгә тәкъдим итә алган шөгыльләр белән дә.

ЯМБУЛАТ ЕГЕТЕ

21 яшь

Семён Коновалов. 17 яшендә туган авылы Ямбулатта* почта тарата. 21дә – 16 немец танкын юк иткән «КВ-1» командиры. «Танк экипажы герой-командир лейтенант Коновалов белән бергә тигезсез сугышта һәлак булды», дип язачаклар бүләкләү кәгазендә. Әмма Герой Йолдызын Семён шәхсән үзе алачак...

Фото: ru.wikipedia.org, «Несокрушимый» фильмыннан кадр, 2018 ел.

* *Татарстанның Югары Ослан районындагы авыл*

Ростов өлкәсе, Нижнемитякин хуторы. 1942 елның 13 июле. Монда, хутордан ерак булмаган бер уйсулыкта, танк бригадасы сафтан чыккан «КВ»ны үзен генә калдырып китә - Семён Коновалов экипажы аны төзәтергә тиеш була. Бер тәүлектән соң разведка төркеме эшнең ничек баруын карар өчен кире килә. Алар күз алдында коточкыч картина ачыла... Асты-өскә әйләндерелгән, яндырылган «КВ» танкы – кыр уртасында, аның эчендә танкистларның үле гәүдәләре, тирәякта – сафтан чыгарылган немец танклары, бронемашиналар, йөк машиналары, үлеләр…

Берничә сәгать дәвам иткән сугыш картинасын торгызырга разведчикларга Нижнемитякинда яшәүчеләр булыша – бәрелеш алар күз алдында бара. Боларның барысын да батальон командиры Васильков соңрак бүләкләү кәгазендә язачак. Документларга караганда, экипаж танкын күренмәслек итеп яшерергә өлгерә. Күрәсең, разведкага чыккан ике немец бронемашинасы үзләре өчен берниндиә дә куркыныч сизми – бер танк тимертомыр өеменә әверелгәнчегә кадәр...

Куркынычны тоеп алган немец танклары тиздән һөҗүмгә күчә – 35 танк. Көчләр, әлбәттә, тигезсез, шулай да безнең экипажның котылу мөмкинлеге кала әле. Ләкин Коновалов башка карар кабул итә: каршылык күрсәтергә. «КВ»ның кайда яшеренгәнлеген фашистлар әле һаман белә алмый. Һәм экипаж, дошманны якынрак җибәреп, немец танкларына уңайлы ераклыктан ата башлый. Дүрт машина дөрләп яна, калганнары чигенә.

Немецлар, күрәсең, аларга берничә машина каршылык күрсәтә дип уйлый – икенче һөҗүмдә безнең «КВ»га каршы бер сафка тезелгән 55 танк чыга! «КВ» бер урыннан икенчесенә бик тиз күчеп йөри, аның тубы төз ата: тагын алты немец танкы юкка чыгарыла, калганнары чигенә.

Яңа атака. Дошман танкларына ярдәмгә пехота күтәрелә. Безнекеләр тагын алты танкны юкка чыгарырга өлгерә. Өстәп тагын бер броневикны, пехота белән берничә машинаны. Дөрес, снаряд тигән «КВ» хәзер инде урыныннан кузгала алмый. Моны сизеп алган дошман форсатны кулдан ычкындырмый: 105 миллиметрлы орудие китереп, 75 метрлы ераклыктан туп-туры совет танкына ата...

Бүләкләү кәгазендә – барысы да бик төгәл. Шулай да... Инде кузгала алмаган «КВ» танкына турыдан-туры ата башлаганчы, лейтенант Коновалов әмер бирергә өлгерә: соңгы снарядны тотып бетерергә һәм танкның аскы люгы аша чыгып качарга. Өчесе, шул исәптән Коновалов та, төн куелыгыннан файдаланып, танктан чыга ала.

Комбат Васильков – Герой исеменә бүләкләү документы тутырган, ә писарьлар кара кәгазь язган арада исән калган танкистлар фашистлар биләп алган территория аша безнең якка чыгарга омтыла. Беркөнне алар үз танклары янында рәхәтләнеп ял итеп яткан немецларны күреп ала. Аларны тиз генә юкка чыгарып, танкны алып китәләр. Инде немец танкында дошман колоннасына якын килеп, ата, таптый башлыйлар.

Аннан соң дошман танкында фронт сызыгын узып үзебезнекеләр ягына чыкканда могҗиза белән генә исән калалар. Немец танкын яулап алу эпизоды үзе генә дә бер бүләккә тарта, әмма моңа вакыт юк: куркак һәм сатлыкҗан булмауларын дәлилләргә кирәк. Бәхеткә, тикшерүләр озакка сузылмый, һәм тиздән Семён Коновалов тагын яуга китә: беренче айларда шул үзләре тартып алган трофей танкында сугыша...

Герой Йолдызын Коноваловка бер елдан соң гына диярлек – 1943 елда тапшыралар. Кыска вакытлы ял бирәләр. Туган өенең ишеген каккач, анасы озак вакыт ачмый тора: «Китегез, минем улым вафат, кара кәгазе килде…» Ялдан соң Семён Коновалов тагын фронтка китә һәм бик күп бәрелешләрдә катнаша. Сугыштан ул исән-имин әйләнеп кайта.

Ә 75 елдан соң, 2018 елда, илебез экраннарына «Несокрушимый» дип аталган фильм чыга. Төп герое – танк командиры Семён Коновалов.

МИНТИМЕРНЕҢ КОРЫЧТАЙ ЧЫНЫГУЫ

32 яшь

Егерме яшьлек өлкән курс студенты чирәм җирләрдә тәҗрибәле комбайнчылар белән беррәттән тир түгеп эшли. Өч елдан соң, туган ягында берничә ай эчендә Мөслим ремонт-техника станциясе баш инженеры итеп билгеләнә. 29 яшендә Ленин ордены белән бүләкләнә, ә 32 яшендә Татарстанның иң яшь министры була...

Казахстанның Павлодар өлкәсе. Биредә авыл хуҗалыгы институты студенты Минтимер Шәймиев чирәм җирләр сынавын уза. Ялан далада палаткалар урнаштырылган, берninди көнкүреш уңайлыклары юк, бары алны-ялны белмичә эшләү генә таләп ителә. Шәймиев – урып-җыю агрегатының өлкән комбайнчысы. Кулдашы – үзе кебек студент белән бергә көне буе эшләп шулкадәр арыйлар, төнлә йокларга гына кайтып егылалар, әмма сынатмыйлар, «Казан» маркасын югары тоталар. Мондагылар каршында да оят

Мөслимдә инженер булып эшли башлаган беренче ел. Минтимер Шәймиев – беренче рәттә, уртада. 1960 ел.

түгел: күрсәткечләр – иң яхшы хуҗалыклар дәрәҗәсендә.

Эштән йокларга гына туктап торалар, ярый әле ерakka йөрергә кирәкми. «Комбайн бункерына, ашлык әченә кереп ятасың да, йокыга киткәнче, бер мизгел очсыз-кырыйсыз күккә – Мәңгелеккә карыйсың...»*, – дип исенә төшерә Шәймиев үзенең чирәм җир күтәрү кыйссасын.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: чирәм җирләрне күтәрүдә егетләр ныклык, булдыклылык ягыннан гына чыныгу узмый. Алар атомтөш корылмалары сынала торган Семипалатинск өлкәсе чигендә эшли.

Киләсе җитди сынау инде укуын тәмамлап эшкә килгәч була. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, аны Мөслим ремонт-техника станциясенә эшкә җибәрәләр. Командада – үз эшен яхшы белгән чын осталар, инженер дипломлы яшь белгечне алар сагаеп каршы ала: үзен ничек күрсәтер, янәсе. Тик яшь белгеч бик төпле күренә, үзен башкалардан өстен куймый. Ә иң мөһиме, бернинди эштән дә борын чөерми. Сезонга остаханәләрне тәртипкә китерергә кушылгач, башкалар белән бергә кулына көрәк ала. «Үзебезнеке икән», – дип нәтиҗә ясыйлар коллективта.

Хәер, үзеңнеке булу эшнең яртысы гына, ә менә инженер буларак нинди? Минтимер Шәймиев эш белән җавап бирә: кышын машина двигателен эшләтеп җибәрү – тулы бер эпопея, ул процессны җиңеләйтү ысулын уйлап таба. Шоферлар яшь инженерны кулларында йөртергә әзер.

Яшь белгечнең идеяләре бихисап, энергиясе җиде кешегә җитәрлек. Менә ул иптәше белән механизаторлар әзерләү курслары оештыра, тагын фермаларны җылыту өчен калорифер конструкциясен уйлап таба: аны РТСның үзендә үк ясый башлыйлар. Авылда су каланчалары куярга карар кылалар, тик нәрсәдән? Шәймиев монда да югалып калмый. Предприятиеләр белән килешү төзеп, аларны зур диаметрлы торбалардан ясарга булалар.

Тынгысыз һәм булдыклы инженерны җитәкчелек тә күреп ала, билгеле. Аңа югарыга күтәрелүнең идеаль баскычын – колхоз рәисе вазыйфасын тәкъдим итәләр. «Юк, – дип җавап бирә Минтимер, – рәис буласым килми. Яраткан һөнәрем буенча эшлисем килә».

Мондый «баш тартучылар»ны, гадәттә, яратып бетермиләр, тик Минтимергә бу кагылмый: үз эшен артык яхшы белә. Мөслим районында эшли башлаганнан соң 9 ай узгач, Минтимер Шәймиевне баш инженер итеп билгелиләр.

1960 нчы еллар башы. Ил буенча бөтен җирдә «кырлар патшабикәсе» – кукуруз үстерелә башлый. Комсомол райкомы бюросы әгъзасы һәм баш инженер, әлбәттә, бу мөһим башлангычтан читтә кала алмый. Биредә дә Шәймиев эшкә иҗади якын килә. «Кукуруз игү технологиясендә иң мөһиме нәрсә? Басуда квадрат ясый белү. Ул заманнарда уңыш язмышын хәл итә торган иң кирәкле ысул... Әмма киң басуда квадрат ясау ансат эш түгел... Шуңа күрә мин үз ысулымны уйлап чыгардым. Ул чакта заводта эшләнгән тарттыру станцияләре куллана иделәр, алар нинди генә тайпылыш ясамасын – безнең квадрат төгәл килеп чыга иде», – дип сөйли Минтимер Шәймиев.

Нәтиҗәдә район республикада иң югары кукуруз уңышы ала, яңалык кертүченең исеме газета битләрендә ешрак пәйда була башлый, аны ВЛКСМның XIV съезды делегаты итеп сайлыйлар. Ә тиздән яңа биеклек яулана: Минтимер Шәймиевне Минзәлә районара «Сельхозтехника» берләшмәсе идарәчесе итеп билгелиләр. 25 яшь өчен – бу бик сирәк очрак.

Яңа вазыйфада ул үзен шулай ук чын белгеч итеп күрсәтә. Эшне үрнәк итеп оештыра, параллель рәвештә, үз инициативасы белән, җирле юлларны тәртипкә китерә башлый. Кул астындагылар яхшы эшләсен генә түгел, лаеклы яшәсен өчен дә тырыша ул...

Дистәләп ел узгач, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев: «Яшь җитәкчеләргә үз тәҗрибәмнән чыккан тормышчан киңәшем: үзегезнең карамакта эшләүче кешеләрне яратыгыз, аларның көндәлек мәшәкатьләре – сезнең мәшәкатьләрегезгә әйләнсен, ә кайчак хәтта башыгызны авырттырсын...» – дип язачак.

* И. Цыбульский һәм Н. Шәйдуллинаның «Минтимер Шәймиев» китабыннан алынган өзекләр файдаланылды.

ТОРМЫШНЫ ДӘРЕСЛЕКЛӘРДӘН ӨЙРӘНМӘСӘҢ

Гарвард, Йель яки Оксфорд университеты, бейсбол, Вегаста каникуллар... «Алардагы» сәясәтчеләрнең яшьлеге бик кызыксыз һәм сәясәтчеләрнең үзләре кебек үк тормыштан ерак. **Фәрит Мөхәммәтшинга** бөтенләй башка университетларны – чын тормышныкын узарга туры килә.

Шыплап бәрәңге утыртылган бакча. Алтмышынчы еллар башында бакча тоту яраткан шөгыль түгел, тормыш таләбе була: хезмәт хаклары әллә ни зур түгел, кибет киштәләре дә байлыктан сыгылып тормый. Өлкәннәр эштә, шуңа күрә унөч яшьлек малайга эш җитәрлек. «Егерме сутый, барысын да утыйсы, кәтмәнлисе, күмәсе бар. Әни эш кушып китә: «Төшкә кадәр өч бураэнаны эшлә, кайткач тикшерәм», – дип сөйли Фәрит Мөхәммәтшин бала чагындагы хезмәт тәрбиясе турында. Аның каравы, булачак сәясәтче крестьян хезмәтенең кадерен дә дәреслекләрдән түгел, ә үз тәҗрибәсеннән белә.

Бакчада эшләүне гап-гади җәмәгать эше дип атарга була, аның белән яшьтәшләрне шаккатыра алмыйсың. Каникулда эшкә урнашып, беренче акчаңны эшләп алу – менә монысы исә омтылуга лаеклы хыял. Тиздән ул да чынга ашачак. «Җәйгә эти мине ремонт-төзелеш идарәсенә урнаштырды, анда мин газоннарны уратып алыр өчен агач штакетниклар җыйдым. Борыс, такта, кадак – көне буе кадакла да кадакла». Җиденче сыйныфтан соң Мөхәммәтшинның җәе әнә шулай уза. Аттракционнар паркы түгел, тәүге хезмәт хакына сатып алынган беренче «Победа» сәгате һәм сеңелләренә бүләкләр – океан аръягындагы яшьтәшләренең паркта «американ» тавында элдерүе һәм этиләренең «Ролекс»ын тагып йөрүенә караганда күбрәк эмоция биргәндер, мөгаен.

21 яшь

Армиягә киткәндә, Фәрит инде җитдирәк хезмәт тәҗрибәсе туплаган була. Тугызынчы сыйныфтан соң чираттагы җәйге каникуллар вакытында хәтта геологик разведка хезмәтендә геодезист булып та эшләп ала. «Геодезистлар нефть мәйданнарын үлчи, мин исә репер линейкасын гына тотып торам», – дип, тыйнак кына искә ала ул бу эш тәҗрибәсе турында. Мәктәпне тәмамлагач, Миңлебай газ-бензин заводына токарь өйрәнчеге булып эшкә урнаша. Аннары – машина йөртүчеләр курслары...

Әлбәттә, хәрби хезмәткә кадәр шофер булып эшләргә өлгергән егет армиядә кухня тирәсенә елышмый. Үзйөрешле зенит җайланмалары белән идарә итү, Тоцкое полигонында өйрәнүләр... – чын тормыш мәктәбе диими, ни дисең... Мөхәммәтшинның нинди солдат булуын сөйләп торасы юк: частьнең Мактау китабына беркемнең дә исемен болай гына язып куймыйлар. Хәер, төп казаныш бу түгел, дип саный ул үзе. «Армия миңа чын ир-атлар дуслыгының нәрсә икәнлеген аңларга һәм аның кадерен белергә өйрәтте», – ди Фәрит Мөхәммәтшин.

Карьера үсеше күзлегеннән караганда, ике еллык хәрби хезмәттә шәп характеристикага лаек булган егеткә туп-туры юл – университетка. Тик ул вакытта карьера сүзе сүгенүгә тиңләнә диярлек: эш урынында тир түгеп хезмәт куйган кешеләр хөрмәттә. Мөхәммәтшин нәкъ менә шундыйлардан. Башкала вузларыннан бигрәк, көтмәгәндә кызыклы эшкә өстенлек бирә – «Әлмәтнефть»кә КИП слесаре булып урнаша. Ә мәҗбүри югары белем белән нишләргә? Анысы исә, гафу итегез, кичләрен генә – газ сәнәгате техникумында (соңрак – читтән торып Уфа нефть институтында). Ул арада Фәрит цехның комсомол оешмасы секретаре вазыйфасын да башкара, җәмәгать эше өчен каян вакыт табадыр – үзе генә белә.

Әлеге университетлары турында сәясәтче болай дип сөйли: «Ул вакытта КИП слесаре булу бик дәрәҗәле санала иде. Бу эшкә актив, эшкә сәләтле, шактый югары интеллектка ия яшьләрне алалар. Бик мавыгып эшләдек, һөнәри конкурсларда теләп катнаштык, төрле электрон нәрсәләрнең серенә төшенер өчен, сәгатьләр буе өйрәнеп утырырга әзер идек. Әмма бу мохит белән генә чикләнмәдек. Ул чакта бер-беребез белән аралашу, китап һәм музыка турында кызып-кызып бәхәсләшү, дөньядагы вакыйгалар карата, кайчак шактый беркатлы булса да, үз фикеребезне белдерү бик мөһим иде. Безгә шәһәр беренчелегенә футбол уйнау, ул вакытта популяр вокаль-инструменталь ансамбльләрдә җырлау кызык иде...»

«Без тормышны кулланырга гына гына түгел, ә чын-чынлап анда катнашырга теләдек, – дип әйтәчәк ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үзенең яшьлеге турында. – Үз шәһәребездә, үз цехыбызда, үз стадионыбызда».

Чит илләрдәге оппонентлары белән чагыштырганда, безнең сәясәтчеләрнең күп очракта сүзләре нигә үтемлерәк, ышандыру көче нигә куәтлерәк икәнен аңлатып тору урынсыздыр. Язмыш сикәлтәләрен шәхсән тоеп, турыдан-туры үзең кичкән тормыш мәктәбе белән Гарвард да, Йель дә, Оксфорд та һичкайчан тиңләшмәячәк.

* Монда һәм алга таба цитаталар һәм фотолар «Фарид Мухаметшин. Виражи судьбы» документаль повестеннан алынды.

Фото: ru-wikipedia.xyz, «Три мушкетёра» фильмыннан кадр, 2013 ел.

БЕЗНЕҢ ЕГЕТ

Моннан ун ел элек **Риналь Мөхәммәтов** һәм аның «Сары асфальт» медиапроекты буенча коллегалары «Кара инде» җырын яздыралар һәм «Евровидение»гә җибәрәләр. Милли көй сөючеләргә җавап килми. Әмма бу, хәер, киләчәктә популярлык казаначак актёрның музыкаль иҗатка тартылуына берничек тә тәэсир итми.

23 яшь

Якташыбызга беренче танылу 2013 елда «Три мушкетёра» фильмы чыкканнан соң килә. Режиссёры – Сергей Жигунов. Татарстандагы Алексеевское бистәсендә туып-үскән якташыбыз 23 яшьлек Риналь Мөхәммәтов анда Д'Артаньян ролен уйный. Фильмның экранга чыгуын салкын каршы алалар, әмма үзенчәлекле харизмага ия яшь актёрның сөйкемле елмаюын тәнкыйтьчеләр дә, тамашачылар да истә калдыра. Ринальнең чынлыкта экрандагы (китаптагы) герой кебек үк әз генә тотлыгуы да мушкетёрга үзенчәлекле фырткылык өсти.

«Гомерем буе тотлыгу белән көрәшәм!» – ди артист үзенең бер әңгәмәсендә. Әлеге көрәш аның язмышында күп нәрсәне хәл итә. Бүген Мөхәммәтовның портфолиосында төрледән-төрле кино һәм театрда уйналган берничә дистә роль, аларда сөйләм телендәге җитешсезлек бөтенләй сизелми. Әмма 1990 нчы еллар ахырында кечкенә генә бистәдә туып-үскән, җитмәсә тотлыгуы да комачаулаган егеткә үзенең иҗади мөмкинлекләрен күрсәтү җиңел булмый. Үсмернең иҗатка омтылышын кайчандыр район мәдәният йорты сәхнәсе йолдызы булган бабасы хуплый.

Алексеевскидан МХАТ сәхнәсенә менү – гаять көчле сикереш. Күпмедер дәрәҗәдә Ринальгә әлеге дә баягы тотлыгуы ярдәм итә. Театр сәхнәсендә карьера төзүгә җөрьәт итмәгән егет, мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан театр училищесының эстрада-цирк бүлегенә укырга керә. Леонид Енгибаров иҗатына сокланып, Риналь дә клоун булырга хыяллана башлый. Әмма бервакыт ул көтмәгәндә генә күренекле режиссёр Кирилл Серебренниковның студиясенә укучылар кабул итүе турында ишетеп ала. Риналь тәвәккәлли – һәм керә. Ул чакта бер урынга 400 кеше туры килгән, дип сөйлиләр.

Ун ел эчендә Мөхәммәтов Серебренников спектальләрендә Бондарчук блокбастерларында, тагын берничә популяр сериалда уйнарга өлгерә. «Мушкетёр»лар кебек үк, әлеге проектларның күбесен тамашачылар аңлап җиткерми һәм кабул итми кала. Әмма бу Ринальне артык борчымый. Үзен ул һөнәри яктан үсәргә мөмкинлек бирә һәм битараф калдырмый торган фильмнарда уйныйм, дип саный.

2018 елда экранга «Временные трудности» картинасы чыга. Реаль вакыйгаларга нигезләнеп ясалган ДЦП диагнозлы малай турындагы фильм ул. Анда әти кешенең диагнозны таныргa теләмичә, малайны кырыс һәм газаплы күнегүләргә дучар итүе турында сөйләнә. Малай үсә һәм Россиядә иң күренекле маркетологларның берсенә әверелә. Фильмда төп рольне Риналь Мөхәммәтов уйный. Җәмәгатьчелек «Временные трудности» фильмын авыр кабул итә, фильм төшерүчеләрне көч куллануны пропагандалауда һәм әлеге диагноз куелган кешеләрнең проблемаларын бөтенләй аңламауда гаепли. «Минем өчен героем гына мөһим иде. Мин аның үсешенә, үҗәтлегенә, үз-үзе белән көрәшенә сокландым», – дип сөйли Риналь бер әңгәмә вакытында.

Быелдан актёр «Подари жизнь» фонды химаячесе булды. Күптән түгел генә аның сүзләренә һәм музыкасына төшерелгән «Запах эвкалипта» клибы дөнья күрде. Төп рольләрдә Риналь әлеге фонд ярдәме күрсәтелә торган 14 яшьлек малай белән кызны төшерә.

Мөхәммәтовның иң танылган рольләренең берсе – Бондарчукның «Притяжение» фильмындагы Хэкон роле. Башка галәмнән килгән Хэкон үзенең сөйгәне – Җир кызы Юлияне коткару өчен үзен корбан итә. Үз юлы белән баручы, һәр яңалыкка ачык, һәрвакыт музыка, театр һәм кинодагы рольләре белән экспериментлар ясарга яратучы Ринальнең үзенә дә ниндидер башка планета сыйфатлары хас кебек. Әңгәмәләренең берсендә ул мондый фикер дә әйтә: «Әгәр клоуннар биргән интервьюларга игътибар итсәгез, алар мәхәббәт турында күп сөйли. Шуңа күрә мин актёр булуга караганда, күбрәк клоун, ахрысы».

Фото: ru.wikipedia.org, © Солтан Исхаков, «Татар-информ» МА.

ТАУ БАТЫРЫ

Данил Садриев. Җирән чәчле, малайларча кыюлыгы, тәвәккәллеге әллә каян күренеп тора. Трамплиннан сикерү белән шөгыльләнүче Россия спортчыларының киләчәге турында сорагандa ул конкрет җавап бирә: «Искиткеч!» Ул болай әйтергә хаклы, чөнки Садриев 2022 елда Пекинда узган Олимпиадада көмеш медаль яулый.

18 яшь

Олимпиадада призёр булганда Данилга әле унсигез тулып кына киткән була – әле ике ел элек «Азия балалары» турнирында чыгыш ясаган иде. Сүз уңаеннан, анда Данил җиңүгә ирешә. Ләкин Олимпиада, бигрәк тә спортның трамплиннан сикерү төре, – бик җитди, тәвәккәллек сорый торган гамәл, яшькә карап тормый. Һәм Данил ниндидер ташламаларга өметләнми дә: ярышның башыннан алып ахырына кадәр җитдилек, һәрбиләрчә кырыслык йөзенә чыккан – бернинди елмаюлар да юк. Дөрес, көндәшләр дә әлегә аны исәпкә алмый – бигрәк яшь бит. Дөнья элитасында өченче сезон ярыша, беренчеләрнең берсенә дә киртә булганы юк, Дөнья кубогында 12 нче урын – зурлар арасында иң яхшы нәтиҗәләр шундый.

Исәпкә алмыйлар – Пекиндагы беренче чыгышларга кадәр. Биредә, уртача трамплинда, Лениногорск егете беренче кечкенә генә могҗизасын ясый. Квалификациядә, трамплин рекорды куеп, 107,5 метрга сикерә – башкалар ничек кенә тырышмасыннар, куып җитә алмыйлар. Финалга дүртенче булып чыга, ә ярыш нәтиҗәсе буенча планетаның сигез иң көчле сикерүчеләре арасына керә. Дебютант өчен – искиткеч нәтиҗә. Бигрәк тә соңгы утыз ел эчендә Россия спортчыларының финишта каядыр икенче дистәдә урнашуына инде ияләшкән булуыбызны күздә тотканда...

Әмма белгечләр күзлегеннән караганда моны уңыш дип санасак та, Данил өчен бу хаталар өстендә эш була... Күбрәккә ирешәсе килә. «Әле Олимпиада алдыннан, Австриядә әзерлек вакытында, мин бер нәрсәне аңладым: барысы да чынга ашарга мөмкин, – дип сөйли ул журналистларга. – Тиешле техник тәэсирләрне тойдым. Дөресен генә әйткәндә шәхси ярышларда зуррак нәтиҗәләрне көткән идем...»

Бу сүзләрне Данил Садриев Олимпиаданың көмеш бүләгенә ия булгач әйтә: шәхси турнирда ала алмаганны команда белән бергә алуга ирешә (әлеге көмеш медаль 54 елдан соң безнең спортчылар тарафыннан Олимпия уеннарында трамплиннан сикерү буенча яуланган беренче бүләк булды). Биредә, ниһаять, таудай җаваплылык өстеннән төшкәч, яшь спортчы камера һәм микрофоннар каршында безнең спортчыларның киләчәге турында бер сүз белән «Искиткеч!» диде.

– Менә күрерсез әле, якын елларда, тагын бер-ничә егет үзен күрсәтәчәк, – дип аңлатты журналистларга Татарстан егете, бәхетле елмаеп.

– Димәк, бу медаль сезнең өчен сенсация түгел?

– Сенсация, әлбәттә, сез нәрсә?! Мин әзер идем, әмма шулай булачагын төгәл белми идем...

Үз-үзеңә ышанганлыкмы? Яшьләрчә мактанчыклыкмы? Данилны яхшы белгән беренче тренеры Николай Герасимов, мөгаен, аны башкалардан яхшырак, төгәлрәк сыйфатлыйдыр. Ныклык, үҗәтлек. Үз-үзенә ышаныч. Мавыгучанлык...

Һәрхәлдә, Пекинда Данил ирешкән уңыш бернинди дә очраклылык түгел. Әлеге медальгә беренче адымны ул алты ел элек, олы абыйсы шөгыльләнә торган трамплиннан сикерүчеләр секциясенә килгәч ясый. Яшьтәшләре балалар бакчасында көндезге йокыда булса, Данил чираттагы тренировкасына бара.

Тагын бер адым – башкалар унбиш яшьләр тирәсендә генә сикерергә тәвәккәлләгән Лениногорскидагы 75 метрлы трамлинны уникe яшендә яулау. Аннан соңгы елларда исәпсез-хисапсыз тренировка, әзерлек һәм ярышлар арасында төннәр буе һәм елларда мәктәп предметларын тырышып-тырышып өйрәнгәндә...

«Азия балалары»ның күптән түгелге җиңүчесе – бүген инде атказанган спорт мастеры һәм «Ватан каршындагы казанышлар өчен» ордены медале иясе. Гәрчә яше буенча һаман әле юниор саналса да. Олимпия уеннарының призёрының киләчәге искиткеч булырмы – барысы да аңардан тора.

– Дөнья йолдызлары дәрәҗәсендә эшли, шуңа күрә тиешле тырышлык куйганда озак еллар биеклектә торырга мөмкин, – дип саный Николай Герасимов.

Данил тренерның йөзенә кызыллык китерергә ияләшмәгән. Март ахырында ил чемпионатында аңа тиңнәр булмады... Т

КИТАП К

ТИМУР СӨЛӘЙМАНОВНЫҢ КИТАП КИШТӘСЕ

Бер үк вакытта ничек тәвәккәл дә, ярдәмчел дә булырга? Ничек итеп һәрвакыт алгарышның башында булып, куйган максатларыңа ирешергә, шул ук вакытта үзеңнең килеп чыгышың, ата-бабаларың һәм төп кешелек сыйфатлары турында онытмаска? Мондый катлаулы сорауларга җавапларны Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов китаплардан ала. «Алар минем өчен белем чыганагы гына түгел, автор белән үзенә күрә әңгәмәгә чакыру да, хәтта ниндидер медитация дә», – ди ул, алдыбызда күпләргә таныш китаплар тупланган шкафын ачып.

БАЛАЧАКТА ҺӘМ ЯШЬЛЕГЕМДӘ МИҢА ТӘЭСИР ИТТЕ...

Әлбәттә, балалар классикасы! Мәсәлән, Марк Твенның Том Сойер маҗаралары турында китаплары яки Александр Волковның «Волшебник изумрудного города» дигән экияти повесте. Бигрәк тә инглиз язучысы Энид Блайтонның «Секретная семёрка» дип аталган балалар өчен детективлар циклы миндә якты хисләр уятты. Бик мавыктыргыч серия! Шуның белә рухланып, мин хәтта Кызыл Чишмә авылындагы йортыбыз янында үскән зур талда штаб та корган идем – нәкъ «җиделек» геройларыныкы кебек!

Балачакта яраткан тагын бер китабым – Норвегия язучысы Анне-Катарина Вестли иҗат иткән «Папа, мама, восемь детей и грузовик» китабы. Ул бер зур гаиләнең тормышы турында. Мәнә аның геройлары авылга юл тота, мәнә аларда эт пәйда була – беренче карашка, көндәлек тормыш вакыйгалары, ләкин алар турында уку шулкадәр рәхәт, якын иде. Китапны миңа әниемнең Уфада яшәгән апасы бүләк итте. Бу басманы кулыма алган саен, әнә шул шәһәр образлары күз алдына килә иде.

Бераз өлкәнрәк яшьтә мин бик күп фәнни-популяр әдәбият укыдым. Шундый китапларның берсе – «Физика будущего». Анда галим Митио Каку якындагы йөз елда технологик үсешебезнең нинди булырга мөмкин икәнлеге турында уйлана. Ә бервакыт икътисад буенча олимпиадада белгечләрнең берсе безгә финанс грамоталылыгының һәм эшмәкәрләрчә фикерләүнең мөһимлеге турында Роберт Кийосаки һәм Шарон Лехтернең

«Богатый папа, Бедный папа» китабын укырга киңәш итте. Яхшы китап, мин аны әллә ничә укып чыктым.

СОҢГЫЛАРДАН ХӘТЕРГӘ УЕЛГАНЫ...

Күптән түгел Кай Фу Линың «Сверхдержавы искусственного интеллекта» китабын укып чыктым. Бик кызыклы һәм актуаль китап. Автор төрле илләрнең ясалма интеллектны өйрәнү өлкәсендәге тәҗрибәләре турында сөйли, хәзерге заманда һәм киләчәктә кешеләр белән роботларның үзара мөнәсәбәтенә һәм кешелеклелеккә кагылышлы мөһим сорауларны куя. Төрле илләрнең уңыш серләре һәм көндәшлеккә сәләтлелеге темасына кагыла, дәүләт куркынычсызлыгы проблемаларын күтәрә һәм аларны ясалма интеллектны үстерү аша чишү турында уйлана. Китапта ясалма интеллектны үстерүдә алдынгылыкны гомумән үз милли идеясе дип игълан иткән Кытайның бу өлкәдәге кызыклы тәҗрибәсе искә алына. Кай Фу Ли әлеге юнәлештә алга барган эре компанияләрнең үрнәкләрен китерә, халыкта

Фото: Александр Ефремов

ИШТӘСЕ

IT-юнәлештә эшмәкәрлек рухын формалаштыру өчен, тулы бер шәһәрләрнең үзгәртеп корылуын сурәтли.

«Китап – иң яхшы бүләк» дигән атаклы гыйбарәне хәтерлисезме? Минем өчен ул актуальлеген югалтмады. Туган көнемә шундый бүләкләрнең берсе «Атомные привычки» китабы булды. Юк, ул физика турында түгел. Ул үзеңдә яхшы гадәтләрне ничек булдырырга һәм начарларыннан ничек арынырга мөмкин икәнлеге турында. Аның авторы Джеймс Клир әлеге механизмны эре компанияләр һәм төрле илләрнең нәкъ менә дөрес гадәтләр формалаштыру бәрабәренә бик зур уңышларга ирешкән спорт җыелма командалары мисалында җентекләп ачып бирә. «Тамчыдан күл җыела» гыйбарәсенә яшеренгән бу идея даими хәрәкәттә булуны күздә тота, синең бүгенге уңышыңның әллә ни зур булмавы мөһим түгел. Кечкенә адымнар белән алга барып, акрынлап үз максатыңа якынаюың әһәмиятле. Системалы үзгәрешләр тектоник күчеш кебек. Аларны башта гади күз белән күрә дә алмыйсың. Һәм алар ниндидер очраклы хәл булып тоела, ә чынлыкта – көндәлек четерекле хезмәт нәтиҗәсе ул.

ӘЛЕДӘН-ӘЛЕ КИРЕ КАЙТЫП...

«Маленький принц»ны рәхәтләнеп кабат-кабат укыйм. Антуан де Сент-Экзюпери бик тормышчан әкият-повесть язган. Иң мөһим кешелек сыйфатлары турында ул.

Кайтып-кайтып яңадан укырга яраткан тагын бер китабым – Ричард Бахның «Чайка по имени Джонатан Ливингстон» дип аталган гыйбрәтле повесте. Берьюлы күп мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә торган ыгы-зыгылы көндәлек тормышымда минем өчен ул үзенә күрә медитация кебек. Бу китапларның икесе дә миңа үз дөньяма чумарга, эчке халәтемдә гармония булдырырга ярдәм итә, чөнки алар мәңгелек кыйммәтләр турында! Бу китапларны сине кирәкле вибрацияләргә алып китә торган камертонга тиңләргә була.

ЯРАТКАНЫ

Бу бик шәхси нәрсә. Әтинең шигырьләр җыентыклары (Татарстан Фәннәр академиясе академигы, «Сәләт» яшьләр проектының инициаторы Җәүдәт Сөләйманов – ред. иск.) ул, алар һәрвакыт янымда. Мәсәлән, аның күптән түгел дөнья күргән «Каталон дәфтәрләре» китабы. Мин бу шигырьләргә еш күз салам. Бу – үзенчәлекле фәлсәфә, өстәвенә әти белән телефоннан гына түгел, ә китап аша да сөйләшеп алу мөмкинлеге.

КӘГАЗЬ КИТАПМЫ ЯКИ ЭЛЕКТРОННЫМЫ?

Һичшиксез, кәгазьдә! Безнең чынбарлыкта, эш дөньясында әйләнә-тирәбез электрон нәрсәләр белән шыплап тулган. Ә менә кәгазь томлыкны кулыңа алуга, ул, әйтерсең, сине башка дөньяга – үз галәмеңә чакыра. Һәм син үз-үзең һәм бу китапны язган кеше белән гәп кору өчен шунда юл тотасың.

МИНЕМ ӨЧЕН КИТАП НӘРСӘ УЛ?

Беренче чиратта, китап – белем хәзинәсе ул. Ә аларның чыганагы – кайчандыр яшәп, кәгазьгә үзләренең зур тормыш тәҗрибәсен салып калдыра алган кешеләр. Димәк, китап – бер үк вакытта кеше дә, бөтен галәм дә. Ә тагын – мантра даһәм, телисез икән, чын медитация дә. Баш мие һәм күңел өчен ризык та.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

...Юваль Ной Харариның «Краткая история человечества» китабын. Бик кызыклы ул. Автор безнең цивилизация турында яза. Ә үз бәянен моннан 13 млрд ел элек булган вакыттан, Галәм барлыкка килгән мизгелдән башлый. Безне бик борчый торган бүгенге сорауларга еш кына тиз җавап алырга телибез. Ни өчен хәзерге вакыйгалар башкача түгел, нәкъ менә шушы тәртиптә бара? Әмма бу җавапларны табу өчен тарихның гомуми контекстына – югарыдан, глобаль дәрәҗәдә карарга кирәк. Һәм Юваль Ной Харариның китабы моны эшләргә мөмкинлек бирә.

ӨМЕТНЕ АКЛАМАДЫ...

Кагыйдә буларак, мин киштәдәге теләсә кайсы китапны алып укымыйм, шуңа күрә күңел кайтулар булмый. Дөньяда укыйсы килгән китаплар шулкадәр күп! Шулай булгач, синең күңелеңә хуш килмәскә мөмкин китапка ник вакыт әрәм итәргә, ди? Еш кына киңәшләргә колак салам. Кайчак теге яки бу китапның әлегә «минем теш үтәрлек түгел» икәнлеген танырга туры килә. Мәсәлән, кайчандыр мәктәп программасындагы әдәбият белән әнә шулай булды. Хәзер аңа кире кайту теләге туа.

КИҢӘШ ИТӘМ!

«Незнайка на Луне» китабын кабат укып чыгыгыз! Балачакта Николай Носовның бу китабы читтә калган. Ә хәзер улым белән бергә укып, ул вакытта кулга кермәгәнне эләктереп калырга тырышам. Автор аны балалардан бигрәк, әти-әниләр өчен дә язган дигән хис туа миндә. Даһи әсәр! Китап көн кадагына туры китереп язылган һәм бүген дә актуальлеген югалтмаган.

Шушы көннәрдә Россия Тышкы эшләр министрлыгының рәсми вәкиле Мария Захарова «1984» романы турында әйткән сүзләрне укыдым: «Без күп еллар Оруэлл тоталитаризмны тасвирлаган дип йөрдек. Бу – глобаль фейкларның берсе. Оруэлл либерализмның ахыры турында язган...» Бу романны тагын бер кат укып чыгу теләге туды. Студент елларында аның миндә бик якты хисләр уятканын хәтерлим әле. Шуңа күрә Джордж Оруэллның «1984» китабын мин, барыннан да элек, үземә укырга киңәш итәм.

Акциянең срогы 2022 елның 16 маеннан 2022 елның 20 сентябренә кадәр. Заявкалар 2022 елның 15 августына кадәр кабул ителә. Оештыручы «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+.
Товарлар рәсемдә тәкъдим ителгәннән аерылырга мөмкин.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР /

Бу санда тәкъдим итәбез:

НИНДИ иске-яңа фильмнар карарга була

Таҗетдин Ялчыгол татар мәдәниятендә **НИНДИ** эз калдырган

Түбән Ушмы башка авыллардан **НӘРСӘСЕ** белән аерылып тора

«Каравон» **НИЧЕК** Татарстан брендына әйләнде

УЛ БЕЗНЕ КАБАТ ЭЗЛӘП ТАПТЫ...

Луиза Янсуар

Җәйге еллар – вакытны үзеңә күбрәк билгеләр өчен кулай чак. Ел дәвамында «карармын» дип тамгалап куйган фильм, сериалларны карап, «укырмын» дигән китапларны укырга мөмкинлек табып, мәсәлән. Ә яңаларына килгәндә, алар арасында да кинәнеп карарлык, йә укырлыклары җитәрлек.

ПОДОЗРЕНИЯ, 2004 (1 СЕЗОН)
Иле: Франция
Жанры: документаль сериал, драма, криминал
Режиссеры: Жан-Ксавье де Листрад
Дөньякүләм премьерасы: 7 октябрь, 2004 ел
Төп рольләрдә: Майкл Петерсон, Дэвид Рудольф, Том Мехер, Билл Петерсон, Фреда Блэк, Джим Хардин, Артур Холлэнд, Тодд Петерсон, Маргарет Рэтклифф һ.б. лар.

ЛЕСТНИЦА, 2022 (1 НЧЕ СЕЗОН)
Платформасы: HBO, Max
Иле: АКШ
Жанры: драма, криминал, детектив, биография, триллер
Режиссеры: Антонио Кампос
Дөньякүләм премьерасы: 5 май, 2022 ел
Төп рольләрдә: Колин Фёрт, Тони Коллетт, Майкл Стулбарг, Патрик Шварценеггер, Софи Тёрнер, Одесса Янг һ.б.

БЕР ЯЗМЫШКА – ИКЕ КАРАШ

«HBO Max» платформасында тәкъдим ителгән әлеге ике сериал нәрсәсе белән үзнчәлекле соң? Беренчедән, бу нуленче елларда зур кызыксыну уяткан һәм популяр булган реаль вакыйгаларга багышланган кейс буенча төшерелгән картиналар. Икенчедән, бер язмышка ике – караш, реаль шәхеснең үзе катнашындагы документаль тасма белән уен картинасы. Өченчедән, «Каратель», «Грешница», «Дьявол всегда здесь» кебек соңгы елларда шактый зур игътибар уяткан фильмнары белән билгеле яшь режиссёр Антонио Кампосның бу шау-шулы тарихка ерактанрак күз ташлап, яңа укылыш бирергә омтылышы.

2001 елда АКШ ның затлы һәм күренекле гражданины – сәясәтче, язучы, Вьетнам сугышы турындагы популяр романнар авторы, Төньяк Каролина штатының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында зур активлык күрсәткән зат, хәтта Дарем шәһәре мэры булырга ниятләгән Майкл Петерсон 911 хезмәтенә шалтырата да хатынының баскычтан егылып төшүен, хәле бик авыр булуын хәбәр итә. Табиблар белән полиция килеп җиткәндә, Кейтлин Петерсон инде исән булмый, ә Майкл үзе аларны өйдә каршы ала. Иң шаккаткычы – Кейтлин Петерсонның тәнендә күпсанлы җәрәхәтләр табыла, бәхетсез очрак буларак каралырга тиешле хәл шунда ук үтерү булырга мөмкин дип табыла. Майкл Петерсон төп шик астындагы кеше буларак карала, җитмәсә, полиция тиз арада мотивларны да актарып чыгара.

Фотолар kinopoisk.ru/сайтыннан алынды

Петерсон, үз чиратында, моны шәхесенә һәм гаиләләренә һөҗүм буларак кабул итә, гаять тәҗрибәле һәм кыйммәтле адвокатлар яллый. Әлеге суд эшенә, адвокатлар белән бергә, француз документалистлары да килеп кушыла. Шулай итеп, Майкл Петерсон эше, әле Интернет, социаль челтәрләр пәйда булганчыга кадәр үк, онлайн-режимда диярлек барган бик зур шау-шу кубарган вакыйгага әверелә. Ә бит ул тиз генә хәл ителгән эш булмый, 15 елга кадәр сузыла. Документаль проект та, шулай итеп, озын язмышлы булып чыга.

Бүген тамашачылар «Подозрения» дип исемләнгән 10 сәгатьлек документаль сериал белән Интернет челтәренә кереп, теләсә кайсы стриминг каналында таныша ала. Бу – 2001 елда башланып, еллар буена сузылган бер язмышның гына түгел, ә аның тирәсендәге кешеләрнең, тулы бер чор, социаль катламның хроникасы. Бу шулай ук моңарчы криминаль эшләр тарихында булмаган уникаль хроника да – биредә документалистлар тулы бер буын адвокатларның яклау сызыгын ничек оештыруы, суд эшчәнлегенең эчке кухнясы, присяжныйларның мөнәсәбәтләре, аларны туплау ысуллары, фокус-төркемнәр һ.б. детальләрне тулы тарихи җирлектә теркәп бара.

Баштарак без үз-үзенә чиксез ышанган һавалы, байлыгы ташып торган ир уртасы белән очрашсак, азакта Майкл Петерсонны сынган, дәрәҗәсен дә, исемен дә, затлылыгын да җуйган йончыган бер картлач хәлендә күрәбез. Нәрсә хакына көрәшә ул еллар дәвамында?!

Һәм ни өчен Антонио Кампос бу тарихка өр-яңадан тотынырга булган, дигән сорау да туа. Ул бу проект, ягъни уен картинасы буларак әзерләнгән «Лестница» сериалы турында әллә ни иркенәеп сөйләми. Бары тик кыска фактлар, детальләр белән генә җавап бирүне кулай күрә:

«МИН БУ ПРОЕКТНЫ ТОРМЫШКА АШЫРЫР ӨЧЕН 2008 ЕЛДАН БИРЛЕ ЭШЛИМ. БУ – БИК ОЗАК ҺӘМ КАТЛАУЛЫ ЮЛ БУЛДЫ, ӘММА ТҮККӘН КӨЧНЕ АКЛАРЛЫК ЮЛ. НӘТИҖӘДӘ, МИН ТЕЛӘСӘ КЕМ БАРЫ ТИК ХЫЯЛЛАНА ГЫНА АЛЫРДАЙ ПАРТНЕРЛАРНЫ ТАПТЫМ – «HBO MAX» КОМПАНИЯСЕ, ШОУРАННЕР МЭГГИ КОН ҺӘМ, ӘЛБӘТТӘ ИНДЕ, КАБАТЛАНМАС, ИСКИТКЕЧ АКТЁР КОЛИН ФЁРТ».

Документаль сериалның адаптациясе рәвешендә эшләнгән уен вариантында Колин Фёртның катнашуы – төп факторларның берсе. Әлеге роль, әйтерсең, еллар буе аны гына көткән. Репутациясе ягыннан Голливудның иң затлы британ актерларыннан исәпләнгән Фёрт, гадәттә, рольләр сайлау мәсьәләсендә шактый четерекле зат буларак билгеле. Без аның каһарманнарының эчке аксөяклегенә шул дәрәҗәдә ышанырга күнеккәнбез ки, бу очракта да беренче серияләрдән без аңа берсүзсез мөкиббән. Режиссер бу эффектны үтә дә уңышлы һәм нечкә итеп куллана.

«Кинопоиск» тәнкыйтьчесе Станислав Зельвенский болай ди: «Лестница» – күп еллар дәвамында бер чылбырга тезелеп килгән ялган һәм иллюзияләр тарихы. Монда бер генә нәрсә дә, беренче карашка күренгәнчә, гади һәм турыдан-туры, җиңел генә чишелешле түгел».

Документаль сериалдан аермалы буларак, Кампос һәр борылышны, детальләрне тамашачыны киеренкелектә тотар өчен файдалана. Шундый итеп файдалана ки, хәтта «Подозрения»не энәсеннән җебенә кадәр караучылар да режиссерның бу кагыйдәләрен кабул итеп, аның кануннарына буйсына. Һәм, әйтергә кирәк, Фёрт – чыннан да, искиткеч! Ул үзенең күз явын алырдай сөйкемле сөяге белән, әйтерсең, экран аша да мистик рәвештә тәэсир итә белә, аның бу көченә бер эләксәң, теләсә нинди ялганга да ышанырга әзерсең. Иң мөһиме – ул гына гаепле булмасын... Без бу геройның караңгы якларын үз күзләребез белән күреп, карап, тоябыз, әрнибез, бәргәләнәбез, әмма аклар өчен һаман да сәбәпләр эзләүне дәвам итәбез. Ә ялганнар бер-бер артлы домино эффекты белән тәгәрәвен дәвам итә, киеренкелектән ми чатный башлый. Һәм без Фёрт образында тулы бер системаны, үзләрен «югары катлам» дип игълан иткән һәм тирәлегенең колына әверелгән затларны абайлый башлыйбыз. Һәм бу баскычтан кешеләрнең бары тик затлы читлеккә генә күтәрелә алуын, ә көннәрдән бер көн аска тәгәрәсә, шулай ук түбәндә читлек көтеп торганын анык күрсәтә режиссер.

Сериал шулкадәр гадәти, тормышчан һәм ясалма экшн-эффектларсыз, аның көндәлек фактурасына кереп күмеләсең дә вакыт узганын сизми дә каласың. Монда – гадәти кеше фаҗигасе дә, гаилә фаҗигасе дә, иҗтимагый-сәяси торышыбыз, җәмгыять фаҗигасе дә. Кампос безгә җаваплар бирми, ә сораулар, ахыр чиктә, канлы чәрдәкләр булып, бушлыкка оча.

ЯЗУГА МӨКИББӘН СУФЫЙ

Илдус Заһидуллин, тарих фәннәре докторы



XIX йөз ахыры – XX гасыр башы татар мәдәнияте тарихында иң күп укылган әсәрләрнең берсе – Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә: шәрхе «Сөбәтел-гаҗизин» китабы. Ул беренче мәртәбә 1847 елны Санкт-Петербургта Түбән Новгород губернасы Сергач өязе Актүк авылыннан килеп башкалада яшәүче Ризван Маллай углы хисабына бастырыла, аннан соң Казан басмаханәләрендә бик күп тапкырлар зур тиражлар белән дөнья күрә.

БЕЛЕМ ЭСТӘҮ ЮЛЫНДА

Таҗетдин Ялчыгол 1768 елны хәзерге Азнакай районындагы 1704 елда Казан өязеннән күченгән ясаклы татарлар нигезләгән Чалпы исемле авылда Ялчыгол-дәрвиш гаиләсендә дөньяга килә.

1775–1776 елларда этисе, 13 яшьлек улын ияртеп, хаҗ кылу нияте белән юлга чыга. Оренбург губернасындагы Сәгыйть бистәсе, Әстерхан аша Кавказга килеп җитә. Хаҗ маршрутыннан читтә урнашкан Азов диңгезе янындагы Җаксай каласына килә. Биредә Таҗетдин 4 ел мәдрәсәдә укый. Ниһаять, аталы-уллы биредән хаҗ сәфәренә кузгалып, Кавказ тауларын кичкәч, тагын маршруттан читләшеп, Анадолу өлкәсендәге Диарбәкер каласына баралар. Биредә Ялчыгол, улын Абдешшәкүр исемле шәехкә тапшырып, хаҗ сәфәрен дәвам итә.

Абдешшәкүр остазы вафатыннан соң (дүрт ел узгач) Таҗетдин Истанбулда хаждан кайтучы этисе белән очраша. Алар анда ике ел яшиләр. Бу вакытта, күрәсең, Таҗетдин укуын дәвам итә. Шул рәвешле Таҗетдин Ялчыгол, 10 ел гомерен чит төбәкләрдә гыйлем туплап һәм шәехләр белән аралашып, иленә гыйлемле суфый булып әйләнеп кайта.

Таҗетдин 1792–1799 елларда – Минзәлә өязенең Җирекле, 1799–1824 елларда Кызыл Чапчак (хәзерге Түбән Кама районы) авылларында, 1824–1838 елларда, вафат булганчы, Мәлемдә (хәзерге Зәй районы) мулла булып тора, мәктәптә балалар укыта, гомерен мөгаллимлеккә, туган халкына аң-белем таратуга, Идел-Урал төбәге мөселманнарының дини бердәмлеген булдыруга багышлый. Төбәктәге авылларга барып, ислам йолаларының, дини кануннарның үтәлешен күзәтүе, руханилар белән сөйләшү-очрашулар уздыруы да аның абруе турында сөйли. Кабере – Имәнлебаш авылы зиратында.

ТАСАУВЫФ ЮЛЫ

Таҗетдин Ялчыгол – Нәкышбәндия тарикатенең күренекле вәкиле, Идел-Урал буендагы мәшһүр суфыйларның берсе. Аның этисе белән, хаҗ кылуны сәбәп итеп, күренекле ишаннары белән дан тоткан суфыйчылык үзәкләренә барып чыгуы да, күрәсең, сәләтле шәкерткә белем бирерлек көчле остаз эзләү белән бәйле була.

Үз заманында Таҗетдин мулла башка руханилардан аерылып тора. Ул үзе музыка кораллары ясый, аларда уйнап җырлый. Аның кульъязмаларының берсендә егерме дүрт кыллы татар гөсләсе, скрипка, думбра һәм тәгәрмәчле лираның сурәтләре һәм алар хакында кыскача мәгълүмат теркәлгән. Болар бүген – искиткеч зур фәнни әһәмияткә ия этнографик чыганак.

Фотолар автордан алынды

Тажетдин Ялчыголның Татарстан Республикасы Зәй районы Имәнлебаш авылындагы кабере.

Таҗетдин суфый шулай ук халык арасында дарулар ясаучы табиб һәм имче-дәвачы булып таныла, аны тирә-як авылларга да дәваларга чакыралар. Менә шундый бер җәяүле сәяхәте вакытында, узып барышлый бер хуҗалыкка су сорап ишек каккач, хуҗа биргән ачы балны эчеп кинәт үлеп китә.

Шиһабетдин Мәрҗани Таҗетдинны язуга, иҗатка мөккибән, язуы яхшы, камил һәм гүзәл булган бер зат иде дип бәяли. Аның чын мәгънәсендә ислам гыйлеме иясе, киңкырлы шәхес икәнен хезмәтләре күрсәтеп тора. Бүгенге көнгә күпчелеге сакланып калмаган 13 хезмәтенең исеме билгеле. Алар арасында, «Рисаләи Газизә: шәрхе «Сөбәтел-гаҗизин» китабыннан тыш, медицина, суфыйчылык тәгълиматы һәм тарих буенча язылган берәр хезмәте булып, калганнарын ислам хокукы буенча язылган шәрехләмәләр һәм 1848 елда китап булып басылган «Һәфтияк шәриф тәфсире» тәшкил итә. Соңгысын Шиһаб Мәрҗани һәм Риза Фәхретдин нык тәнкыйтьлиләр. Чынннан да һәммәсе 70 сүрәгә бирелгән шәрехләүләрдә зур урынны риваять һәм хикәятләр алып тора. китап нигездә авыл муллалары һәм гади халыкка атап язылган дигән тәэсир кала.

Исламны өйрәнүче галим Михаэль Кемпер фикеренчә, XVIII–XIX гасырларда Идел-Урал төбәгендә суфыйчылык мәсьәләләрен яктыртуда Таҗетдин Ялчыгол дәрәҗәсендә фикерле һәм гыйлемле башка шәхес булмаган. Сүз гарәп телендәге (Таҗетдиннең гарәп телен бик яхшы белгәнлеге мәгълүм) «Инийат ас-субхани» исемле кульязмасы турында бара. Ялчыгол бу хезмәтендә Нәкышбәндия тарикате суфыйлары тарафыннан Аллаһ белән кушылу юлында үтәлергә тиешле шартларны саный, аларга тасвирламалар бирә.

Автор әйтүенчә, мистика белән шөгыльләнү ислам догматикасына нигезләнергә, Коръән, сөннә, хөрмәтле шәехләр, бигрәк тә матуридлар иҗмасына (килешеп кабул ителгән бердәм карарларына) һәм кыйясына (Коръән һәм сөннәгә охшатып карар кабул итү) туры килергә тиеш.

Ялчыгол тасаувыф ритуалларын башкаруның тышкы шартлары дип барлык гыйбадәтләрне вакытында башкаруны, даими рәвештә туганнар белән аралашуны һәм начар гамәлләр (хәләл җефетенә хыянәт итү, кешегә нахак яла ягу, сүгенү, күп сөйләшү һәм тәнне авырттыру) кылудан саклануны атый.

Нәкышбәндия тарикатенең эчке шартлары буларак шайтанга хас тәкәбберлек, мактанчыклык, эгоизм, кешеләрне күралмау, икейөзлелек, көнчелек, саранлык, явызлык кебек начар сыйфатлардан котылырга, шулай ук төрле тыелуларны һәм күрсәтмәләрне үтәргә кирәклеген искәртә. Шушы шартларны үтәгән шәхес кенә Аллаһка якынаерга мөмкинлек ала, дип ассызыклый. Аллаһны илаһи тану юлында Таҗетдин тагын 10 алшартны шәрехләп үтә.

«ТАРИХНАМӘИ БОЛГАР» КИТАБЫ

1897 елда китап булып басылган «Тарихнамәи Болгар» әсәре тарихчы галимнәр (Шиһабетдин Мәрҗанидән башлап) тарафыннан хаклы рәвештә кискен тәнкыйть утына тотылып килә. Чөнки бу хезмәттә еш кына төрле заманнарда яшәгән затлар янәшә куела, булмаган, тарихи чыганаклар белән расланмаган вакыйгалар булган хәл дип тәкърарлана.

Китапның башында аны язу тарихына тукталып, автор унлап гарәп, фарсы һәм төрки телдәге чыганакларны саный, шулай ук халык телендәге риваять һәм үзе ишеткән мәгълүматны файдаланганын әйтергә дә онытмый. Адәм галәйһиссәламнән башлап (һәммәсе 85 буын), Таҗетдиннең нәсел шәҗәрәсе дә теркәлә.

Совет чоры һәм бүгенге Татарстандагы тарихи хезмәтләрдән аермалы буларак, Көнбатыш галимнәре Аллен Франк һәм Михаэль Кемпер бу хезмәтне Идел һәм Урал төбәгендә исламның бик борынгыдан таралуын исбатлауны һәм монда яшәгән халыкларны исламчылык концепциясендә тәрбияләүне максат итеп куйган идеологик китап дип саный. Идеологик хезмәтләр, билгеле булганча, мифлаштырудан баш тартмый: кайбер дөрес фактлар белән аралаштырып, уйдырма-легендаларны һәм риваятьләрне иркен куллана. Хезмәтнең үзегендә исә борынгылатылган, мифлаштырылган болгар исламчылыгы ята.

Төрекмәннән туган Кинҗәнең олы улы – Татар, аннан кечеләре Мишәр, Иштәк һәм Нугай дип күрсәтеп, Таҗетдин барысының да үз дәүләтләрен төзүләрен ассызыклый. Иштәкнең улы – Бәкәтун, аның олы улының – Әйле икәнен

яза. Аның Нариман атлы улыннан Коръәндә телгә алынган Сократ хәким туган, имеш. Ул юнан (грек) иленә барып, шулай ук исламга кадәрге чорда Коръәндә искә алынган Искәндәр (Александр Македонский) белән очраша, Сократ хәким аның белән кабат Идел-Чулман төбәгенә мәңгелек тормыш бирүче тереклек суы эзләп килә, алар икәүләп Болгар шәһәренә нигез салалар. Сократ Болгарда өйләнә, үзләре киткәч, улы Гөфтар Болгар шаһы булып кала. Бу Әйле һәм Сократ хәким Таҗетдин Ялчыголның ерак бабалары дип бәян ителә.

Мондый легендалар болгарлар арасында таралган була. Әйтик, XII гасыр гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнати Александр Македонскийның Болгарга «тимер капка» кору өчен килгәнен һәм болгарларның үзләрен аның дәвамчылары дип санауларын язып калдырган. Шуңа өстәп, татар һәм болгарлар риваятьтә үзләренең борынгы бабалары дип Кара бәкне атый, аның этисе итеп Сократ хәким яки Бачман тәгаенләнә. Сократ Анадолу ягыннан килеп, Җаек яки Сакмар елгасы буенда төпләнгән дип сөйләнелә. Кара бәк шәҗәрәсе нугайларга барып тоташа.

Китапта, шулай ук, болгарларның исламны Мөхәммәд тарафыннан төбәк халкын вәгазьләү өчен бирелгән дәстар, таяк һәм кара савыты алып килгән өч сәхабәдән – Габдрахман бине Зөбәер, Зөбәер бине Җәгъдә һәм Талха бине Госманнан – кабул итүләре әйтелә. Сәхабәләр башта Болгарда кешеләрне дәвалап йөри. Китапта Айдар ханның, кызын дәвалау алдыннан биргән вәгъдәсен үтәп, ислам динен кабул иткәне тасвирлана. Шулай итеп, Болгар төбәгендә исламның бик борынгы булуы, Мөхәммәд пәйгамбәр заманыннан ук таралганы «раслана». Бу сюжет, шулай ук Аксак Тимернең Болгарны харап итүе вакыйгасы Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» хезмәтендә дә кабатлана.

«РИСАЛӘИ ГАЗИЗӘ: ШӘРХЕ «СӨБӘТЕЛ-ГАҖИЗИН» ӘСӘРЕ

Таҗетдин мулла гаиләсендә 4 ул һәм 3 кыз тәрбияләнә. Уртанчы кызы Газизә үтенече буенча, ул XVIII гасырдан башлап Идел-Урал төбәге халкы арасында мәшһүр, чыгышы белән Идел буеннан булган Бохара суфые Суфи Аллаһиярның (1713 елда үлгән) борынгы үзбәк телендә язылган, шуңа күрә аңларга кыен булган «Сөбат әл-гаҗизин» («Газизләр ныклыгы») хезмәтен үзе язганча «болгар телендә» тәфсилләп шәрехли. Шуңа күрә 1806 елда тәмамлаган әсәрен «Рисаләи Газизә» – «Газизәгә җыентык» яки «Газизә китабы» дип атый.

«Сөбат әл-гаҗизин» 77 бүлеккә тупланган 1718 шигъри ике юллыклар – бәетләрдән гыйбарәт. Аллаһиярның максаты – Мөхәммәд пәйгамбәрне үрнәк итеп куеп, сүз сәнгате ярдәмендә укучыларында югары әхлак тәрбияләү. Суфыйчыл әдәбият үрнәге булган бу әсәрнең бүлек исемнәрендә дә әлеге максат чагылыш тапкан: «Аллаһы Тәгаләнең сигез сыйфаты», «Мөхәммәд Рәсуллаһ бәяны», «Үгет-нәсихәт», «Фәрештәләр бәяны», «Гомернең вакытлы гына булу хәбәре», «Җәннәт белән тәмуг бәяны», «Комсызлык хикәяте», «Яхшы юлдашның бәяны» һ.б.лар. Шагыйрь тормыштагы һәрбер кыенлыкны, авырлыкны олы сабырлык белән каршы алырга һәм зарланмый чыдарга өнди.

Таҗетдин Ялчыгол китапның керешен, шул исәптән, язылу сәбәбен һәм Аллаһияр турында тарихны, ахырын, шулай ук үзеннән бәетләр өстәп язган. Төп өлештә Суфи Аллаһиярның бәетләрен китереп, аларга аңлатмалар бирә, үзеннән һәм башка авторлардан хикәятләр, күп төрле мәгълүматлар өсти, шулай итеп, мөстәкыйль оригинал хезмәт килеп чыга.

Дини планда, китапның ике «канаты» бар: бердән, ислам диненең асылы һәм икенчедән, Бохара Нәкышбәндия тарикатендә XVIII гасырның беренче яртысында өстенлек иткән тасавыф этикасы кануннары бәян ителә.

Китапта ислам дине һәм пәйгамбәрләр турында кыйссалардан соң сүз Аллаһ, аның атрибутлары, ахирәт һәм андагы тормыш, Коръән иңдерелү, иман, фәрештәләр, кыямәт көне, могъҗизалар турындагы тарихларга күчә, шигырьләргә өстәп оригиналь текстлар язылган. Шулай ук төрле мәзһәпләрнең имамнары, иҗтиһадның өч төре һәм тәкълиднең дүрт формасы турында мәгълүмат бирелә, имамны сайлау шартлары һәм аны сайлау мәҗбүрилеге, солтан (яки мөфти) шәригатькә каршы чыкса, мөселманнарның аңа каршы булырга хокуклары барлыгы әйтелә.

Хикәятләрендә тискәре әхлакый сыйфатларны тәнкыйтьләүдән тыш, Таҗетдин бу дөньядагы һәртөрле вәсвәсәләрдән ваз кичеп, дин кардәшләрен гыйлем алырга өнди, остаз һәм мөршид арасындагы элемтәнең нык булырга тиешлегенә игътибар итә. Бер үк вакытта автор кайбер шәехләрне акчага хирыслыклары, үзләренең йогынтыларын файдаланып, дин кардәшләренең милекләренә кул сузулары өчен кискен гаепли.

Автор, бер яктан, дин гыйлеме белән шөгыльләнмәүче һәм ислам хокукы мәсьәләләрен хәл иткән өчен халыктан ришвәт алучы руханиларга һөҗүм итә, икенче яктан, начар гамәлләрдән тыелып, бозык һәм бай кешеләрдән, хакимият вәкилләреннән читләшеп яшәүче, байлыкка кызыкмаучы һәм гыйльми бәхәсләрдә катнашмаучы муллаларны голәмәләргә үрнәк итеп куя.

Дини менталитетлы халыкка Мөхәммәд һәм башка пәйгамбәрләр тормышы турындагы кыйссаларны шәрехләгәндә, Ялчыгол, үзенең тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп, аерым сүзләргә, гыйбарәләргә аңлатма бирә.

Таҗетдин сәяхәтләре вакытында җыйнаган тәүсавыф гыйлемен шәкертләре һәм мәхәллә халкына түкми-чәчми тапшыра. Аның туган телендә язган китаплары XIX гасыр башында суфый мулланың халыкны иманлы һәм әхлаклы итүнең гүзәл үрнәге булып тора.

Таҗетдин Ялчыголның шәхси мөһере.



Оборудование для медицинских центров и клиник

Ordamed Russia

Офис в Казани:
г. Казань, ул. Николая Столбова, д. 2, офис 103

Телефон:
+7 (968) 039-70-72

ordamed.ru

РЕКЛАМА

ИСТАНБУЛДА НИЧЕК ҮЗ КЕШЕ БУЛЫРГА

Ни өчен россиялеләрнең Төркиядә күпләп күчемсез милек сатып ала алуы һәм бу илдә гражданлыкны ничек алып булуы турында Premium Realty компаниясе башкарма директоры **Руслан Новикас** сөйли.

– Руслан, кайбер мәгълүматларга караганда, соңгы айларда россиялеләрнең күчемсез милек белән кызыксынуы 2 тапкырга арткан. Сәбәпләре нидә?

– Алар күренеп тора. Төркия белән РФ арасында дустанә мөнәсәбәтләр, җирле законнар чит ил инвесторлары мәнфәгатьләре сагында тора. Бу илгә инвестицияләр керткән өчен Төркия Республикасы гражданлыгын алырга була – бу асылда санкцияләр шартларында гадәти яшәү рәвешен саклап калу мөмкинлеге. Төркия гражданнары якынча 110 илгә визасыз керә ала. Тагын Евросоюз илләренә һәм АКШка виза алу җиңеллеге. Әйдәп баручы Төркия һәм чит ил университетларында белем алу, җирле банкларда счетлар ачу, җиһанның теләсә кайсы почмагында дөньякүләм түләү системаларының банк карталарын куллану мөмкинлеге – боларның барысын да Төркия бирә. Өстәвенә, күчемсез милеккә салым бу илдә шактый аз. Коммерциячел милеккә - 0,4 процент, торакка — 0,1 процент. Хокукны теркәү – нибары 4 процент. Чагыштыру өчен, күчемсез милегегезне арендага тапшырудан кергән керем уртача 3–4 процентны тәшкил итә. Төркиядә чит ил кешеләре өчен күчемсез милекне мирас итеп алу хокукы нык саклана, әйтик БГӘнән аермалы буларак. Климат, таныш менталитет, бизнес алып бару өчен яхшы мөмкинлекләр, менә дигән медицина – болар барысы да ватандашларыбызны Төркиягә җәлеп итә...

– Әйтик, мин инвестицияләр өчен гражданлык алырга телим. Сезнең фикерегезчә, акчаны кайсы төбәккә салу яхшырак?

– Вариантлар күп. Өстенлекләрнең берсе – Истанбул. Шәһәр озак вакытлар санкция басымы астында булган илләр өчен тарихи яктан «дөньяга тәрәзә» булып тора. Инвесторларны бирегә нык үскән инфраструктура да, йомшак климат та җәлеп итә. Инвестор гаиләсенә ул 250 мең АКШ долларына күчемсез милек сатып алган очракта Төркия гражданлыгын алу мөмкинлеге бирүче программа да БДБ илләреннән Истанбулга инвестицияләр кертүгә этәрә. Дөрес, 2022 елның 13 июненнән күчемсез милек алуның минималь сумма 400 мең АКШ долларына кадәр артачак. Әмма инвесторны бу гына туктата алмый, чөнки керәчәк файда шактый зур.

— Нәрсәне сатып алу яхшырак? Әзер объектмы, әллә төзелеп килүчесенме? Һәм кайда?

– Монда күп нәрсә куелган максатка бәйле. Отышлы итеп яңадан сатарга телисез икән, котлован стадиясендәгене сайлагыз, төзелеш процессында аларның бәяләре шактый үсәчәк. Әлбәттә, киләчәктә метро, сәүдә үзәге булачак яңа районны карарга кирәк. Әгәр торакны үзең өчен карыйсыз икән, әзер яисә төзелешнең финал стадиясендәге объектка тукталыгыз. Бу очракта тәрәзәдән тирә-якны күрергә, планировкага бәя бирергә мөмкин.

— Тагын нәрсәгә игътибар итәргә киңәш итәсез?

— Location, location, location* - күчемсез милекнең ликвидлылыгын бәяләгәндә барлык девелоперларның төп киңәше әнә шул. Иң мөһиме - объект салынган җир. Ремонтны яңадан эшләргә, идарәче компанияне алыштырырга була, ә менә урын — ул мәңгегә. Транспортның булуы, экология, җәмәгать киңлекләренең, сәүдә үзәкләренең якынлыгы – болар барысы да торакның капиталлашуын арттыра. Әлбәттә, иң мөһим күрсәткеч — төзүчене сайлау. Төркиядә эскроу системасы юк, төзүче компания абруе – проектны гамәлгә ашыру һәм сыйфат гарантиясе.

- Агымдагы вазгыятьтә Төркиягә валюта күчерү мөмкин хәлме?

- Төркия компанияләре счетларына валютада акча күчерүгә чикләүләр юк. Бары тик SWIFT системасына күчерү өчен нигез генә (әгәр банк санкция кагылганнар исемлекләренә кермәсә) таләп ителә. Безнең клиентлар доллар һәм евроны биржа курсы буенча сатып ала, ә аннары сату-алу килешүе буенча аларның счетына күчерә. Әгәр сумма 50 мең АКШ долларыннан артып китсә, банкка акчаларның килеп чыгышы турында өстәмә мәгълүмат бирергә кирәк: 2-НДФЛ белешмәсе, банктан кертемнәр турында белешмә, күчемсез милек яки транспорт чарасын сату-алу килешүе һ. б.лар.

- Сату-алу килешүен рәсмиләштерүгә күпме вакыт кирәк?

- Минималь. Күчемсез милек объектын сайлыйсыз - агентлык белән контракт төзисез. Аннары - нотариаль шартнамә рәсмиләштерү һәм гражданлык турында эшне алып бару өчен юрист белән контракт имзалау.

Без инвесторларны гражданлыкны рәсмиләштерү, банкта исәп-хисап счеты ачу, күчемсез милек сатып алу буенча таныштыру турларына Истанбул һәм Аланиягә чакырабыз. Компаниябез премиаль сегментта эшли, без консультатив ярдәм күрсәтәбез, күчемсез милек сатып алуның барлык этапларында, акчаларны күчерү һәм сделканы юридик яктан рәсмиләштерү вакытында клиентларыбызның янәшәсендә булабыз. Барлык сораулар буенча WhatsApp - +79872973507 номеры аша элемтәгә керергә була. Һәм без Төркиядә булу вакытыгыздагы барлык вак-төякне чишүгә кадәр үз өстебезгә алабыз һәм күчемсез милекне сайлап алуда һәм рәсмиләштерүдә ярдәм итәбез.

Күчемсез милек турында
телеграм-канал: **asiya_novikas**
Тел.: **+79872973507**
Истанбулдагы күчемсез милек:
+79872973507
Аланиядәге күчемсез милек:
+79274401790
Сайт: **prrealty.ru**

* Location — локация (ингл.). ** Свифт. *** Вотсап.

Фото Premium Realty компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

САКЧЫЛЛАР ГАЗНЫ САЙЛЫЙ

2021 ел нәтиҗәләре буенча Россиядә метан иң аз чыгымлы ягулык булып кала бирә. «Газпром газомоторное топливо» ягулык салу станцияләрендә табигый газ бәясенең үсеш темплары башка ягулык төрләренә караганда түбәнрәк. Ул дизель ягулыгы хакының 50% нан да артмаслык бәядә тотыла һәм 2022 елда компания тарафыннан инфляция дәрәҗәсе нигезендә индексацияләнәчәк.

Метанның тотылу күләме бензин кебек үк. Уртача 8 литр сарыф ителгән очракта, һәр мең километрга 2560 сум экономияләнә (95 ле бензин белән чагыштырганда). Метанның тагын бер мөһим плюсы мотор өчен файдасында: газ бензиннан чистарак һәм көек утыртмый диярлек. Өченче өстенлеге – экологик яктан чисталык. Дизель белән чагыштырганда, метанның углерод эзе 1,7 тапкыр кимрәк. Калган зарарлы матдәләр бензинныкыннан 6 тапкыр кимрәк бүлеп чыгарыла.

Татарстанда газ ягулыгындагы автомобильләр саны 14 меңгә диярлек җитте. Экология күзлегеннән алдынгы автопарк үсешенең темплары ягыннан республика әйдәп баручы төбәкләрдән санала. «Газпром газомоторное топливо» компаниясенең Татарстанда ун еллык эшчәнлегендә иң төп нәтиҗәләрнең берсе әнә шундый.

Газ ягулыгының бәхәссез өстенлекләре – экологиялелек һәм чагыштырмача очсызлык. Бензин һәм дизель урынына табигый газ кулланучы автомобиль хуҗалары бергә алганда өч ай эчендә генә дә ягулыкта 640 миллион сумга якын акчаны янга калдырган. Бу вакыт аралыгында республикада парник газлары – 35,1 мең тоннага, зарарлы матдәләр 575 тоннага кимрәк бүлеп чыгарылган.

Газ салу станцияләренең тармакланган челтәрен булдырмыйча торып, автомобильләрне экологик чиста ягулыкка күчерү, хәтта бу аның арзанлыгына да карамастан, чынга ашырыла алмас иде. Алдан уйланылган гамәлләр стратегиясе менә шуңа бәйле. Татарстан Республикасы Хөкүмәте, «Газпром» ГАҖ һәм «Газпром газомоторное топливо» ҖЧҖ арасында гамәлдә булган килешү мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ куллануны киңәйтү өлкәсендә хезмәттәшлек юнәлешләрен билгели. Газ салу станцияләре инфраструктурасы объектларын төзү һәм табигый газда йөри торган автомобильләр санын арттыру өчен уртак эшче төркем җаваплы.

Килешеп башкарылган уртак эш нәтиҗәләре күз алдында. 10 ел эчендә «Газпром газомоторное топливо» компаниясе, бу өлкәдәге инфраструктурага 3 миллиард сумга якын инвестицияләр кертеп, Татарстан территориясендә 25 станция ачты. «Газпром» АГНКС челтәренең гомуми җитештерү куәте 2,5 тапкыр арттырылды һәм хәзерге вакытта ул елына 201 миллион кубометр компримацияләнгән табигый газ (КПГ) тәшкил итә.

Республикада АГНКС челтәрен төзү программасын тормышка ашыру дәвам итә. Узган ел ахырында берьюлы өч яңа станция сафка басты: икесе – Казанда һәм берсе – Мәләкәстә. Быел әле Яр Чаллының Сәнәгать урамындагы станцияне төзеп бетерү дә планлаштырыла.

Газ салу станцияләре челтәрен киңәйтү потенциаль кулланучылар санының артуына ярдәм итә. Газда йөри торган автомобильләр паркын арттырырга булышкан тагын бер нәтиҗәле чара – компания тарафыннан республикада уңышлы кулланыла торган маркетинг программаларының комплекслы механизмы. Биш ел эчендә маркетинг программалары нигезендә 5275 транспорт чарасы табигый газ куллануга көйләнгән. Әлеге программалардан тыш, техниканы метанга күчерү эшенә бюджет субсидияләре дә этәргеч бирә. 2022 елда федераль һәм төбәк бюджетлары хисабыннан бу максатларга 134 миллион сумнан артык акча бүлеп бирелгән.

Газга көйләнгән техника санының тотрыклы үсеше, үз чиратында, экологияле ягулыкка ихтыяҗны арттыра. Татарстанда «Газпром» газ салу станцияләрендә компримацияләнгән табигый газ сату күләме соңгы сигез елда гына да сигез тапкыр арткан. 2022 елда 75,5 миллион кубометр газ сатылыр, дип фаразлана. Беренче кварталда мотор ягулыгы сыйфатында 18,2 миллион кубометрдан артык табигый газ сатылган. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, үсеш 17% тәшкил иткән.

Ирешелгән уңышлар тукталып калыр өчен сәбәп түгел. Кабатлап китәбез: техниканы газга күчерү – автомобиль йөртүчеләр өчен икътисадый яктан отышлылык кына түгел, ә бөтен кеше өчен чистарак экология ягына тагын бер адым.

Мәсәлән, Казанда автобус паркының 30 процентын КПГга күчерү зарарлы матдәләр бүлеп чыгаруны елына 126 тоннага, парник газларын 11 мең тоннага киметергә мөмкинлек бирде. Шәһәр автобусларының бөтенесен дә газ ягулыгына күчерсәң, бүлеп чыгарыла торган зарарлы матдәләрнең еллык күләме – 463 тоннага, ә парник газларыныкы 40 мең тоннага диярлек кимиячәк. Килешәсездер, саннар бик өметле, шуларга омтылырга кирәк.

Фото «Газпром газомоторное топливо» ҖЧҖ тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

АВТОМОБИЛЕГЕЗНЕ ҮЗГӘРТЕП КОРЫРГА ТЕЛИСЕЗМЕ? ЭКСПЕРТИЗАДАН БАШЛАГЫЗ

«Поволжье» сынау лабораториясе» ҖЧҖ Татарстанда транспорт чараларына экспертиза ясау тармагында инде 4 елдан артык төп рольне башкарып, республиканың меңләгән автомобильчеләренә законлы нигездә үз машиналарын үзгәртеп корырга мөмкинлек тудыра.

«Поволжье» сынау лабораториясе» ҖЧҖ составында түбәндәге хезмәтләрне күрсәтә торган берничә бүлекчә бар:

- аккредитацияләнгән сынау лабораториясе төп эшне башкара: экспертизалар үткәрә һәм транспорт чараларына төрле үзгәрешләр кертүгә, шул исәптән баллонлы газ җиһазларын (ГБО) урнаштыруга бәйле беренчел нәтиҗәләрне чыгара, үзгәрешләр керткәннән соң, конструкциянең куркынычсызлыгына экспертиза үткәрә һәм куркынычсызлык беркетмәләрен тутыра;
- транспорт чараларының электрон паспортларын (ЭПТС) рәсмиләштерә;
- өстәмә маркировка төшерә,
- транспорт чараларына техник карау үткәрә.

– Эшебездә иң мөһиме, беренче чиратта, транспорт чараларының куркынычсызлыгы, – ди «Поволжье» сынау лабораториясе» ширкәте директоры Марат Ярмиев. – Шуңа күрә безнең өчен «вак-төякләр» юк, һәрнәрсә Таможня берлегенең 2011 елның 9 декабрендә кабул ителгән 18 нче санлы «Тәгәрмәчле транспорт чаралары куркынычсызлыгы турында»гы техник регламентына катгый туры килергә тиеш. Башка сүзләр белән әйткәндә, безгә мөрәҗәгать иткән һәркемдә, автомобильнең ышанычлылыгы, куркынычсызлыгы саклансын өчен кирәкле барлык экспертизаларны да уздырачагыбызга шик уянмавы зарур. Төрле күңелсез нәтиҗәләргә юл куярга хакыбыз юк.

Беренче карашка, автомобильгә фаркоп (тагылмалы автомобиль белән идарә итү өчен тарту-тоташтыргыч җайланмасы (ТСУ)) кую авыр эш түгел кебек. Берничә шартны белеп торганда һәм үтәгәндә, бүгенге көндә проблемалар, чыннан да, булмаячак. ТСУ урнаштырганда, транспорт чаралары шартлы рәвештә өч категориягә бүленә:

– җитештерүче завод тарафыннан ТСУ урнаштыру мөмкинлеге каралган автомобильләр, ягъни сынау завод шартларында үткәрелгән һәм бу хакта транспорт чарасы типын раслау документында (ОТТС) күрсәтелгән;

– ТСУ урнаштыру мөмкин автомобильләр, әмма сынауларны махсус сынау лабораторияләрендә уздырырга була.

Ике очракта да, әлбәттә, тагу-тоташтыргыч җайланмасының паспорты һәм төзеклеге турында сертификаты булырга тиеш. ТСУ урнаштырганнан соң, автомобиль хуҗасына куючыдан алынган декларация белән (яки мөстәкыйль рәвештә урнаштырырга) безнең лабораториягә кабат килергә кирәк. Монда без җайланманың дөреслеген тикшерәчәкбез, тиешле сынаулар уздырачакбыз һәм куркынычсызлык беркетмәсен бирәчәкбез.

– Шулай ук ТСУ урнаштыру тыелган автомобильләр дә бар.

Сүз уңаеннан, шуннан соң таләп ителгән техник карауны да биредә, «Поволжье» сынау лабораториясе»ндә узарга мөмкин. Куркынычсызлык беркетмәсен алу һәм конструкциягә үзгәреш кертүне теркәү документларына билгеләп кую процедурасы өчен берничә сәгать вакыт җитә – лаборатория ЮХИДИ бүлекчәсе белән бергә урнашкан. Мондый уңайлылыктан үз машиналарына ГБО куярга карар кылган автомобиль хуҗалары да файдалана.

– Нигездә, охшаш процедуралар, – дип аңлата Марат Ярмиев. – Аерма шунда гына: баллонлы газ җиһазларын сертификацияләнгән сервиста гына урнаштырырга мөмкин һәм куела торган барлык җиһазлар да сертификацияләнгән булырга тиеш. Без ГБО экспертизасын шактый җентекләп уздырабыз, бу эштә нечкәлекләр җитәрлек, ә теләсә нинди хата да авыр нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Сүз уңаеннан, автомобильне үзгәртеп коруга бәйле теләсә нинди эшкә тотыныр алдыннан, лабораториягә шалтыратып, моны эшләргә ярыймы-юкмы икәнен сорарга киңәш итәм.

Автомобиль хуҗаларына уңайлы булсын өчен, «Поволжье» сынау лабораториясе»нең республикада берничә аккредитацияләнгән техник карау пункты бар. Казаннан тыш, алар Чаллы, Азнакай һәм Нурлатта урнашкан. Урыннарга барып тикшерену өчен, лабораториядә күчмә пункт та эшли. Тәҗрибәле белгечләр Татарстанның теләсә кайсы районына барып, тиешле процедураларны үткәрә һәм диагностика картасын бирә ала.

– Газ ягулыгының куркынычлыгы яки автомобиль двигателенә тискәре йогынты ясавы турында фикерләр зур ялгышлык булып тора, – ди лаборатория җитәкчесе Марат Әсәдуллин. – ГБО урнаштыруның барлык норма һәм кагыйдәләрен үтәгән очракта, газда йөрү экономияле генә түгел, экологик яктан файдалы да. Моны аңлап, Россия һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте инде берничә ел транспортны табигый газга күчерү белән шөгыльләнә торган юридик һәм физик затларга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр рәвешендә ГБО урнаштыруга ташламалар бирә. Шунысы игътибарга лаек: бу тәкъдимне беренчеләрдән булып муниципаль автотранспорт предприятиеләре хуплады.

ИСПЫТАТЕЛЬНАЯ ЛАБОРАТОРИЯ
ПОВОЛЖЬЕ.COM

Казан шәһәре, ТЭЦ ур.,
5 йорт, 1 офис
+7 (843) 570-98-78
info@поволжье.com
www.поволжье.com

РЕКЛАМА

ТҮБӘН УШМЫ: УРАМ ТУЛЫ БАЛА-ЧАГА

ТҮБӘН УШМЫ

Фото: Александр Ефремов

Кызганыч ки, кайбер авылларга баргач, буп-буш урамнар каршы ала. Ничә сәгать йөреп тә бер-ике кеше очратырга мөмкин. Мамадыш районының Түбән Ушмы авылында исә хәл бүтәнчә: урам тулы кеше. Аеруча балалар күп, монысы бигрәк күңелле.

Руфия Фазылова

КАРА БАГАНАЛЫ АВЫЛ

Түбән Ушмы Мамадыш район үзәгенә орынып тора, җиде чакрым гына. Шуңа күрә дә биредә шәһәрчә яшиләр. 95 укучы белем ала торган мәктәп, алтмышка якын бала йөри торган балалар бакчасы – бу авылда яшь гаиләләрнең күплеге турында сөйли. Мәктәп дигәннән, ел саен, ким дигәндә, унберенче сыйныфны бер укучы алтын медальгә тәмамлый. Берничә ел элек хәтта дүрт медалист булган. БДИ буенча уртача баллары да бик яхшы. Россиянең дәрәҗәле югары уку йортларында бюджет урыннарында укучы егет-кызлары шактый икән.

Түбән Ушмы бик борынгы авыл, монда XII–XIII гасырларда ук халык яшәгәнлеге билгеле. Дүрт мәхәлләле авылның дүрт мәчете булган. Авылны уртага бүлеп Ушмы елгасы ага.

– Хәтта авыл башында кара багана торган дип сөйлиләр, – диде Түбән Ушмының китапханәчесе Айсылу Галимуллина. – Авылда дүрт колхоз да булган. Җирләр бик уңдырышлы, шуның өчен дә халык күп килеп урнашкандыр. Авылны «Мең душлы Ушмы» дип атап йөргәннәр, бу истәлекләрдә калган. Әби патша юлы да безнең авыл аша узган. Шуңа карамастан, Түбән Ушмы чукындыруга бирешмәгән, динен алмаштырмаган. Әйтәм бит, көчле, күп халык яши торган зур сала булган ул.

Түбән Ушмыда тормыш чыннан да шәһәрчә: фонтан белән паркка кадәр бар. Аны 2014 елда Бөек Ватан сугышында һәлак булган, сугышта катнашкан һәм тылда хезмәт күрсәткән авылдашларына багышлап ачканнар. Шуның өчен

1
– Ике кызыбыз да гаиләләре белән бергә яши, – диде Түбән Ушмының китапханәчесе Айсылу Галимуллина.

дә ул Җиңү паркы дип атала. Бүген ул олысының да, кечесенең дә яраткан ял итү урыны. Парк үзе бер музейны хәтерләтә: Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга багышланган һәйкәл белән беррәттән, авылда туып-үскән атаклы кешеләр исемлеге, Әфган, Чечня сугышында катнашкан, һәлак булган батырлар – берәү дә читтә калмаган.

Айсылу Галимуллина белән паркны карап йөргәндә урамнан әллә ничә бала узып китте.

– Бу кайтучы балалармы, әллә авылда яшәүчеләрме? – дип сорадым.

– Күбесе монда яшәүчеләр. Түбән Ушмыда буш йортлар юк диярлек, Мәскәүдән хәтле кайтып алалар. Авылда йорт салырга бер буш нигез дә юк. Мисал өчен безнең ике кызыбыз да гаиләләре белән бергә яши. Икесенең дә Мамадышта фатирлары бар, әмма монда кайттылар. Икесе дә шәһәр егетләренә кияүгә чыкты, кияүләр дә авылга кайтты.

Айсылу апаның төпчек кызы Диләрә Хәкимуллина кечкенә улы белән урамда йөри иде. Шәһәр егетләрен авылга алып кайткан кызларның берсе белән якыннанрак таныштык.

– Алабуга дәүләт педагогика университетының физкультура бүлеген тәмамладым, – диде Диләрә. – Аннары Мамадыш тәрәзәләр заводында менеджер булып эшләдем. Әлегә бәби ялында, улыбызга көзгә ике яшь тула. Эшкә исә Түбән Ушмы мәктәбенә керермен дип ниятлим. Ирем Рөстәм Рифат Мәхмүтович Мотыйгуллин агрофирмасында эшли.

– Ирләрегезне авылга кайтырга ничек үгетләдегез?

– Үгетләп торасы булмады, үзләре теләк белдерде. Фатирда яшәп арыгач, ирем белән Мамадыштан йорт сатып алырга уйлаштык. Ләкин күңелгә ятышлы өй таба алмадык. Рөстәм белән сөйләшкәндә, Түбән Ушмы турында сүз чыкты. Юри генә җир карый башлаган идек, шундый әйбәт урын таптык. Кыш көнә җир алып, көзгә өйне өлгертеп тә чыктык. Апам монда балалар бакчасында эшли. Алар да йорт салырга әзерләнә, гаражларын төзеделәр инде. Авылда тормыш бик күңелле. Яшь гаиләләр белән Түбән Ушмы авылы спорт залына йөрибез. Мәдәният йортында бик еш чаралар уза – берсен дә калдырмыйбыз. Үзебез дә катнашабыз. Балалар өчен дә әйбәт: районда иң матур балалар бакчасы бездә. Өч төркем бар, әле урыннар җитми дә.

БОРЫНГЫ МӘЧЕТ

Манарасы киселмичә калган мәчетләр Татарстанда гына түгел, бөтен илдә дә бармак белән генә санарлык. Түбән Ушмы мәчете шундыйлардан. 1904 елда салынган иман йорты бүген дә ерактан ук балкып утыра. Аның тарихы бик үзенчәлекле: 1898 елны төзелә башлаган мәчеттә янгын чыга. Шуннан соң яңа бина төзүдә ярдәм сорап, авыл картлары икенче гильдия Казан сәүдәгәре Әхмәт Хөсәеновка мөрәҗәгать итә. Ул ризалык биргүгә, ушмылылар бердәм рәвештә төзелеш эшләрен башлый. Яңа мәчет 1904 елда төзелеп бетә. Шуның өчен мәчет тарихы төрлечә бирелә, бер китапта ул 1898 елда, икенчесендә 1904 елда салынган дип бара.

– Ничек кенә булмасын, мәчеткә, кимендә, 118 ел диган сүз, – диде авылның имамы Илнар хәзрәт Фәхретдинов. – Һәм аның язмышы гыйбрәтле дә, могҗизалы да. 1904 елда мәчет сигез манаралы булып төзелә. Аның бишесен кисәләр, ләкин өчесе утырып кала. Манара кискән вакытта көчле давыл чыга, читтән килгән кешеләр, ярты юлда туктап, авылдан китеп бара. Совет чорында ул гыйбадәтханә булмый, әлбәттә. Монысы инде гаҗәп түгел – илдә барган сәясәт безнең авылны да читләтеп узмый. Балалар бакчасы, 1940 нчы елларда клуб, ашлык саклау складлы... Ә менә 1980 нче еллардан 1990 нчы елларга кадәр мәчет авыл музее булып хезмәт итә. Аның тарихы да кызык: мәчет бинасының түбәләре бик таушала. Моны күреп, күп еллар «Кызыл флаг» миллионер колхозы рәисе булып эшләгән Мөхәммәтҗан абый Шакиров бик борчыла. Һәм ул мәчетнең түбәсен яңартырга керешә. Әмма бу хакта КПССның Татарстан өлкә комитетына хәбәр килеп ирешә: колхоз рәисе мәчетне төзекләндерә! Райкомга обкомнан махсус комиссия килачәге турында хәбәр итәләр. Мөхәммәтҗан абый моны ишетеп, авыл халкы белән бергә бер тәүлек эчендә иске әйберләрне мәчеткә урнаштыра. Мәчет ишегенә «Төбәкне өйрәнү музее» дигән язу элеп куялар. Комиссия килеп, мәчет эчендәге экспонатларны карап чыга. «Менә бит, башка авылларда да шундый музейлар булдырырга кирәк. Шәп!» – дип кайтып китәләр. Менә шулай итеп авылда зур фаҗига булмый кала...

1990 нчы елларда, дин ирегә кайткач, мәчет янә үз вазыйфасын үти башлый. Ә 2006 елда

шул чакта хуҗалык рәисе булган Рафаэль Мөхәммәтшин иман йортын тулысынча төзекләндерә. Ләкин Түбән Ушмы авылы мәчете бүген инде янә яшәргән. Ул затлылыгы белән аерылып тора. Мамадыш районының җитмеш процент җирләренә хуҗа булган эшкуар Мотыйгуллин Рифат аны үз акчасына ясаткан.

– Мәчетнең тышкы өлеше – ташлары шул килеш калды, – диде Илнар хәзрәт. – Элекке заманнарда биналарны калын таштан ясаганнар – җылы сакласын өчен дип. Безнең мәчет стенасының калынлыгы бер метр. Бу бит инде йөз ел элек салынган. Заманына күрә бик зур хезмәт булган, монысы, һичшиксез. 2014 елны мәчетнең йөз ун еллыгын үткәрдек. Шул чакта Рифат Мәхмүтович мәчетне төзекләндерде, зур рәхмәт аңа. Эчке ягын тулысынча мәрмәр таш белән ясап чыктылар. Монда тәрәзәләр дә гади генә түгел бит, милли бизәк белән. Авыл өчен әйтеп бетергесез зур бүләк булды ул... Түбән Ушмы мәчетенә җомга намазына иллеләп кеше йөри. Моннан тыш, мәчет каршында мәдрәсә эшләп килә. Атна саен авылның балалары, хатын-кызлары, ир-атлары дин кануннарын өйрәнергә йөри. Авылда бик күп кеше ураза тота, күмәк ифтарлар уза. Кыскасы, халкыбыз ислам кануннары белә, зурлый.

Аллаһ йортыннан бер рәхәтлек алып чыктык. Авылларда түгел, шәһәрдә дә мондый затлы, тарихи иман йортлары сирәк. Монысы бер. Икенчесе – мондый имамнар да еш очрамый. Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге Казан Югары мөселман мәдрәсәсен тәмамлаган Илнар хәзрәт Фәхретдинов сүзе белән дә, йөзе белән дә иман нуры тарата төсле тоелды.

«БАЛ КОРТЛАРЫ КОТКАРДЫ»

Түбән Ушмының авыл җирлеге башлыгы Раил Ганиев, үзенчәлекле гаилә дип, безне Шакировлар йортына алып килде. Фәрит абый белән Зәйтүнә апа икесе дә укытучылар икән. Гаилә башлыгы күп еллар Түбән Ушмы авылы мәктәбендә эшләгән, мәктәп директоры булып та торган. Хәзер исә күрше авыл мәктәбен җитәкли. Ә Зәйтүнә апа Түбән Ушмы урта мәктәбендә уку-укыту буенча директор урынбасары.

– Без укытучылар династиясе, – дип сүзен башлады Фәрит Шакиров. – Әтием Салих белән әнием Шәмсенасар да гомер буе Түбән Ушмы урта мәктәбендә эшләде. Берсе тарих, җәмгыять белеме, икенчесе математика укытты. Әти күп еллар мәктәп директоры булып торды. Хәзерге Түбән Ушмының мәктәп бинасын ул салдырган. Мин исә технология, хатыным рус теле, әдәбияты укытучысы. Шулай булгач, мәктәп безнең тормышның аерылгысыз бер өлеше.

Шакировлар ике бала үстергән. Олы уллары Дамир, Алабуга дәүләт педагогия университетын тәмамлап, Түбән Ушмыда технология, ТИН дәресләрен укыта. Кызлары Диләрә дә шул ук уку йортының татар теле, инглиз теле бүлеген тәмамлаган. Гаиләсе белән Чаллыда яши, әлегә кечкенә баласы белән ялда. Аңа кадәр балалар бакчасында тәрбияче булып эшләгән.

– Әле бит Фәритнең ике апасы да укытучы, – дип сүзгә кушылды Зәйтүнә апа. – Иң олы апасы Рәмзия апа алтмыш җиде яшендә, әлеге кадәр көллияттә укыта. Икенче апасы Рузалия апа да алтмышка кадәр эшләде. Бер елны династияләр буенча район конкурсында катнашкан идек. Шул вакыт Фәрит белән Шакировлар династиясен нык өйрәндек. Баксаң, безнең нәселдә укытучылар күп булган. Узган гасырда Мамадышта педагогия училищесы эшләгән, күбесе әнә шунда укыган. Безнең әти белән әни дә заманында әлеге уку йортын тәмамлаган.

Шакировлар матур, зыялы гаилә. Шуңа өстәп бик тырышлар да. Хәләл көчләре белән зур йорт җиткергәннәр, бүген инде балаларына булышалар. Мәктәп эшеннән тыш, тагын бер күңелләренә хуш килгән өлкә бар – умартачылык. 1994 елдан бирле кортлар тоталар икән.

2 Күп фаҗигаләрдән дә исән калган борынгы мәчет.

3 Сүзе белән дә, йөзе белән дә иман нуры таратучы авыл имамы – Илнар хәзрәт Фәхретдинов.

– Ул чорда тормышлар авыр иде бит, укытучыларның хезмәт хакы түбән. Аз булса да акча керер дип, кортлар үрчетә башладык, – дип елмайды Фәрит абый. – Һәм ялгышмаганбыз – кортлар безгә аякка басарга нык ярдәм итте. Умартачылык шөгыленә җитди килдек: өйдә махсус әдәбият тупланган кечкенә генә китапханәбез дә бар. Бу өлкәдә белем, тәҗрибә булмаган килеш кортлар үрчетә башладык. Ә укымыйча, өйрәнмичә генә уңышка ирешеп булмый.

Бүген Шакировларның хуҗалыгында кырык оя умарта бар. Тагын әле уллары Дамир да кортлар тота. Аныкы авылда түгел, болында икән. Кыскасы, бу гаилә җәй көне бер тик тормый.

– Умарта кортлары кышны ничек чыкты? – дим.

– Аллага шөкер, әйбәт кышладылар. Берәм-сәрән генә үлә инде ул, анысы куркыныч түгел. Яз соң килгәнгә, кортлар быел соңрак эшли башлады, ләкин миңа калса аның зыяны булмас. Умартачылык өлкәсендә бүген төп проблема – балны урнаштыру. Мамадыш районы умартачылар төбәге бит. Республика буенча иң күп умартачылар бездә. Шулай булгач, конкуренция көчле.

Фәрит абый бал сатуның җаен тапкан – ишек алдына агачтан беседка ясап куйган. Җәй буе шунда чәй кайнап утыра. Сатып алучыларга башта яңа аертылган бал белән шул беседкада чәй эчертә. Бер банка балга дип килгән кешеләр, икене алып китә икән.

– Кешегә караганда балның бәясен илле, йөз сумга арзанрак та итәм, – дип дәвам итте умартачы. – Фәлән сумга кимрәк акча керә, аның каравы сатылып бетә. Тимерне бит кызуында сугарга кирәк, бал вакытында урнашмаса, аннары шулай савытларда тора ул. Халык балны тәмле килеш ашасын. Безгә дә күңелле, аларга да отышлы.

...Түбән Ушмыда һәр өч йортның берсендә бал кортлары тоталар. Шакировлар кебек кырыгар оя, биш-ун баш тотучылар да бар. Аның каравы мал-туар бик асрамый халык. Авылда Рифат Мотыйгуллинның зур агрофирма булганга, күпләр шунда эшли. Алабуга, Чаллы, Мамадышка йөреп эшләүчеләр дә байтак.

Түбән Ушмыда социаль объектларның барысы да төзекләндергән булуы сөендерде. Мәдәният йорты, балалар бакчасы, заманча амбулатория үзәге – барысы да соңгы ун ел эчендә яңартылган. Авылны Мамадыш районының визит карточкасы дияргә буладыр. Юллар салынган, йортлар төзек. Хәтта үзләренең бик зур спорт үзәкләре дә бар. Нәкъ шәһәрдәгечә ул – мунчасы, тренажерлары, аерым киенү бүлмәләре, зур заллары белән. Атна саен диярлек анда район, республика ярышлары уза. Шуңа күрә дә без авылны заманча зур бер бистәгә охшатып кайттык.

4

5

4

– Яз соң килгәнгә, кортлар быел соңрак эшли башлады, ләкин, миңа калса, аның зыяны булмас, – диде Фәрит Шакиров.

5

Укытучылар династиясен дәвам итүче Шакировлар.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Флера Мөхәммәтханова, мәгариф ветераны, авыл тарихын өйрәнүче:

– Гомерем буе көндәлекләр яздым, әле дә алып барам. Шул исәптән авыл тарихына караган истәлекләрне дә язып бардым. Берничә ел элек аларны җыеп «Түбән Ушмы авылы тарихыннан сәхифәләр» дип китап та чыгардым.

Авылга Ушмы атлы мари карты нигез салган, дип беләбез. Халык теленнән күчкән тарих бу. Татарлар килеп урнашкач, марилар башка җирләргә күченеп киткән булырга тиеш. Зиратта XIII гасырга караган кабер ташлары бар. Димәк, шул чорларда ук биредә халык яшәгән дигән дәлил бу. Безнең мәктәпне тәмамлаган язучылар Шаһинур Мостафин, Ринат Мөхәммәдиев та авыл тарихы белән кызыксынды. Казан Фәнни-тикшеренү институтында эшләүче авылдашыбыз Лилия Мөхәммәтҗанова бар, ул да әлеге борынгы ташларны, архив документларын өйрәнде. Алар да, шул чорларда монда татарлар яшәгән, дигән фикергә килде.

«КАРАВОН» ҖӘЙГӘ СТАРТ БИРДЕ

Яңгырлы май ахырында Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында 30 нчы тапкыр «Каравон» рус халык бәйрәме узды.

170 тән артык коллектив, 150 дән артык халык һөнәрчелеге остасы һәм республиканың төрле почмакларыннан килгән күп кенә кунаклар, яңгырга да карамастан, «Каравон» белән бергә җәйне һәм күпмиллэтле Татарстан халыкларының җәйге милли бәйрәмнәрен башлап җибәрү өчен гадәттәгә Никольск авылына җыелды.

– «Каравон» беренче булып безнең традицион җәйге бәйрәмнәрне башлап җибәрә. Аннан соң мари, чуваш, татар бәйрәмнәре узачак. Бәйрәм республикабызның танылган брендына әйләнде, – дип билгеләп үтте ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов. – Рус мәдәнияте – ул безнең илнең нигезе. Мин бу матур бәйрәмгә чын күңелдән рәхмәтлемен.

Президент билгеләп үткәнчә, «Каравон» бәйрәме аша бүген яшь буынга тапшырылырга тиешле күп кенә традицион һөнәрләр яңадан торгызыла.

Фото: Александр Ефремов

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама